# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2021 3(31)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

***Журнал «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында 2014 елдан кварталга бер сан нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның халык шагыйре (Казан)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
СӘЛАХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Төркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Нур-Солтан)

► **БАШ РЕДАКТОР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
МӨХӘММӘТҖАНОВА Л.Х., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать), МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият), ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т., ЛУКЬЯНЧЕНКО Е.Ф., ЧУГУНОВ А.С.

## БУ САНДА

### ТЕЛ БЕЛЕМЕ


*Вәлиева М.З.* XVII–XVIII гасыр иске татар язма чыганакларында «вакыт» категориясе белән бәйле лексик берәмлекләр . . . . . . . 7
*Сәгъдиева Р.К.* Сүзләр арасындагы төгәлләүле мөнәсәбәтне белдерә торган чара буларак сүзләрнең янәшә торулары . . . . . . . 15
*Хисамов О.Р., Хөсәинова А.Я.* Төмән өлкәсе Төмән районы географик терминнарының фонетик һәм лексик үзенчәлекләре . . . 23
*Булатова Ә.К., Сәгъдиева Ф.К.* Татар телендә чигү эшенә караган лексик берәмлекләр (эш әсбаплары һәм кирәк-яраклары мисалында) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31


### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ


*Закирҗанов Ә.М.* XXI гасыр башы драматургиясендә милли яшәеш мәсьәләләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
*Каюмова Г.И.* Ризван Хәмиднең «Хан кызы» драмасында тарихи шәхес концепциясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
*Закирова И.Г., Даутова С.Б.* И. Есенберлинның «Алтын Урда» романында хөкемдар образы. Эпик традицияләр һәм заман идеологиясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
*Мусабәкова Р.Р.* Тәрҗемә мәсьәләләренә карата: Рөстәм Кутуй . . . 62


### ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ


*Шәйдуллин Р.В.* 2002 һәм 2010 еллардагы Бөтенроссия халык санын исәпкә алуларда Татарстан халыклары . . . . . . . . . . . . 67
*Рәсүлов А.Н., Рәсүлова Р.А.* Татарлар Төркестан автономиясендә (1917–1918 еллар) . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78


### ХАЛЫК ИҖАТЫ


*Хәбибуллина Э.К., Дәүләтшина Л.Х.* Төрки халыкларда бала тууга бәйле йолалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
*Хөсәенова Г.Р.* Дастаннарда жанр атамасындагы төрлелек мәсьәләсе әдәбият һәм фольклор яссылыгында . . . . . . . . . . . 95


### МИЛЛИ МӘГАРИФ


*Хәбетдинова М.М.* Нәкый Исәнбәтнең педагогик эшчәнлеге һәм карашлары (галимнең фәнни биографиясен төзү юлында) . . 103
*Ибәтуллин А.Г.* Хәзерге заман милли мәгарифендә рухият һәм традицияләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119


### СӘНГАТЬ


*Юнысова Г.Ф.* Татар вокаль музыкасында шигырь текстын тәрҗемә итү мәсьәләләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
*Халикова И.И.* Ф. Халиков әсәрләрендә борынгы Казанны сурәтләү үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135

**ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР ФӘНЕ**

*Габиббәйле И.А.* Азәрбайҗан әдәбиятын дөньяга танытткан ядкяр: Низами Ганҗәвинең «Җиде гүзәл»е . . . . . . . . . . . . . . . . . 142

**ФӘННИ ЯДКЯРЛӘР**

Ә. Каргалыйның «Румлылар белән кытайлар арасындагы бәхәс» шигъри хикәяте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147

**ЯҢА КИТАПЛАР**

*Галимова О.Н.* И. Сабитова, Г. Саберованың «Үсемлек атамаларының татарча-русча аңлатмалы сүзлеге» (Казан: ТӘҺСИ, 2020. 216 б.) турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153

*Сафиуллина Р.Ф.* «Милли-мәдәни мирасыбыз: Удмуртия татарлары» (Казан, 2021. 2 нче басма. 400 б.) китабы турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156

*Гайнуллина Г.Р.* Н.М. Йосыпованың «XX гасырның икенче яртысы татар шигърияте: традицияләр һәм яңачалык» (Казан: Школа, 2021. 296 б.) китабына бәяләмә . . . . . . . . . . 162

**ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

*Кадирова Э.Х.* Ләйлә Мәхмүтова – татар тел белеме тарихында тирән эз калдырган шәхес . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167

**ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН**

## В НОМЕРЕ

### ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Валиева М.З.* Лексические единицы, связанные с категорией «время» в старотатарских письменных памятниках XVII–XVIII вв. . . 7

*Сагдиева Р.К.* Соседство слов как средство связи конкретизирующего отношения . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15

*Хисамов О.Р., Хусаинова А.Я.* Фонетические и лексические особенности географических терминов на территории Тюменского района Тюменской области . . . . . . . . . . . 23

*Булатова А.К., Сагдеева Ф.К.* Татарские лексические единицы, относящиеся к вышивальному делу (на материале наименований инструментов и аксессуаров) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31

### ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Закирзянов А.М.* Проблемы национального бытия в драматургии начала XXI века . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35

*Каюмова Г.И.* Концепция исторической личности в драме «Ханская дочь» Ризвана Хамида . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43

*Закирова И.Г., Даутова С.Б.* Образ правителя в романе «Золотая Орда» И. Есенберлина. Эпические традиции и идеология эпохи . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53

*Мусабекова Р.Р.* К вопросу перевода: Рустем Кутуй . . . . . . . . . 62

### СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Шайдуллин Р.В.* Народы Татарстана в всероссийских переписях населения 2002 и 2010 гг. . . . . . . . . . . . . . 67

*Расулов А.Н., Расулова Р.А.* Татары в Туркестанской автономии (1917–1918 годы) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78

### НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Хабибуллина Э.К., Давлетшина Л.Х.* Обряды родильно-нарекательного цикла у тюркских народов . . . . . . . . . . . . . . . 87

*Хусайнова Г.Р.* Проблема разнородности жанровых названий в дастанах сквозь призму литературы и фольклора . . . . . . . . . . 95

### НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Хабутдинова М.М.* Педагогическая деятельность и взгляды Наки Исанбета (на пути к созданию научной биографии ученого) . 103

*Ибатуллин А.Г.* Духовность и традиции в современном национальном образовании . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108

### ИСКУССТВО

*Юнусова Г.Ф.* Переводы поэтического текста в татарской вокальной музыке . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124

*Халикова И.И.* Ф. Особенности образа ханской Казани в произведениях Ф. Халикова . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131

## НАУКА ТЮРКСКИХ НАРОДОВ

*Габиббейли И.А.* Мировая жемчужина азербайджанской литературы: «Семь красавиц» Низами Ганджяви . . . . . . . . . . 142

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

Поэтическое повествование «Спор ромейцев с китайцами» А. Каргалый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147

## НОВЫЕ КНИГИ

*Галимова О.Н.* О книге И. Сабитовой и Г. Саберовой «Үсемлек атамаларының татарча-русча аңлатмалы сүзлеге» (Казань: ИЯЛИ, 2020. 216 с.) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153

*Сафиуллина Р.Ф.* О книге «Милли-мәдәни мирасыбыз: Удмуртия татарлары» (Казань, 2021. 2-е изд. 400 с.) . . . . . . . . 156

*Гайнуллина Г.Р.* Рецензия на книгу Н.М. Юсуповой «XX гасырның икенче яртысы татар шигърияте: традицияләр һәм яңачалык» (Казань: Школа, 2021. 296 с.). . . . . . . . . . . . . 162

## ПЕРСОНАЛИИ

*Кадирова Э.Х.* Ляйля Махмутова – личность, оставившая глубокий след в истории татарского языкознания . . . . . . . . 167

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 81′37

*М.З. Вәлиева*

# XVII–XVIII ГАСЫР ИСКЕ ТАТАР ЯЗМА ЧЫГАНАКЛАРЫНДА «ВАКЫТ» КАТЕГОРИЯСЕ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЛЕКСИК БЕРӘМЛЕКЛӘР

В статье рассматриваются особенности вербализации категории «время» в старотатарских письменных источниках XVII–XVIII веков. Как показало исследование, в них наблюдается употребление самых разнообразных лексических единиц с временными значениями. В генетическом плане их можно разделить на две группы: слова тюрко-татарского происхождения и арабо-персидские заимствования. Со временем их семантика расширилась за счет коннотаций религиозного и духовно-культурного характера.

**Ключевые слова**: старотатарский литературный язык, старотатарские письменные источники XVII – XVIII веков, лексика, лексические единицы с временными значениями, семантика, религиозные и духовно-культурные коннотации.

The article discusses the features of the verbalization of the category «time» in the old Tatar written sources of the XVII–XVIII centuries. According to the study, they use a wide variety of lexical units with temporal meanings. In genetic terms, they can be divided into two groups: the words of Turkic-Tatar origin and Arab-Persian borrowings. Over time, their semantics have expanded due to connotations of a religious and spiritual-cultural nature.

**Keywords:** old Tatar literary language, old Tatar written sources of the XVII–XVIII centuries, vocabulary, lexical units with temporal meanings, semantics, religious and spiritual-cultural connotations.

Тел белемендә «вакыт» төшенчәсе киңкырлы категорияләрнең берсе санала. Мәсәлән, татар теленең аңлатмалы сүзлегендә *вакыт* сүзенең барлыгы җиде мәгънәсе теркәлгән: 1) фәлсәфи яктан караганда, яшәешнең объектив бер формасы; 2) яшәеш дәвамлылыгын секундлар, минутлар, көннәр, айлар, еллар белән бүлеп исәпли торган кисем, аралык; 3) эштән, берәр шөгыльдән соңгы буш ара, төп эштән бушаган чак; 4) гомумән, тормышта берәр чор, дәвер, чак; 5) сөйләмгә төгәллек өсти: шул чак, шул ара; 6) берәр эш-хәлгә билгеләнгән вакыт, срок, чак; 7) нинди дә булса эшне башкару яки берәр эш кәгазен тутыру датасы көне [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2005, б. 110]. Телдә мәгънәләр күптөрле лексик берәмлекләр белән белдерелә. Татар тел белемендә бу берәмлекләр диалектолог галимә Т.Х. Хәйретдинова тарафыннан өйрәнелгән. Аерым алганда, аның хезмәтләрендә атна, көн, ел фасыллары һ.б. белдерә торган сүзләрнең татар диалектларында кулланылышы тикшерелә [Хәйретдинова, 2004; 2006; 2007]. Әлеге мәкалә кысаларында бу төр сүзләрнең XVII–XVIII гасыр язма

истәлекләрендә кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү максат итеп куелды.

XVII–XVIII гасыр язма истәлекләрендә «вакыт» төшенчәсен белдереп килә торган лексик берәмлекләрдән түбәндәгеләр еш очрый: *вакыт, заман, дәвер, корун, җаһилият, ел, сәнә, ай, көн, сәгать, һәнүз, даим* һ.б. Бу сүзләр һәм алар катнашында ясалган сүзтезмәләр «вакыт» төшенчәсенең мәгънәви төсмерләрен ачыклап, конкретлаштырып киләләр. Мәсәлән, «тормышта берәр чор, дәвер, чак» төшенчәсе язма чыганакларда *заман, дәүер, корун* һ.б. сүзләр белән белдерелә. *Заман* сүзенең җәмгыять үсешендә, яшәештә билгеле бер вакыт, дәвер, чор мәгънәсен белдерү максатыннан кулланылышы ешрак күзәтелә: *Ул биш нәрсәнең берсе – Кыямәт көненең каю заманда вә каю фасылда, вә каю көндә булмагыны Аллаһы Тәгаләдән гайре белмәсләрдер* [Мөслими, 1999, б. 17]. *Андаг сылу кешене ул заманда һич күрмеш йук ирде, артындан ике даясе алтын табакка сачын салыб йөртер ирде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 77]. Текстларда «чор, замана» мәгънәләрен *заман* лексемасы белән беррәттән *дәвер* сүзе дә белдерә: *Ошда анлар мондаг чиру белән килмәкдә, әмма ул дәүердә, ул заманда Болгар шәһәрендә ханлары Габдулла хан дигән ирде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 85]. Түбәндәге мисалда *вакыт* лексемасының «чор, дәвер» мәгънәсендә кулланылуы күзәтелә: *Корун мөнкасим улыр, аны вакыт диерләр* [Мөслими, 1999, б. 8]. Гарәп теленнән кергән *корун* сүзенең «йөз еллык вакыт, гасыр, чор» мәгънәләрен белдерүен игътибарга алсак, бу очракта *вакыт* лексемасы аның мәгънәдәш пары булып чыга.

Түбәндәге җөмләдә *заман* сүзе «наданлык, белемсезлек» мәгънәләрендәге *җаһилият* термины белән янәшә килеп, «наданлык, белемсезлек хөкем сөргән чор» дигәнне аңлата: *Вәҗһе тәсмия бил-гарәбия улдыр ки, Пәйгамбәребез галәйһисәлламнең җаһилият заманында Һашим дидеге йөкчәк бабасы бар иде, гарәб кабиләләренең газыйм шаһы ирде* [Мөслими, 1999, б. 13].

Берәр күренекле шәхес яшәгән яисә идарә иткән чор турында мәгълүмат биргәндә әлеге лексик берәмлек шул зат исеме белән семантик бәйләнешкә керә: *Бараҗ хан заманында Вулгы иделе андин күчеб мәгъриб тарафындан акды* [Мөслими, 1999, б. 26].

Язма чыганакларда «заман, чор» мәгънәсе түбәндәге мисалда *бу көндә* сүзтезмәсе белән дә җиткерелә: *Бу көндә ул мөбарәк күл бардыр, урыслар аны нәҗес күл диеб эчмәзләр, ул чиркәүгә кермәсләр Аксак Тимер нәҗес әйләде диеб* [Мөслими, 1999, б. 46].

Югарыда китерелгән мисалларда *заман, вакыт, дәүер* сүзләре һәм *бу көндә* сүзтезмәсе үзара мәгънәдәш сүзләр буларак кулланылганнар.

*Замане әүвәл* сүзтезмәсеннән исә «борынгы чор» төшенчәсе аңлашыла: *Замане әүвәлдә Тәфтазани илә Әндрай кальгасе бер иде, Тәфтазани бер мәхәллә ирде* [Мөслими, 1999, б. 48]. «Дәфтәре Чыңгызнамә» әсәрендә әлеге мәгънәне *әүвәл заман* сүзтезмәсе җиткерә:

*Әүвәл заманда Ак диңгез эчендә Мальта дигән шәһәр бар иде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 69]. *Бараҗ халкының әүвәл замандагы борынгы төб йорты ошбу Зәй тамагыда улыр ирде* [шунда ук, б. 85].

Текстларда «борынгы чор, элекке вакыт, нинди дә булса вакыйгага кадәрге вакыт, элек» төшенчәләрен *замане әүвәл, әүвәл заман* сүзтезмәләре белән беррәттән, *борынрак* лексемасы да белдереп килә: *Андин бер углан йөгереб узыб, ул куйган нәрсәне алайын, мин элек хан булайын тигүнчә, андин борынрак ул нәрсәне Аксак Тимер бүреген ташлаб орды* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 82].

*Шул ук заман* сүзтезмәсендә килгән очракта *заман* берәмлеге вакытны конкрет атап килә, нинди дә булса эш-вакыйгага бәйләп, аның чикләрен билгели: *Шул ук заман утыз тәвагә йөк йөкләделәр* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 83].

Семантик яктан караганда, *шул ук заман* һәм *ул вакытта* сүзтезмәләре үзара синоним булып торалар: *Әмма ул вакытта Турымтай Чәчәннең углы Тумавыл Мәргән атасына ачы ирде, ил тышына чыгып йатар ирде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 70].

Чыганакларда «шул ук вакытта» төшенчәсен гарәп алынмасы *дәрхаль* дә белдереп килә: *Дәрхаль ут сәр вә мәүхәм берлә набәдүт булд*ы [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 507].

Ә инде вакытны чикләмичә, «һаман, һәрчак» төшенчәләрен бирергә кирәк булганда, авторлар гарәп чыгышлы *һәнүз* һәм *даим* лексемаларына мөрәҗәгать итәләр: *Ул сурәт улан ташка «өфф» дисәләр, ком улыр, «өфф» димәен суга салсалар, һәнүз адәм сурәтендә дорыр* [Мөслими, 1999, б. 24]. *Вә әгәр мәни танымасаң, мән ул ак елан торырмын кем, кара еланның кулындин хәлас кылдың вә сәбәбе хәятем сән булдың вә ул кара елан атамның бәндәсе ирде вә даим мәңа гадәвәт кылыб форсат саклар ирде* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 505].

Язма истәлекләрдә «вакыт» төшенчәсе белән бәйле лексик берәмлекләр күпчелек очракта яшәеш дәвамлылыгын секундлар, минутлар, көннәр, айлар, елларга бүленә торган аралыкларны да белдереп киләләр. Мәсәлән, биредә «билгеле бер вакыт аралыгы» төшенчәсен белдерү өчен *вакыт-вакыт берлән* сүзтезмәсе һәм *мөддәт* сүзе кулланыла: *Әмма ул Алтын хан үзе вакыт-вакыт берлән килер ирде, күрә торган ирде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 69]. *Вә ул әхвалдин һич йөзигә салмады вә бу арада берничә мөддәд үтеп ирде, пәри кызыйдин янә бер кыз вөҗүдкә килде* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 508].

Язма чыганакларда «ел» төшенчәсен бирү өчен төрки-татар асыллы *ел* сүзе актив кулланыла. Авторлар тарафыннан аның унике айдан торуы да искәртелә: *Унике ай елына, дәүре заман эчендә* [Мәүлә Колый, 1963, б. 500].

Гадәттә бу лексема еллар исәбен күрсәткән саннар белән янәшә килеп, вакытны чикләп күрсәтә: *Ул көймә берлә бер ел киттеләр, диңгездән гайрене күрмәделәр* [Мөслими, 1999, б. 21]. *Имде Тумавыл Мәргән егерме йыл ханлык сөрде, андин соң Дуйын Бәйан унтугыз йыл ханлык сөрде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 71].

Язма истәлекләрдә еш кына бу терминның гарәп теленнән кергән *сәнә* синонимын очратырга мөмкин: *Тарих һиҗрәте рәсүлуллаһи галәйһисәлламнең тугызынчы сәнәсендә Хут йолдызында, Рамазан мөкәррәмәнең тугызынчы көнендә Болгарда ул заманда хан аталмыш кемсәнә Айдар хан ирде* [Мөслими, 1999, б. 25].

Әлеге мисалда без «вакыт» төшенчәсе белән бәйле *тарих һиҗрәте* сүзтезмәсе белән дә очрашабыз. Белгәнебезчә, *һиҗри / һиҗрәт* терминнары белән мөселманнарның ай хисабы белән йөртелә торган ел башын атаганнар, ә *тарих* лексемасы исә, үзенең төп мәгънәсеннән тыш, «вакыт, дата» мәгънәләрен дә белдерә.

Шунысын искәртергә кирәк, язма истәлекләрдә *сәнә* белән чагыштырганда *ел* термины ешрак очрый һәм ул, беренче чиратта, үзенең төп мәгънәсендә кулланыла: *Тарих һиҗрәтнең тугызынчы йөз икенче елы ирде, эт елы ирде* [Мөслими, 1999, б. 47]. Әлеге мисалдан күренгәнчә, Идел буе татарлары, вакытны белдерү өчен, һәрбер ел берәр хайван атамасы белән әйтелә торган 12 еллык циклдан файдаланганнар. Галимнәр фикеренчә, елларны 12 хайван циклы белән атау Идел буе Болгар дәүләте төзелгәнче үк гуннардан үтеп кергән булырга тиеш [Беркутов, 1987, с. 11]. XVII–XVIII гасыр язма истәлекләрендә дә елларны шул традиция нигезендә атау өстенлек итә.

Текстларда кайбер очракта төрки-татар асыллы һәм алынма лексик берәмлекләр янәшә кулланыла. Мәсәлән, «сарык елы» мәгънәсендәге *куй елы* һәм *хәмәл елы* сүзтезмәләрендәге *куй* һәм *хәмәл* сүзләре: *Сәфәрнең егерме алтынчы көнендә, тарих һиҗрәтнең илле алтынчы елы ирде, куй елында мөбарәк җомга кичәсендә иде* [Мөслими, 1999, б. 11]. *Ел башыдыр гарәбләр катында, әмма гаҗәмләр катында ноуруз, ягъни хәмәл ел башыдыр* [Мөслими, 1999, б. 10]. *Андин соң тарих мең дә илле өч тә ирде, кенәз Михайла Фидорович хан булды, куй йылы ирде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 91].

Биредә шунысын да онытырга ярамый, *куй елы* һәм *хәмәл елы* дигәндә, ике төрле календарь күздә тотылырга мөмкин. Беренчесе – төрле хайваннарның исемнәре бирелгән унике еллык циклга, икенчесе кояш ел хисабына нигезләнгән календарь. Соңгысында яңа ел башы нәүрүзгә, ягъни унике йолдызлыкның өченчесенә – сарык бәрәне, гарәпчә хәмәл, русча овен аена – мартка туры килә [Дәүләтшин, 1999, 175–176]. Югарыда китерелгән мисалларда да шул хакта сүз бара. Димәк, Мөслиминең «Тәварихы Болгария» әсәрендә кояш календаре күздә тотылган булса, «Дәфтәре Чыңгызнамә»дә унике еллык циклга нигезләнгән календарь кулланылган булырга мөмкин. Әйтергә кирәк, язма чыганакларда соңгысына караган барлык ел атамаларын да очратырга мөмкин. Алар күпчелек очракта җөмлә ахырында кулланылып, теге яки бу вакыйгаларның башкарылу вакытын тагын да төгәлләштереп киләләр. Мәсәлән: *Тарих һиҗрәтнең тугызынчы йөз икенче елы ирде, эт елы ирде* [Мөслими, 1999, б. 47]. *Андин соң йәнә беләсез кем, Чыңгыз хан пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллалаһу галәйһи вә сәлламнең тарихындан соң биш йөз кырык ту-*

*гызынчыда ирде, туңгыз йылында Зөлкәгъдә айында анадин тугды* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 81]. *Йәкшәмбе көн гакраб йолдызының икенче көне ирде, сычкан йылында ирде* [шунда ук, б. 91]. *Андин соң тарих мең дә йегерме дүртдә ирде, Җанали йагый булды, сычкан йылы ирде* [шунда ук, б. 91]. *Андин соң тарих мең дә иллед͏ә ирде, илгә чиру булды, йылан йылы ирде* [шунда ук, б. 91]. *Андин соң тарих мең дә унйидедә ирде, кенәз Митрий йагый булды, тавык йылы ирде* [шунда ук, б. 91]. *Андин соң тарих мең дә йитмеш тукызда ирде, казак урыс берлә йагый булды, эт йылы ирде* [шунда ук, б. 91]. *Андин соң тарих мең дә алтмыш бишдә ирде, уләд булды, йылкы йылы ирде* [шунда ук, б. 91]. *Андин соң тарих мең дә йитмеш бердә ирде, башкорт урыс берлә йагый булды, барс йылы ирде* [шунда ук, б. 91].

Мисаллардан күренгәнчә, ел атамалары буларак, нигездә, төрки-татар асыллы сүзләр кулланылган: *сычкан, куй, барс, йылан, эт, дуңгыз, йылкы* һ.б. Аларның һәрберсе аерым символик мәгънәгә ия булган һәм тотем хайван булып исәпләнгән. Эт елы муллык, иминлек елы буларак юралган. Аеруча мал-туар асрауда уңышлар көтелгән [Дәүләтшин, 1999, б. 95]. Төрки халыкларда барс шулай ук байлык, көч-куәт, дан-дәрәҗә китерә торган изге хайван саналган. Шуңа күрә халыкта аның елы уңыш китерә, байлык-муллыкка ирешә торган ел буларак кабул ителгән.

XVII – XVIII гасыр язма истәлекләрендә урын алган ел фасылы атамалары бүгенге көнгә бернинди үзгәрешсез килеп җиткәннәр. Яз фасылы еш телгә алына: *Язны алты ай яратты...* [Мәүлә Колый, 1963, б. 500]. *Яз йелләрен истергән...* [шунда ук, б. 500]. *Бер көн ул Кәнанә вәзирләре илә, язның әүвәлге ае ирде, сәфәрә чыкдылар илә күрделәр ки, сачәкләр ачылмыш* [Мөслими, 1999, б. 11]. *Хан әйде, кыш көнендә аны кайдан алмак кирәкдер, диде* [шунда ук, б. 26]. *Яз фасылында Шәһри Болгара ирешделәр* [шунда ук, б. 43]. *Әлкыйсса, ул кыш анда кышлады* [шунда ук, б. 47]. *Йай көне ирде, Амәт биек тауның башында ултырыб торыр ирде, кыз алсыдан караб күрде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 75].

Утыз көнлек вакыт аралыгын белдерә торган *ай* сүзе текстларда үзенең туры мәгънәсендә генә кулланыла: *Икенче бармагы ишарәтдер, ягмур ягмагыны каю айда вә каю көндә, вә каю сәгатьдә ягмагыны Аллаһы Тәгаләдән гайре белмәсләрдер* [Мөслими, 1999, б. 17]. *Өч айгача яхшы хезмәтләр кылыр ирде* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 519]. *Өч айда барыб йитделәр* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 75].

Мәгълүм булганча, ислам дине кабул ителгәннән соң, төрки-татарларда гарәп асыллы ай атамалары да кулланылышта йөри башлый. Бу ай атамалары язма истәлекләрдә генә түгел, болгар-татар эпиграфика ядкярләрендә дә күпләп сакланып калган [Юсупов, 1960]. XVII–XVIII гасыр язма чыганакларында вакыйгаларны тасвирлау барышында авторлар шулай ук әлеге лексик берәмлекләрне файдаланганнар: *...Рамазан мөкәррәмәнең тугызынчы көнендә Болгарда ул заманда хан аталмыш кемсәнә Айдар хан ирде* [Мөслими,

1999, б. 25]. *Йәнә йитмеш ике йылдан соңра, туңгыз йылында, мөбарәк Рамазан айының ундүртенче көн, тарих алты йөздә дөнйадан вафат итде, сүзе дөнйада калды* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 81]. *Андин соң йәнә беләсез кем, Чыңгыз хан пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллалаһу галәйһи вә сәлламнең тарихындан соң биш йөз кырык тугызынчыда ирде, туңгыз йылында Зөлкәгъдә айында анадин тугды* [шунда ук, б. 81]. *Аксак Тимернең орышыга түзмәделәр, сындылар, килеб Болгар шәһәрегә керделәр* [шунда ук, б. 85]. *Сәфәрнең егерме алтынчы көнендә, тарих һиҗрәтнең илле алтынчы елы ирде, куй елында мөбарәк җомга кичәсендә иде* [Мөслими, 1999, б. 11].

Без тикшергән текстларда «вакыт» төшенчәсе белән бәйле көн һәм сәгать сүзләре дә очрый. Биредә алар үзләренең төп мәгънәләрендә кулланылалар. Мәсәлән: *Көнне төндин озайтты* [Мәүлә Колый, 1963, б. 500]. *Көн, төн хыял эчендә* [шунда ук, б. 500].

Түбәндәге мисалда *көн* сүзе *берничә көн* сүзтезмәсе составында берничә тәүлеккә сузылган вакыт аралыгын белдереп килә: *Берничә көн анда җәүлан кыйлдым, дуслар* [шунда ук, б. 489].

*Көнләрдә бер көн* сүзтезмәсендә аның мәгънәсе билгесезлек төсмере белән баетыла: *Көнләрдә бер көн Әндрай кальгасына йитделәр* [Мөслими, 1999, б. 42]. *Көнләрдә бер көн, балигъ булгандин соң әйтер ирде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 69].

*Бу көн, ул көн* сүзтезмәләре составында ул киресенчә конкретлык мәгънә төсмеренә ия була: *Кани бу көн кулдин китте, нитмәк кәрәк* [Мәүлә Колый, 1963, б. 492]. *Гомеремдә ир йөзен күргәнем йук торыр, бу көн кич сине күрдем, – тиде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 70]. *Ул көн һич нәрсә белмәделәр* [шунда ук, б. 75].

Узган көннәр турында мәгълүмат бирергә теләгәндә, авторлар *өч көн борын, түнәге көн* сүзтезмәләрен кулланалар: *Андин өч көн борын халкыдин бикләрен йийыб әйде...* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 71]. *Әллә син түнәге көн бер ботка сатып алган Балин берлән уйнаш идеб, буаз булгансың, – диделәр* [шунда ук, б. 73]. *Түнә көн диванханәдә күренде кәгазьләре* [Мөслими, 1999, б. 39]. Соңгы мисалларда теркәлгән «кичә, кичәге көн, узган көн» мәгънәләрендәге *түнә / түнәге / төнәге* лексемалары бүгенге көндә татар диалектларында сакланып калган.

Язма чыганакларда көн саен кабатлана торган вакыйгаларга мөнәсәбәттә *һәр көн* сүзтезмәсе кулланыла: *Алты-йиде угыл булыб һәр көн бозау көтәр ирделәр* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 82].

Геройның бертуктамый эшләвен ассызыкларга теләгән очракта авторлар *көн-төн* парлы сүзенә мөрәҗәгать итәләр: *Бу мискин, Мәула Колый, төн-көн тик ятмай* [Мәүлә Колый, 1963, б. 488]. *Көн-төн батыйн эчрә коръән тезеде* [шунда ук, б. 489]. *Көн-төн тәсбихен әйтер* [шунда ук, б. 502].

Туачак, булачак көнне белдерү өчен алар хәзерге телдә дә актив *иртәгә, иртәгәсен* сүзләрен кулланганнар: *Дүртенче бармагы ишарәтдер, һич нәфес белмәс иртәгә ни кәсеб кыйласын, Аллаһы Тә-*

*галәдән гайре белмәсләр* [Мөслими, 1999, б. 17]. *Иртәгәсен Чыңгыз хан түрт ыруның олы кешеләренә олуг кыргын итде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 77].

Белгәнебезчә, төрки-татарларда көннәрне атауда ике төрле система яшәп килә, аның берсе халыкта, диалектларда кулланыла торган көн атамалары, икенчесе – фарсы теленнән кабул ителгән һәм бүгенге көндә татар әдәби телендә дә кулланыла торган берәмлекләр. Фарсы чыгышлы атамалар татар теленә ислам дине белән бергә үтеп керә һәм иң борынгы язма истәлекләрдә дә очрый [Беркутов, 1987, с. 20]. «Тәварихы Болгария» әсәрендә без шулардан *чәһаршәмбе* атамасы белән очрашабыз: *Чәһаршәмбе көннең кичәсендә тәмам госел идеб вә намаз кыйлыб беткәнләрендән соң...* [Мөслими, 1999, б. 12].

«Тәварихы Болгария»дә көн исемнәренең гарәпчә вариантлары да теркәлде: *йәүмел-җомга, йәүмес-сәбет, йәүмел-әхәд, йәүмел-иснәйн, йәүмел сөляса, йәүмел-әрбага, йәүмел-хамис* [шунда ук, б. 8–9].

Мәгълүм булганча, җомга көн мөселманнар тарафыннан аеруча югары бәяләнгән, изге көн буларак каралган. Гасырлар дәвамында туплана килгән ышану-йолалар һәм ислам дине кануннары буенча, җомга көнне кылган дога, теләнгән теләкләр кабул була. Җомга көн – башка барлык көннәрдән дә өстен торган иң изге көн. Әлеге сүз үзендә халыкның дөньяга карашын, рухи күзаллавын чагылдыра торган этномәдәни һәм дини атама булып тора. Бу түбәндәге мисалда да чагылыш таба: *Вә Адәм галәйһисәллам дөньяга җомга көн килде һәм җомга көн оҗмахка керде һәм җомга кон оҗмахтан чыкты* [Мөслими, 1999, б. 8].

Тәүлекнең төрле өлешләрен белдерә торган лексик берәмлекләрдән язма чыганакларда *таң, иртә, көндез, төш, кичә* сүзләре теркәлде: *Чыңгызны сөйсәңез, иртә берлән биш-алты ыругның йахшы кешеләре килеңез* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 75]. *Таң атканча Гали Кошчы хәзрәтләре хәрәм капусында торды* [Мөслими, 1999, б. 38]. *Чун иртә торыб, бу дөшне Һәрат падишаһына сөйләде* [шунда ук, б. 37]. *Андин соң Тумавыл Мәргән ул кичә чадыр корып кызны алып йатыр булдыр* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 70]. *Ул көймә таңла төш вакытында килер булганда, – тиде* [шунда ук, б. 70]. *Әмма Тикәлик суының кары йоласы улдыр кем көндез ташыб кабыгындин ишәйер, кичәсе юлына төшәр, – диде* [шунда ук, б. 75].

Вакыйга конкрет бер көн белән бәйләнмәгән, вакыт ягыннан конкретлаштырылмаган очракларда *кичләрдин бер кичә* сүзтезмәсе килә. Ул җөмләгә билгесезлек төсмере өсти: *Әлкыйсса, кичләрдин бер кичә хәзрәте Аксак Тимер үзе шымчы булыб Бараҗ халкының арасына иңде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 86].

*Кичә* һәм *көндез* сүзләре еш кына бер үк җөмләдә бергә кулланылып киләләр: *Ягъни заман див кичә һәм көндезнең килеб китдегенә диерләр, әмма микъдары хәрәкәте әфляк иләдер* [Мөслими, 1999, б. 8]. *Ул ташларә үтмәс балталары, пычаклары салсалар, өч кичә вә көндез анда тотсалар, үткен улыр, корычлы улыр* [шунда ук, б. 24].

Шунысын да искәртергә кирәк, XVII–XVIII гасыр язма истәлекләрендәге «вакыт» төшенчәсенә ия берәмлекләрнең кулланылышында борынгы чорлардан килә торган норма-традицияләрнең саклануы күренә. Мәсәлән, *вакыт, заман, мөддәт, һәнүз, даим, сәгать, ел* һ.б. кебек берәмлекләрнең, *ел, ай, көн* атамаларының Алтын Урда, Казан ханлыгы язма истәлекләрендә дә телгә алынуы мәгълүм [Кадирова, 2001; Нуриева, 2004].

Нәтиҗә ясап әйткәндә, XVII–XVIII гасырлар иске татар язма истәлекләрендә «вакыт» категориясе белән бәйле күпсанлы лексик берәмлекләрнең кулланылуы күзәтелә. Килеп чыгышлары ягыннан аларны ике төркемгә – төрки-татар һәм гарәп-фарсы асыллы сүзләргә аерырга мөмкин. Гасырлар дәвамында әлеге лексемаларның семантикасы төрле характердагы, аерым алганда, халыкның дини һәм рухи-мәдәни тормышына караган образлы мәгънә төсмерләре белән баетылган.

**Әдәбият**


*Беркутов В.Д.* Народный календарь и метрология булгаро-татар. Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. 95 с.

*Дәүләтшин Г.М.* Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 512 б.

Дәфтәре Чыңгызнамә // Мирастан биш сәхифә: XVII–XIX гасырлар әдәби-тарихи ядкярләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 37–96.

*Кадирова Э.Х.* Поэмы Мухаммедьяра «Тухфа-и мардан» и «Нур-и содур»: лексика. Казань: Дом печати, 2001. 232 с.

Мәүлә Колый поэмалары / төз. Р.Ф.Мәрданов. Казан: Милли китап, 2008. 88 б.

Мәүлә Колый шигырьләре // Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. Б. 487–503.

Мәҗмүгъ әл-хикәят // Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. Б. 503–522.

*Мөслими.* Тәварихы Болгария / басмага әзерләүче С. Гыйләҗетдинов. Казан: Иман, 1999. 100 б.

*Нуриева Ф.Ш.* Исторические и лингвистические условия формирования тюрко-татарского литературного языка золотоордынского периода. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2004. 376 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 510 б.

*Хайрутдинова Т.Х.* Заимствования, относящиеся к названиям времени // Актуальные вопросы татарского языка. Вып. 5. Казан, 2007. С. 127–134.

*Хайрутдинова Т.Х.* Слова, обозначающие время в диалектах сибирских татар // «Сулеймановские чтения – 2006»: Материалы IX Всероссийской научно-практической конференции (г. Тюмень, 18–19 мая 2006 г.). Тюмень: Экспресс, 2006. С. 134–135.

*Хәйретдинова Т.Х.* Татар теле диалектларында атнадагы көн исемнәре // Инсани фәннәр: эзләнү һәм табышлар. Казан: Фикер, 2004. Б. 92–98.

*Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1960. 322 с.



***Вәлиева Миләүшә Зәки кызы,***

*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 81ʹ373

***Р.К. Сәгъдиева***

# СҮЗЛӘР АРАСЫНДАГЫ ТӨГӘЛЛӘҮЛЕ МӨНӘСӘБӘТНЕ БЕЛДЕРӘ ТОРГАН ЧАРА БУЛАРАК СҮЗЛӘРНЕҢ ЯНӘШӘ ТОРУЛАРЫ

В образовании связи слов, выступающих в конкретизирующее отношение в татарском языке, как правило, участвует несколько средств связи вместе. Соседство слов, как средство связи, также осуществляет связь слов не один, а вместе с лексическим значением, интонацией, иногда порядком слов и с аффиксом притяжательности. В данной статье исследуется соседство слов как средство связи конкретизирующего отношения в татарском языке, выявлены смысловые оттенки и значения.

**Ключевые слова:** конкретизирующее отношение, соседство слов, средство связи, господствующее слово, зависимое слово.

In the formation of the connection of words, acting in a concretizing relation in the Tatar language, as a rule, several means of communication are involved together. The neighborhood of words, as a means of communication, also carries out the connection of words not one, but together with the lexical meaning, intonation, sometimes the order of words and with the affix of possessiveness. This article examines the neighborhood of words as a means of communication concretizing relations in the Tatar language, identifies semantic shades and meanings.

**Keywords:** concretizing relation, neighborhood of words, means of communication, dominant word, dependent word.

Сөйләмдә сүзләр бер берсенә бәйләнеп килә. Сүзләр бәйләнеше эчтәлектән һәм формадан гыйбарәт. Эчтәлек булып – алар арасындагы төрле мәгънә мөнәсәбәтләре, ә форма булып төшенчәләрне бәйли торган чаралар тора. Сөйләмне оештыра торган төп синтаксик берәмлек – җөмлә – сүзләрнең ияртүле юл белән бәйләнешкә керүеннән хасил була.

Ияртүле бәйләнеш – сөйләм оештыруда катнаша торган сүзләр арасындагы ияртүле мөнәсәбәтне махсус тел чаралары, ягъни төшенчәләрне бәйли торган чаралар белән белдерү ул. Иярүче белән ияртүче компонент арасындагы мөнәсәбәт мәгънәви мөнәсәбәт дип тә йөртелә. Шуңа нигезләнеп, ияртүле бәйләнешнең өч төрле мәгънә мөнәсәбәтен аерып чыгаралар: хәбәрлекле, ачыклаулы (төгәлләүле) һәм аныклаулы [Алпаров, 1945, б. 213; Зәкиев, 1958, б. 17; Сафиуллина, Ибраһимов, 1994, б. 11].

Ияртүле бәйләнешнең бер төре булган төгәлләүле мөнәсәбәт синтаксик күренешләрнең иң бае, иң күләмлесе, чөнки ул күптөрле чаралар ярдәмендә белдерелә [Сагдиева, 2000, с. 23]. Сөйләмдә әлеге бәйләүче чаралар, гадәттә, бер-берсе белән үрелеп бара. Мәсәлән,

*Һавада кошлар оча* җөмләсендә *һавада очу* берәмлеге тәгалләүле мөнәсәбәттә килә. Әлбәттә, анализ вакытында *һава* һәм *очу* сүзләре урын-вакыт килеше кушымчасы *-да* ярдәмендә бәйләнгәннәр диелә. Әмма әлеге ике төшенчә шул ук вакытта үзара лексик мәгънә ягыннан да бәйләнгән. Янәшә тору чарасы да башка чаралар, ягъни лексик мәгънә, сүз тәртибе, интонация белән бергә кулланыла. Еш кына тартым кушымчасы да өстәлә. Әлеге хезмәт исә янәшә тору чарасы хакында. Әлеге чара кайсы сүз төркемнәре арасында бәйләүче чара вазифасын башкара, бу очракта нинди мәгънә мөнәсәбәтләре хасил була? Мисаллар ярдәмендә шуңа күзәтү ясарбыз.

Янәшә тору чарасы ярдәмендә исем белән фигыль арасында тәгалләүле бәйләнеш оеша ала. Бу вакытта баш килештәге исем, һичшиксез, фигыль белән янәшә торырга тиеш. Әлеге очракта түбәндәге мәгънә мөнәсәбәтләре хасил була.

Иярүче исем ияртүче фигыль белән янәшә торганда, туры объектны белдерә: *Авылдашлар күктә* ***печән чаба****, ялт-йолт килә үткер чалгылары* (Л. Зөлкарнәй).

Иярүче исем хәрәкәт фигыле белән белдерелгән процессның үтәлү урынын: *Абау, әллә инде* ***су кергәндә*** *телен чуртан балык тешләп алган?* (Г. Гобәй) яисә вакытын ачыклый ала: ***Кич уңмаган иртә уңмас****, ди шул халык* (Т. Галиуллин).

Иярүче исем процесс үтәлүенең вакыт яки пространство ягыннан күләм-чамасын, дәрәҗәсен белдерә: *Шушы хәбәрне ишетүгә йөрәге бүтәнчә җилкенә башлаган Сөләйман карт Шәкүр солдатны* ***көн көтте****,* ***төн көтте****, [...], Шәкүрнең шәүләсе күренмәде* (А. Гыйләҗев). Бик еш кына исемнәр сан белән тәгалләндерелә (*биш ел уку, алты чакрым узу*), һәм нәтиҗәдә катлаулы тәгалләүле мөнәсәбәт хасил була.

Иярүче исем ияртүче хәрәкәт фигыле белән бирелгән эш-хәлнең коралын ачыклап килә: *Балалар таудан* ***чана шуалар****.* Ләкин татар телендә андый тезмәләр әкренләп идиоматик тезмәгә әйләнә баралар.

Сан сүз төркеме белән фигыль сүз төркеме янәшә килеп, тәгалләүле мөнәсәбәт хасил булганда, ияртүче фигыль белән белдерелгән эшнең саны, күләме конкретлаштырыла: ***Бер күрде****, аннары ничектер бик табигый рәвештә танышып та киттеләр, сөйләшә, көлешә, уйный-шаяра да башладылар* (Ә. Еники).

Сөйләмдә еш кына рәвеш белән фигыль арасындагы тәгалләүле мөнәсәбәтне дә янәшә тору чарасы белдерә. Бу очракта иярүче рәвеш ияртүче компонент аша белдерелгән процессның үтәлү ысулын ачыклап килә ала: *Зарифуллин яланбаш тора иде, нинди дер* ***аңсыз хәрәкәт ясап****, башыннан бүрек әзләде* (М. Мәһдиев).

Күләм-чама рәвеше фигыль белән янәшә килеп, тәгалләүле мөнәсәбәт барлыкка килгәндә, эшнең күләм-чамасы тәгаенләнә: ***Озак та үтми****, ул үзенең өстенлеген күрсәтүдә шул дәрәҗәгә барып җитте ки, миңа хәтта әти-әнием алдында шелтә ясый торган булды* (Ә. Еники).

Иярүче вакыт рәвеше эш-хәрәкәтнең үтәлү вакытын төгәлләндереп килә ала: ***Иртә торып, соң ятарга*** *өйрәнгән, иркә шәһәр тормышы белән бозылмаган авыл егетенә тәртипкә күнегү әллә ни кыен булмады* (Т. Галиуллин).

Урын рәвеше дә фигыль белән янәшә килә, һәм бу очракта процессның үтәлү урыны ачыклана: *Сүзләр якын иде, күңелләр **ерак булды*** (Ш. Галиев).

Кабатлауны белдерә торган рәвешләр (*тагын, кабат, яңадан*) фигыльләр белән янәшә килеп, төгәлләүле мөнәсәбәт хасил итәләр һәм кайчандыр башкарылган процессның янә кабатлануын аңлаталар: *Алай гына да түгел, мин аның **яңадан кабынуын** тели идем, киләчәгем хакына, әти-әнием хакына ихлас күңелдән тели идем* (Ә. Еники).

Сәбәп һәм максат рәвешләре дә фигыль сүз төркеме белән янәшә килә һәм төгәлләүле мөнәсәбәт хасил итә. Нәтиҗәдә, процесс үтәлүнең максаты яисә сәбәбе тәгаенләнә: *«Кемне, нәрсәне?» – дигән булдым мин, **юри аңламаган** булып* (Ә. Еники).

Бернинди кушымчасыз, бәйлек һәм бәйлек сүзләрдән башка, ә янәшә тору чарасы ярдәмендә генә исемнәр арасында да төгәлләүле мөнәсәбәт барлыкка килә, һәм түбәндәге мәгънәләр ачыклана.

Теге яки бу әйбер үзе ясалган материалы аша төгәлләндерелә: *Манарасы кыйшайган мәчетнең **калай гөмбәзендә, җиз аенда** кояш уйный, кояшлы урамнар, салам түбәле, кыйшык-мыйшык ызбалар, ара-тирә калай яки агач түбәле төзек йортлар гамьсез тынлыкта рәхәт черем итәләр кебек* (Г. Гобәй).

Иярүче компонент иярткүче исем белән бирелгән затның һөнәрен белдерә, ягъни зат үзенең профессиясе аша ачыклана: *Мин колхозның идарәсенә – авылдан сөрелгән **кибетче Сәгъдиләр** өенең урам башына барып кердем* (Ә. Еники).

Кайбер очракларда исемнәр арасында төгәлләүле мөнәсәбәт хасил булганда, иярүче исем үзе сан аша ачыкланып килергә мөмкин (*бер пот он, ике чиләк су, биш чакрым юл*), һәм, нәтиҗәдә, катлаулы сүзтезмә оеша: *Бәдретдин үзенең сандыгыннан **бер-ике уч шикәр** алып, шушы ашъяулык уртасына салды* (Ә. Еники).

Иярткүче компонент белән бирелгән әйбер яки зат иярүче исем аша белдерелгән әйбергә яки затка охшатыла, йә аның белән чагыштырыла. Әгәр иярүче сүз чагыштыруның объектын белдерсә, иярткүче исем чагыштыруның субъектын атый. Бу төр төгәлләүле мөнәсәбәт сөйләмгә сәнгатьлелек өсти. Әлеге очракта да төрле мәгънә төсмерләре чагылыш таба: а) затлар яисә әйберләр билгеләре, характерлары ягыннан охшатыла: *Мин югында **пәри егетләр** урламасын үзеңне* (М. Мәһдиев); ә) әйберләр үзара күләмнәре, саннары ягыннан чагыштырыла: *Гомер буе язып, **тау кульязма** җыйган һәвәскәрләр...* (Т. Галиуллин); б) әйберләр үзләренең формалары аша тәңгәлләштерелә: *Ап-ак булып чуарланып тора – игенченең **борчак-борчак тирләре** әрәм тәгәрәп ята* (Ш. Галиев). Бу очракта янәшә тору чарасы белән бергә кабатлану чарасы да файдаланыла.

Янәшә тору чарасы – сыйфат белән исем арасындагы төгәлләүле мөнәсәбәтне белдерә торган чара да. Бу очракта да ияртүче компонент ияртүче компонентны төрле яктан ачыклап килә: а) ияртүче исем белән бирелгән күренешнең, әйбернең төсен белдерә: ***Зәңгәр күктә ак болытлар** туктап калган* (Ш. Галиев); ә) әйбернең күләм-чамасын ачыклый: ***Биек яр** буйларында агач кәүсәсендәге еллык боҗрасыдай түшәлгән гасырлар катламын киселештә күрергә була* (Ш. Галиев); б) күренешне, әйберне образы, формасы ягыннан төгәлләп килә: *Куаклык артындагы **түгәрәк күл** дә уянып килә иде* (Г. Гобәй); в) ризыкның тәмен белдерә: *Әни базардан **әче алма** алып кайтты. Илгиз авылда **төче катык** ашарга ярата;* г) затның эчке үзенчәлеген тәгаенләп килә: *Исән йөртмәм мин сине дөнья йөзендә, **тәкәббер кыз*** (Г. Гобәй). *Кичә вокзал янында йөгереп йөргән **шук, наян егетме** соң бу?* (А. Гыйләҗев); д) әйбернең төрле үзенчәлеген, күп очракта эчке сыйфатын конкретлаштыра: ***Саф һавада якты йолдызлар** булып йолдызлар җемелди* (Ш. Галиев). ***Салкын күзләреңнән кайнар тамчылар** тамар әле!* (Ш. Галиев).

Сан белән исем янәшә килгәндә дә, алар арасында төгәлләүле мөнәсәбәт хасил була. Төп сан ияртүче компонентролендә килгәндә, ияртүче исем аша күрсәтелгән әйбернең төгәл санын тәгаенли: *Яшендәй китереп суккан бу хәбәрдән соң, **бер көн** узды, **ике көн** узды, **өч көн** дә узды шикелле...* (Ш. Галиев).

*Бер* саны исем белән төгәлләүле мөнәсәбәткә кергәндә, югарыда әйтелгәнчә, әйбернең яисә затның санын, яки аларның билгесез булуын белдерә: *Гөлшаһидә, күңелендә үтә **бер җиңеллек** һәм сафлык тоеп, урыныннан җәһәт торды, халатын киде...* (Г. Әпсәләмов). Әлеге мәгънәне аңлату өчен, *бер* саны кабатланып та килергә мөмкин: *«**Бер-бер шатлыгың** бармы әллә, кызым?» – дип сорады* (Г. Әпсәләмов).

Тәртип саны белән исем арасындагы төгәлләүле мөнәсәбәт тә янәшә тору чарасы ярдәмендә хасил була ала. Бу очракта әйбернең яисә затның тәртибе тәгаенләнә: *Җирдә тереклек яралганда, иңенә канат чыкканчы, **беренче кошлар** да биектән төшеп, бәрелеп харап булгандыр...* (Ш. Галиев). *Икенче* саны исә, үзенең беренчел мәгънәсен югалтып, ияртүче исем белән белдерелгән әйберне яки затны ассызыклау өчен хезмәт итә. Әлеге очракта ул *башка*, *бүтән* сүзләре белән алмаштырылырга мөмкин: *Ул **икенче егет** дигәнем староста малае икән* (Ф. Хөсни).

Әгәр ияртүче компонент парлы саннан торса, ул ияртүче исем белән бирелгән әйбернең яки затның якынча санын конкретлаштыра: *Аның тирәсендә җәңгәчәй һәм тагын **өч-дүрт кыз** чуала* (Ә. Еники).

Бүлем саны, ияртүче копонент булып килгәндә, ияртүче исем белән бирелгән әйбернең яисә затның бертигез сандагы төркемнәргә бүленүен ачыклый: *Сез миңа **бишәр сүз** язызыз* (М. Мәһдиев).

*Берәр* саны исә билгесезлек мәгънәсен белдерә: *Ниятем: болай җае туры килсә, нинди дә булса район учреждениеләренең берсенә*

*секретарьмы, хисапчымы булып эшкә урнашу; алай барып чыкмаса, ронога кереп, **берәр мәктәпкә** укытучы итеп җибәрүләрен сорау* (Ф. Хөсни).

Кайбер хәбәрлек сүзләр исем белән янәшә килсәләр, шулай ук төгәлләүле мөнәсәбәт хасил була: ***Кирәк кешеләр*** *килеп беттеме? Юк* хәбәрлек сүзе, исемгә ияреп, ияртүче исем белән бирелгән әйбернең яисә затның сөйләүче өчен бернинди дә әһәмияткә ия булмаганлыгын күрсәтә: *Ялгыз хатын-кызга, **юк сүзен** бар итеп, сагыз кебекябышырга йөргән ир-атларны беренче генә очратуы түгел ләбаса* (М. Мәһдиев).

Янәшә тору чарасы ярдәмендә рәвеш белән сыйфат сүз төркемнәре арасында да төгәлләүле мөнәсәбәт барлыкка килергә мөмкин. Күп очракта ияртүче компонент булып күләм-чама рәвеше килә һәм ул ияртүче компонент белән белдерелгән билгенең күләм-дәрәҗәсен тәгаенли: *Оппонентлар да коры рәсмилеккә **беркадәр җылы** хәерхаһлык кушып, күбрәк мактап, азрак тәнкыйтьләп, кыскасы, бөтен шартын китереп, диссертация турында үз фикерләрен әйттеләр* (Ә. Еники). *Өебез май кебек җылы, тик **бераз караңгырак*** (Ә. Еники).

Рәвеш белән икенче бер рәвеш тә үзара янәшә торып, сөйләмдә төгәлләүле мөнәсәбәт хасил була ала. Күләм-чама, саф, охшату-чагыштыру рәвешләре икенче бер рәвеш белән янәшә торганда, ияртүче компонент белән күрсәтелгән билгенең күләме тәгаенләнә: *Тукран **шулкадәр тиз** вә каты такылдатты ки, кыз түзмәде, башын күтәреп карады* (М. Хәбибуллин).

Әгәр янәшә тору чарасы ярдәмендә вакыт рәвешләре арасында төгәлләүле мөнәсәбәт хасил була икән, бер вакыт ияртүче компонент белән белдерелгән вакыт аша төгәлләндерелә: ***Кичә кичен*** *генә мунча кергәнне сылтау итеп, бүген битен дә юмаган унбиш-уналты яшьлек малайлар училище коридорында колхоз тузанын кагалар* (М. Мәһдиев).

Кайбер очракта төгәлләүле мөнәсәбәтне хасил итүдә янәшә тору чарасына ярдәмгә *-ы/-е*, *-сы/-се* тартым кушымчасы да өстәлеп килә. Бу күп очракта исемнәр арасындагы ияртүле бәйләнешкә хас. Исем белән исем янәшә килеп, ияртүче компонент тартым кушымчасын алганда, түбәндәге мәгънә төсмерләре чагылыш таба.

Ияртүче исем белән белдерелгән әйбер яки зат ияртүче исем аша бирелгән билгеле әйбергә яисә затка карый. Бу очракта, иярүче компонент булып, иялек килешеннән башка да билгеле булган исемнәр кулланыла, ягъни ялгызлык исемнәр, уникаль әйбер яки күренеш исем-атамалары һәм үзен төгәлләп килә торган сүзләре булган исемнәр алына: ***Кояш нурлары*** *булып, күзләреңә төшәрмен, яфраклар булып муеныңа сарылырмын, җилләр булып гәүдәңә уралырмын* (Ш. Галиев).

Әгәр иярүче компонент булып уртаклык исемнәр килсә, бу төгәлләүле бәйләнештә конкрет әйбернең билгесез әйбергә мөнәсәбәте

чагыла: *Бик юка туралган, **борчак оны** катыш **арыш онынннан** иләмичә пешерелгән, уалып торган ипи килде* (А. Гыйләҗев).

Иярүче компонент тартым кушымчасын алып, иярүче белән ияртүче исемнәр янәшә торган очракта, иярүче сүз ияртүче исемне милләте ягыннан тәгаенләп килә ала: *Җан диләр, йөрәк диләр, **татар халкы** шулар уртасына Күңел дигән серле дәрья урнаштырган* (А. Гыйләҗев). *Әркәшә Пермяков – **рус малае*** (М. Мәһдиев).

Ияртүче исем белән билдерелгән әйбер яки зат үзенең атамасы аша төгәлләндерелә: *Безнең күңелләргә Бетховен, Шаляпин, Григлар да иркен керә, океан-диңгезләр, елга-дәрьялар, **Кавказ-Кырым таулары** да сыя, алар да синеке, син – кеше, синең күңелең күпне тели, күпне үз итә ала* (А. Гыйләҗев).

Ияртүче сүз – ыруглык, ә иярүче исем төр төшенчәсен белдергәндә, ыруглык төшенчәсе төр аша ачыклана: *Әрсез күгәрченнәр кыектан-кыекка пыр-пыр очты, **шомырт агачларында** тирбәлгән ач күз чыпчыклар чыркылдашты...* (А. Гыйләҗев).

Ияртүче компонент – өлешне, ә иярүче исем бөтенне белдергәндә, берничә мәгънә төсмерен аерып чыгарып була: а) нинди дә булса әйбергә (бөтенгә) аның кайсы да булса өлеше карый: *Дилә, туктальп, озынча, ябык бармаклары белән Идриснең **күлмәк якасын** кайтарып карады* (А. Гыйләҗев); ә) нинди дә булса бөтенгә күләме яки саны ягыннан кимрәк булган шундый ук төрдәге бөтен туры килә: *Һәм Хәлил өчен бу мәхәббәт диңгез төбеннән табылган саф **энҗе бөртеге** кебек гаҗәеп бер байлык иде, ак итә, пакь итә, яктылыкка илтә торган гомерлек бәхет иде* (Ә. Еники); б) нинди дә булса урынга аның өлеше карый: ***Ирен читләрендә** көнләшү сызыклары үткен пәке булып сызылып тора* (Ш. Галиев).

Шулай итеп, мисаллардан күренгәнчә, һәр очракта да өлеш бөтен аша төгәлләндерелә. Бу өлеш шул бөтен составына кергән.

Иярүче компонент ияртүче исем белән бирелгән әйбернең, күренешнең барлыкка килүендә максат булып торган әйберне белдерә, ягъни предметның ни өчен билгеләнүен аңлата, яисә әйбернең, затның урнашкан, барлыкка килгән урынын ачыклый: *Табигый ки, Бик-тимер **балалар йортында** үсә, Суворов мәктәбен тәмамлагач, Казанда ук танк училищесында белем ала* (Т. Галиуллин). *Кулына ни эләксә – күмер кисәгеме, акбурмы, чыбык кисәгеме – стенага, **мич акшарына**, **урам комына**, **яр балчыгына**, ак кәгазьгә иң әүвәл кеше сурәтен сызгалый* (А. Гыйләҗев). *Шул көннәрдә Яңа елга багышланган **стена газетасы** чыкты* (М. Хәсәнов).

Әлеге мисаллардан күренгәнчә, урын мәгънәсе иярүче компонент аша белдерелә. Кайчак киресе дә була: урынны ияртүче компонент атый. Иярүче сүз бу очракта шул урын белән бәйле булган әйберне яисә затны күрсәтә: ***Картлар дөньясы** аерым яшәсә, моңсу була иде* (Ш. Галиев).

Ияртүче компонент вакытны белдерә, һәм ул иярүче исем аша төгәлләндерелә. Вакыт еш кына вакыт аша тәгаенләнә: ***Апрель киче***

(Ә. Еники). Вакыт иярүче сүз аша гына да белдерелә ала: ***Яз исе*** *– сафлык исе, сәбәпсез сөенеч, рәхәт үзгәрешне сиздергән хуш дулкын күңелгә кагылып үтте* (Ш. Галиев).

Янәшә тору чарасы һәм тартым кушымчасы ярдәмендә исем сүз төркемнәре үзара төгәлләүле мөнәсәбәткә кергән очракта, иярүче компонент ияртүче исем белән бирелгән әйбернең яки күренешнең составында булган әйберне белдерә: ***Каз бәлеше*** *була,* ***кабак бәлеше,*** *каздан* ***баш-аяк бәлеше*** *була* (М. Мәһдиев). *Коридор буйлап электр тогы узгандай булды, һәм без, туң миләребезне кыймылдатып өлгергәнче,* ***тузан болыты*** *эченнән ялтыравыклы күзлек пыялалары күренде* (М. Мәһдиев).

Исемнәр үзара янәшә килеп һәм ияртүчесе тартым кушымчасын алган очракта, объект белән башкаручының мөнәсәбәте дә чагыла ала. Бу вакытта объект башкаручы ягыннан төгәлләндерелә: *Тәнзилә апа үзенең нечкә генә тавышы белән Гарданов абыйны бүлдерде: «Бүреләр оясы икән», – диде* (Н. Дәүли), яисә башкаручы объект ягыннан тәгаенләнә: ***Пролетариат дошманнары*** *безгә дә, сезгә дә явызлык эшләргә чамалыйлар* (Н. Дәүли).

Исем икенче бер тартым кушымчалы исем белән янәшә килеп, төгәлләүле мөнәсәбәт хасил булган очракта, иярүче исем ияртүче сүз белән бирелгән процессны коралы яисә туры объекты аша ачыклый: ***Гражданнар сугышы*** *вакытында Колчак баскынчыкларымы, кызыл зәхмәтләрме, хәзер ул хәтлесен берәү дә әйтә алмый, әтисе мулланы, күңелсез булмасын өчен абыстайны да атып китәләр* (Т. Галиуллин).

Иярүче компонент белән белдерелгән әйбер ияртүче исем аша күрсәтелгән әйбергә охшатылган булырга мөмкин: *Нәни очкынны дөрләтеп,* ***мәхәббәт уты*** *кабызмакчылар* (Ш. Галиев). *Юк, энем,* ***йөрәк ялкынын*** *кул белән капшап кына сизеп булмый, маташма* (Н. Дәүли).

Әдәби телдә һәм сөйләмдә исемнәрне охшату-чагыштыру яки сүзне көчерелмә мәгънәдә куллану нигезендә дә төгәлләүле мөнәсәбәт хасил була: *Кеше гомере үтә кыска,* ***саескан гомерен*** *биргән дөнья адәм баласына* (А. Гыйләҗев).

Исем фигыль дә тартым кушымчасын алган исем белән янәшә торганда, төгәлләүле мөнәсәбәт барлыкка килә. Бу очракта исем белән белдерелгән әйбер яки зат үзенең процессы ярдәмендә төгәлләндерелә. Анда әйбер, зат йә башкаручы, йә булмаса объект булып килә: *Ләкин аңарда* ***яшәү теләге*** *үлемнән көчлерәк була* (Г. Гобәй). *Әхәтнең кайчандыр әйткән* ***кисәтү сүзләре*** *хәтергә төште* (А. Гыйләҗев).

Югарыдагы мисаллардан күренгәнчә, янәшә тору чарасы сүзләрнең лексик мәгънәсе һәм интонация ярдәмендә исем белән фигыль, сан белән фигыль, рәвеш белән фигыль, исем белән исем, сыйфат белән исем, рәвеш белән исем, хәбәрлек сүз белән исем, рәвеш белән сыйфат һәм рәвеш белән икенче бер рәвеш арасында төгәлләүле

мөнәсәбәт хасил итә ала икән. Ияртүче сүзгә тартым кушымчасы өстәлсә, төгәлләүле мөнәсәбәт ике исем сүз төркеме һәм исем фигыль белән исем арасында барлыкка килә.

**Әдәбият һәм чыганаклар**

*Алпаров Г.* Сайланма хезмәтләр: Грамматикасы һәм гомуми тел белеме мәсьәләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1945. 330 б.

*Әпсәләмов Г.* Ак чәчәкләр: Роман. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 510 б.

*Галиев Ш.* Илһамым-мәхәббәтем: лирик язмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 408 б.

*Галиуллин Т.* Дәгъва: Хикәяләр, публицистика, әдәби тәнкыйть. Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. 256 б.

*Гобәй Г.* Маякчы кызы: Повесть. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 191 б.

*Гыйләҗев А.* Әсәрләр: дүрт томда. 4 т.: Роман. Повесть. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 400 б.

*Дәүли Н.* Яшәү белән үлем арасында: Повесть. Җимерелгән бастион: Роман. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 446 б.

*Еники Ә.* Җиз кыңгырау: Хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. 224 б.

*Зәкиев М.З.* Хәзерге татар әдәби теле: Синтаксис. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1958. 244 б.

*Зөлкарнәев Л.* Кар өстендә алмалар: Шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 79 б.

*Мәһдиев М.* Сайланма әсәрләр: 3 томда. 1 т.: Повестьлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 534 б.

*Сафиуллина Ф.С., Ибраһимов С.М.* Татар теле: Синтаксис. Казан: Мәгариф, 1994. 176 б.

*Сагдиева Р.К.* Аффиксы как средства выражения кокретизирующих отношений в татарском языке: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2000. 164 с.

*Хәбибуллин М.* Илчегә үлем юк: Роман. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 384 б.

*Хәсәнов М.* Саф җилләр: Роман-дилогия. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 423 б.

*Хөсни Ф.* Утызынчы ел: Роман. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 391 б.

***Сәгъдиева Рамилә Камил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты*
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты*
*Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбенең*
*татар теле белеме кафедрасы доценты*

УДК 81′28

***О.Р. Хисамов,***
***А.Я. Хөсәинова***

# ТӨМӘН ӨЛКӘСЕ ТӨМӘН РАЙОНЫ ГЕОГРАФИК ТЕРМИННАРЫНЫҢ ФОНЕТИК ҺӘМ ЛЕКСИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

В данной статье рассматриваются ядерные и периферийные фонетические и лексические особенности географических терминов в тюменском говоре на территории Тюменского района. Приводятся примеры соответствий согласных и другие фонетические явления (чередование, оглушение, озвончение, выпадение, вставка согласных и др.). Прослеживается изменение семантики (сужение или расширение) диалектизмов, как компонентов детерминативов. Выявляются ядерные элементы татарской диасистемы в области топонимии, также приводится сравнительный анализ с другими говорами татарского языка и другими тюркскими языками.

**Ключевые слова:** диалекты, фонетические диалектизмы, семантический диалектизм, географический термин, тюменский говор, соответствия согласных, восточный диалект.

This article discusses the nuclear and peripheral phonetic and lexical features of geographical terms in the Tyumen dialect on the territory of the Tyumen region. Examples of consonant correspondences and other phonetic phenomena (alternation, deafening, ringing, falling out, insertion of consonants, etc.) are given.A change in the semantics (narrowing or expansion) of dialectisms as components of determinants is traced. The nuclear elements of the Tatar diasystem are identified, and a comparative analysis with other dialects of the Tatar language and other Turkic languages is also given.

**Keywords:** dialects, phonetic dialectisms, semantic dialectism, geographical term, Tyumen dialect, consonant correspondence, eastern dialect.

Теге яки бу тел составындагы билгеле бер диалектның һәм ареалның тел үзенчәлекләрен, тел яки диалектның сүз һәм аваз составын бербөтен система буларак тулысынча өйрәнүгә ярдәм итә торган ареаль фактик материалны фәнни әйләнешкә кертү тикшеренү эшенең актуальлеген билгели.

Географик терминнар атамалар ясауда мөһим роль уйный: этимологик тикшеренүләрдә төп функцияне үти; топонимик атамаларның үзенчәлекләрен билгели. Шуңа күрә топонимик тикшеренүләр, иң беренче чиратта, җирле географик терминнарны җыю һәм системага салудан башланырга тиеш.

Географик терминнар – билгеле бер географик чынбарлыкны белдерә торган сүзләр. Алар таралуы һәм функцияләре ягыннан ике төргә бүленәләр: ыруглык һәм төр терминнарына [Мурзаев, 1970, с. 18].

Төрле территорияләрдә киң таралган, нигездә, гомумтөрки катламга караган атамалар ыруглык терминнарына керә. Мәсәлән, *елга, күл, саз* һ. б. Төр терминнары бер үк географик объектларның (мәсәлән, *күлнең*) төрле үзенчәлекләрен белдерә. Еш кына әлеге категориягә диалекталь апеллятив лексика (мәсәлән, *чүгәт* «камыш куакларында кечкенә күл», *тоба* «текә ярлы тирән булмаган күл», һ. б.) керә.

География терминнарның һәм топонимнарның аермасы шунда: терминнар бертөрле географик предметлар классын атыйлар, ә топонимнар аерым предметларны номинациялиләр, беренчеләре шулай ук төшенчәләрне белдерә, ә икенчеләре аларны белдерми. Башка сүзләр белән әйткәндә, аерма географик терминнарның – уртаклык атамалары, ә топонимнарның ялгызлык исемнәре булуына кайтып кала [Карпенко, 1970, с. 36].

Әлеге тикшеренүнең теоретик нигезе булып М.З. Зәкиев [Татар лексикологиясе, 2017], Д.Г. Тумашева [Тумашева, 1977], Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова, Т.Х. Хәйретдинова, З.Р. Садыйкова [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 2009; Татар халык сөйләшләре, 2008] кебек күренекле татар диалектологларының фәнни-теоретик нигезләмәләре һәм Г.Ф. Саттаров, Ф.Г. Гарипова [Гарипова, 2017], Э.М. Мурзаев [Мурзаев, 1970], Ю.А. Карпенко [Карпенко, 1970] һ. б. топонимчы галимнәрнең хезмәтләре тора.

Әлеге мәкалә Төмән өлкәсе Төмән районы географик терминнарының фонетик һәм лексик үзенчәлекләрен тикшерүгә багышлана. Ул ТР Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 2021 елгы комплекслы экспедициясе вакытында Төмән өлкәсенең Төмән районы татар авылларында (Ембай, Янтык, Чикча, Муллаши, Индрәй) җыелган кыр материалларына нигезләнеп язылды, шулай ук татар теленең диалекталь сүзлекләрендәге материаллар да файдаланылды.

Төмән өлкәсе Төмән районы территориясендә татар теленең көнчыгыш диалектына керүче төмән сөйләше таралган. Географик терминнарның төп өлеше татар диасистемасының төш элементларын тәшкил итә, ягъни барлык диалектлар һәм татар әдәби теле өчен уртак булып тора. Алга таба тар локаль яки таралыш ареалы чикләнгән терминнарны тикшерәбез.

*Фонетик үзенчәлекләр*

Д.Г. Тумашева билгеләвенчә, цылаштыру тубыл-иртыш диалектының төп аеручы үзенчәлеге булып тора, ягъни әдәби телдәге өрелмәле [ч] авазы урынына йомык [ц] әйтелә [Тумашева, 1977, с. 53]. [ц] – тел алды, аффрикатив тартык, сүздә барлык позицияләрдә дә очрый: сүз башында: *цаң* – чәч, *цымылтык* – пәрдә, *цай* – чәй; сүз уртасында: *аңыу* – үпкә, *аңкыц* – ачкыч, *цыңкан* – тычкан; сүз ахырында: *пурыц* – бурыч, *калац* – калач, *аң* – ач.

Төмән сөйләшендә татар теленең көнчыгыш диалектына хас булган цылаштыру системалылыгын берникадәр югалта. Шуның белән бергә биредә [ч] һәм [ц] авазларының параллель кулланылу очракла-

ры да күзәтелә. Мәсәлән, *Манчыл, Манцыл, Малцы, Манжел* (авыл исеме), *пецәнлек* – печәнлек; *цийәлек* – сазлык җиләкләре үскән урын (информантларда *көртмәлек*).

Географик терминнарда да кайбер аваз үзгәрешләре күзәтелә.

1. Эпитеза – сүзнең ахырында янәшә ике тартык булса, сузык аваз өстәлү күренеше. Мәсәлән*, қыра* сүзе «яшелчә утыртылган кыр» мәгънәсенә ия (тат. әдәби *кыр*), *прорарба* сүзе (русча *прорубь*) – «бәке» төшенчәсен белдерә. Төмән районында *қыра* лексемасы «иген чәчелгән кыр», ә эчкен сөйләшендә, тубыл-иртыш һәм бараба диалектларында «кыр, басу» мәгънәсендә кулланыла. Тевриз сөйләшендә *қыра* сүзе «болын» мәгънәсен, ә саз ягы сөйләшендә «бәрәңге кыры, бәрәңге кишәрлеге» мәгънәсен белдерә. Мәсәлән: *Инәкәм белән қырага йөрдек* (төмән). *Ашлары қороп қалты қырасы белә* (тевриз).

2. Эпентеза (грекча epenthesis – «вставка») – сүзнең башында ике тартык янәшә килгәндә, алар арасына сузык өстәлү процессы. Мәсәлән, *цоңқор* сүзе төмән сөйләшендә «чокыр» мәгънәсен белдерә. Чагыштырыгыз: төмән сөйләшендә *цоңғыр* «чоңгыл» мәгънәсендә. Төмән сөйләшендә *цоңқор* сүзе тагын түбәндәге мәгънәләргә ия: а) «тирән»: *Шәкәцә (касә) була цоңқор гына*; ә) «җилкә чокыры» (анатомик термин): *Пы қыйра (бу ялкау), цоңқоро сур тейләр пестә* [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 2009, б. 714].

*Пыруд* сүзе төмән сөйләшендә «буа» мәгънәсендә йөри. Әдәби *буа* сүзенең төрле фонетик вариантларыннан тыш, татар сөйләшләрендә *пруд* алынма сүзенең түбәндәге вариантлары кулланыла: *борот* (Урал ягы сөйләшләре), *пырт* (нократ), *пурт, прыт, порт, пырут* (темников), *пырыт* һ. б. Шулай ук себер татарлары диалектларында *туан* варианты билгеле.

3. Төмән сөйләшендә авазлар чиратлашу күренеше дә урын ала. Мәсәлән, әдәби телдәге арткы рәт, югары күтәрелешле [у] авазына арткы рәт, урта күтәрелешле [о] авазы туры килә. Мәсәлән: *отрау* – утрау; отраwцық – кечкенә утрау, утраучык (сазлыкта).

4. Дифтонгларның әйтелешендә дә үзенчәлекләр бар. Мәсәлән, ачык иҗек оештыра торган [у], [ү] авазларына, барлык көнчыгыш диалектларга һәм касыйм, Урал төбәге сөйләшләренә хас булганча, [ыw]/[еw] дифтонгы тәңгәл килә: *тыwған* – туган, *сыw* – су, һ. б. Ачык иҗектә яки сүз азагында килгән [и] авазына шактый системалы рәвештә [ей] дифтонгы тәңгәлләшә: *цейә* – чия, әд. җиләк, *пейек* – биек һ. б.

Шулай ук [о] сузыгы кайбер алынмаларда [уй] дифтонгы белән алмашына. Мәсәлән, төмән сөйләшендә *уймат* (русчадан – омут) сүзе «түбән җир, иңкү җир» дигәнне аңлата. *Уймат йерләртә су китми утыра қый* [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 2009, б. 678]. Чикча авылы сөйләшендә *уймат* сүзенең «упкын» мәгънәсе бар.

5. Авазлар саңгыраулашу: тартыкларны әйткәндә артикуляциянең көчәюе һәм тавышның кимүе нәтиҗәсендә сүз азагында яки саңгырау тартыклар алдында аерым очракларда кайбер яңгырау тартыклар

саңгырау парлары белән чиратлаша. Түмән сөйләшендә кайбер сүзләрдә ирен-ирен, йомык, яңгырау [б] авазына шартлаулы саңгырау [п] тартыгы туры килә. Мәсәлән, *паш* – баш, берәр географик объектның башланган урыны, *пуй* – янәшә (тат. әдәби буй), *сиарат* – татар зираты.

6. Авазлар яңгыраулашу: саңгырау тартыклар нинди дә булса бер позициядә яңгырау парлары белән алмашына. Түмән сөйләшендә тел арты, саңгырау тартык [к]  яңгырау, тел арты, йомык [г] авазы белән белән алмашыну очраклары күзәтелә. Мәсәлән, *гол* – күл.

Түмән сөйләшендә әдәби телдә сүз башындагы шаулы, ярык [җ] тартыгына яңгырау [й] сонанты туры килә: *йиләклек* – җиләклек. Шул ук вакытта кайбер сүзләрдә башлангыч әдәби [й] да саклана: *йаӄ* – як. Алынмаларда [х] спиранты [ғ]/[г]. авазларына туры килә. Мәсәлән: *пағытный җир* (русчадан – пахотный) – «сөрүле җир».

*Лексик үзенчәлекләр*

Тикшерелгән территориядә очрый торган географик терминнарда семантик, ягъни әдәби эквивалентлардан мәгънәләре белән аерылып торган омоним диалектизмнар еш кулланыла. Кайбер мисалларга аерым тукталыйк.

*Иген* сүзе түмән сөйләшендә «иген чәчә торган басу» һәм «төп утардан читтә урнашкан бакча» дигән мәгънәләргә ия (тат. әдәби – иген, «хлеба»). Чагыштырыгыз: *иген* пермь сөйләшендә «ашлык басулары» мәгънәсендә. *Арыш, бодай, арпа, гәрәчүхә – һәммәсе безнең игендә үсәләр*. Әстерхан сөйләшендә – «яшелчә» мәгънәсендә [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 2009, б. 205].

Түмән сөйләшендә *тал* сүзе «таллык» мәгънәсендә кулланыла. Тархан, хвалын сөйләшләрендә *тал* лексемасы «агач» мәгънәсенә ия: *Безнең баӄчада таллар күп* (тархан). Тара сөйләшендә әлеге лексема «тәндә – йон бөртеге, мамык бөртеге, төк» мәгънәсендә йөри [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 2009, б. 603].

Түмән сөйләшенең географик терминнарында еш кына «янәшә, янәшәдә, урыны янәшәдә» мәгънәсендә *ӄабаты* бәйлеге кулланыла – (тат. әдәби *кабат* – «яңадан»). *Ӄабаты* сүзе эчкен сөйләшендә «чит, кырый, як, ян-як» мәгънәсендә йөри: *Уң йаӄ ӄабатына ӄуйа торғаныйы йозаӄны*. Эчкен сөйләшендә һәм тубыл-иртыш диалектында – «ян, кат» төшенчәсен белдерә: *Wагун ӄабатына бардыӄ* (эчкен). *Өй ӄабатта* (тубыл). *Сийарәт ӄабатынта йәм-йәшел чыршы үсә. Ӄыс ман йегет ӄабатынта нүгәр (кияү егете) булады. Ӄабатымта утыраты* (тевриз). Тубыл-иртыш диалектында әлеге сүз «янәшә» мәгънәсендә кулланыла: *Икәү ӄабат утыратылар, мулла сурайды, эриса булып алдыңма?* (тевриз). Тубыл һәм тевриз сөйләшләрендә «кырый, чит» төшенчәсен аңлата: *Матур, ӄабатларында тәңкәләре булады* (тубыл). Саз ягы һәм тубыл сөйләшләрендә *ӄабаты* сүзе «чит»мәгънәсендә йөри: *Эшләнгәнне ӄабаттан ӄарап йөрү килешмәйте* [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 2009, б. 372]. Чагыштырыгыз: казакъ, каракалпак, кыргыз телләрендә *ӄабат* сүзе «кат, ярус» мәгъ-

нәсен, төрекмән телендә *габат* «якында, тирәли» мәгънәсен белдерә, үзбәк телендә *қабат* «икенче кат кием», чагатай телендә «икенче катлам» мәгънәләрендә кулланыла.

*Сырт* төмән сөйләшендә «нәрсәнең дә булса кыры, чите» дигән мәгънәгә ия (тат. әдәби арка, арка сырты (хайваннарда); тау сырты). Чагыштырыгыз: каргалы, мәләкәс һәм касыйм сөйләшләрендә *сырт* сүзе «берәр нәрсәнең арткы ягы»н аңлата: *Магазинны узып китеп, сырттарақ* (каргалы). *Бездә йәшләр зийаратка кереш йук, сыртта гына кала* (мәләкәс). Көнбатыш диалектта ул «өй артындагы урын, өй арты» мәгънәсендә кулланыла [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 2009, б. 595]. Башкорт телендә *һырт*, үзбәк телендә *сиртъ* «сырт, тышкы як» мәгънәсендә, угыз диалектларында «тау аралыгы» дигән мәгънәдә кулланыла (икенчел мәгънә) [Татар теленең этимологик сүзлеге, 2015, б. 192].

«Баш, кайдадыр керү урыны (мәсәлән, урманга)» мәгънәсендә төмән сөйләшендә *аwыс* сүзе кулланыла. *Аwыз* термины географик терминнар ясалганда еш очрый, мәсәлән: *урман аwызы, урман аwызы болыны* һ.б. Борынгы төрки *аүiz* сүзе «авыз», «тишек», «елга тамагы» мәгънәсендә кулланыла. М. Кашгари сүзлегендә әлеге сүз «арык тамагы», «кое тамагы» төшенчәсен белдерә. В. Радлов сүзлегендә *aғis* чагатай телендә – «авыз», «тишек», «елганың тарлавыгы» мәгънәсенә ия [Гарипова, 2017, б. 11]. Әлеге апеллятив ярдәмендә ясалган географик атамаларның таралыш ареалы гаять киң.

*Қалым* сүзе тубыл һәм төмән сөйләшләрендә «зур булмаган күл, торгын сулы зур булмаган күл» мәгънәсендә кулланыла: *Пы гөл (күл) төгөл, қалым қуй, күлцегәц кенә* (төмән). Тубыл сөйләшендә әлеге лексема «баткаклык» мәгънәсендә йөри [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 2009, б. 384].

*Қаш* сүзе төмән сөйләшендә «калкулык» мәгънәсендә кулланыла (тат. әдәби каш – «бровь»). Мәсәлән: *Пестә қаш пашта уйнатың.* Казан арты сөйләшләрендә, минзәлә, бөре һәм пермь сөйләшләрендә дә ул шул ук мәгънәдә йөри: *Алар қаш пашқа цыққаннар та йатқаннар* (төмән). *Пейек қаш пар* (тубыл). Томск һәм тубыл сөйләшләрендә әлеге сүз «яр» мәгънәсен белдерә: *Қашта қарлыгач ойалары бар ит, пуйыл күрмәгәнем.*

Себер диалектларында *төс* сүзе «урман, дала, кыр» дигән мәгънәдә кулланыла (тат. әдәби төс – «цвет»): *Төстә цийә йәйеп йататқаннар әwәле* (тубыл).

*Түбә* сүзе тикшерелгән территориядә «калкулык, курган» мәгънәсендә кулланыла (тат. әдәби түбә «крыша»). Тубыл һәм бараба сөйләшендә *түбә* лексемасы «түшәм» мәгънәсенә ия: *Бишекне бау ман эләләр түбәгә.* Эчкен сөйләшендә әлеге сүз «тау башын» белдерә: [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 2009, б. 663].

Географик терминнарда семантик диалектизмнардан тыш сүзләр семантикасының тараю яки киңәю процесслары күзәтелә. Аерым мисалларга тукталыйк.

Татар әдәби телендә һәм диалектларында *ком* сүзе «җир кабыгының өске өлешләрендә очрый торган каты минералларның вак кына бөртекләре» мәгънәсендә кулланыла, түбән сөйләшендә сүзнең семантикасы киңәя һәм *ком* сүзе «комлы яр» дигәнне аңлата.

*Йыш* сүзе түбән сөйләшендә «чытырман, урманда куе, үтеп булмаслык урын» мәгънәсенә ия (тат. әдәби еш – «часто»). Чагыштырыгыз: тевриз сөйләшендә *йыш агац* «чыршы» төшенчәсен аңлата; тубыл сөйләшендә – *йыш ийә* «урман иясе» дигән мәгънәдә.

Түбән сөйләшендә *мөйөш* сүзе «елга үзәне борылган урын» дигән өстәмә мәгънәгә ия. Башка сөйләшләрдә һәм диалектларда *мөйөш* сүзе һәм аның *мийеш/мейеш/мөгеш* фонетик вариантлары «почмак» мәгънәсендә (минзәлә, каргалы, тевриз, саз ягы, әстерхан һ. б. сөйләшләрдә) кулланыла. Бу очракта без түбән сөйләшендә мәгънә таралу процессын күзәтәбез.

Шулай ук тикшерелә торган территориядә тар локаль диалекталь берәмлекләр, ягъни лексик диалектизмнар таралган. Аларның кайберләренә тукталып китик.

*Масарат* сүзе өйрәнелгән төбәктә «рус зираты» төшенчәсен белдерә. Тара сөйләшендә *ул* «галәмәт, гаҗәп хәлләр» мәгънәсендә йөри. Әлеге сүзнең мәгънә күчү нәтиҗәсендә дә (татар халкы өчен хас булмаган, гаҗәеп), *мазар* һәм *сиарат* сүзләрен яраштыру нигезендә дә барлыкка килгән булуы ихтимал. Татар теленең күп кенә сөйләшләрендә «зират» мәгънәсендә *мазар* лексемасы кулланыла. Мәсәлән, тархан сөйләшендә *мазар ат* (гарәпчәдән), мордва-каратай сөйләшендә *мазарка* [ар. + суфф. *-ка*], чистай, сергач, чүпрәле сөйләшләрендә *мазарлык* [гар. + афф. *-лык*] сүзләре «каберлек, зират» мәгънәсендә йөри: *Теге ыцта урыс мазарлыгын күргәнсездер* (чистай) [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 2009, б. 462]. Түбән һәм тубыл сөйләшләрендә әлеге мәгънәдә *қырбаш* сүзе кулланыла: *Пөгөн қәбер қасқалы партық қырбашқа*.

*Цағыт* сүзе түбән сөйләшендә «чокыр, түбәнлек» дигәнне аңлата. Көнчыгыш диалектның башка сөйләшләрендә әлеге лексема башка мәгънәләргә ия. Мәсәлән, саз ягы сөйләшендә *цағыт* «кечкенә елга»ны аңлата. Тевриз һәм саз ягы сөйләшләрендә әлеге лексема «сикәлтәле, ермак» мәгънәсендә дә кулланыла.

*Цуқ* сүзе түбән сөйләшендә «нарат күркәсе»н белдерә. Тубыл, тара сөйләшләрендә, бараба диалектында бу сүз «күп» мәгънәсендә йөри. Бараба диалектында ул «куе» мәгънәсенә ия [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 2009, б. 715–716].

*Сиңер* сүзе түбән һәм саз ягы сөйләшләрендә «мыс, борын», тубыл-иртыш диалектында «үр» мәгънәсендә кулланыла: *Сауысңан сиңер. Қосық сиңер* [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 2009, б. 575]. Чагыштырыгыз: *сиңгәр, сиңгер* «борын, тау тезмәсе» > чув. *сиңкер* «кальга; тайгада сынган агачлар төшү нәтиҗәсендә барлыкка килгән табигый киртә», чагт. *сäңир* «ныгытма», каз. *сеңгір* «таулар чылбыры», ком. *сянгер*, нуг. *сенкер* «окоп»; кырг. *сеңир*

«өслегендә үлән үскән тау» [Татар теленең этимологик сүзлеге, 2015, б. 163].

Төмән сөйләшендә *цөй* сүзе ике мәгънәгә ия: 1) «урмандагы дымлы урын»; 2) «елга тугайларындагы түмгәкле сазлы урын»: *Цөй агацлықта мүкле йир булады. Цөйләртә булаты күк цөйә* (караҗиләк). Төмән һәм тубыл сөйләшләрендә – әлеге лексема «сазлыклы урын, сазлык» дигәнне аңлата: *Ул йаққа барып булмай, цөй.* Тубыл һәм саз ягы сөйләшләрендә «яшь наратлык» мәгънәсендә йөри: *Цийә цөйнең эцентә пулмайт, ул агацлың ңый* (тубыл). Тара сөйләшендә шулай ук *цөй агац* сүзтезмәсе «чыршы» мәгънәсенә туры килә.

Төмән сөйләшендә «ылыслы агач» мәгънәсендә *керцек* сүзе кулланыла. Тубыл-иртыш диалектында *керцек* сүзе «ылыс» дигән мәгънәгә ия: *Урманнықы* (чыршыныкы) *керцекләре қойылмайты* [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 2009, б. 300].

*Күрән* сүзе төмән сөйләшендә «тугай, озакка су баса торган түбәнлек» дигән мәгънәдә кулланыла. Тубыл-иртыш диалектында бу сүз «сазлыкта чабылган печән; нигездә кыяклардан торган печән» мәгънәсенә ия.

Төмән сөйләшендә *қыwақ* сүзе «елга буендагы, сазлыктагы куаклар» мәгънәсендә йөри: *Балтырган қыwақларда үсәте*. Чагыштырыгыз: тубыл сөйләшендә әлеге сүз «урмандагы кечкенә сазлык» мәгънәсендә [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 2009, б. 434].

Тар кулланышлы географик терминнар категориясенә түбәндәге лексемалар керә: *көрийә* – «култык», *өйөрмә* – «упкын», *тишек қуыш* – «трактор белән чабып бетерә алмаслык печән», *сугылыш* – «янәшә, якын җир», *дөрйә* – «зур тигез җир», *тумар* – «сазлыкта түмгәк» һ.б. Мәсәлән: *Анта тумарлы йер, пецән цапңалы пулмайты. Пецән пулмады тумар цабып* (тубыл). *Тумарлы йертә пецән цаwawac* (саз ягы).

Шулай итеп, тикшеренү түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкинлек бирә. Төмән районы территориясендәге географик терминнар татар әдәби теленә һәм татар теленең башка диалектларына якын торалар. Тикшерелә торган категориядә көнчыгыш диалект сөйләшләренә хас төш элементлары да бар, шуның белән бергә төрле тарихи, социаль, табигый-географик һәм башка факторлар йогынтысында барлыкка килгән үзенчәлекле фонетик һәм лексик күренешләр дә урын ала. Гомумән алганда, тикшерелгән мисаллар төмән сөйләшенең татар диалект системасының бер элементы булуын тагын бер кат раслый.

## Әдәбият

Атлас татарских народных говоров / под ред. Д.Б. Рамазановой, Т.Х. Хайрутдиновой. Казань: ИЯЛИ, 2015. 632 с.

*Гарипова Ф.Г.* Татар топонимиясе: халкыбызның географик атамаларында – терминнар / Ф.Г. Гарипова. Казан: ТӘһСИ, 2017. 456 б.

*Мурзаев Э.М.* Местные географические термины и их роль в топонимии // Местные географические термины. М., 1970. С. 16–35.

*Карпенко Ю.А.* Топонимы и географические термины (вопросы взаимосвязи) // Вопросы географии. 1970. № 81. М., С. 36–45.

Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2017. Т. III. 1 кис. 536 б.

Татар теленең зур диалекталогик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

Татар теленең этимологик сүзлеге: 2 томда / төз. Р.Г. Әхмәтьянов; фәнни мөхәррире Р.Т. Сәфәров. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. Т. II. 567 б.

Татар халык сөйләшләре: Ике китапта / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б. Казань: Мәгариф, 2008. Беренче китап. 463 б.

*Тумашева Д.Г.* Диалекты сибирских татар. Опыт сравнительного исследования. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1977. 294 с.

***Хисамов Олег Ришат улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директорының фән эшләре буенча урынбасары*

***Хөсәинова Алинә Ямил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 81ʹ374

***Ә.К. Булатова,***
***Ф.К. Сәгъдиева***

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЧИГҮ ЭШЕНӘ КАРАГАН ЛЕКСИК БЕРӘМЛЕКЛӘР
## (эш әсбаплары һәм кирәк-яраклары мисалында)

Вышивание у татар является одним из традиционных и излюбленных видов рукоделия. Исследование данного лексического пласта не только способствует определению исторических этапов развития языка, но и имеет немаловажное значение для освещения многих вопросов духовной культуры, языковой картины мира татарского народа.

**Ключевые слова:** термины вышивания, татарский язык, терминосистема, наименование инструментов, отраслевая лексика, профессионализм.

Embroidery is one of the traditional types of needlework among the Tatars. The study of the vocabulary related to it not only helps to determine the historical stages of the development of the language, but also has an important significance for highlighting many issues of spiritual culture, the linguistic picture of the world of the Tatar people.

**Keywords:** embroidery terms, Tatar language, term system, name of tools, industry vocabulary, professionalism.

Чигү элек-электән татар хатын-кызларының иң яраткан һөнәрләреннән берсе булган. Үсмер чактан ук яшь кызларны бирнә өчен төрле эшләнмәләр чигәргә өйрәткәннәр. Йорт эчләрен бизәү өчен дә чигелгән сөлге, япма, кашага, келәмнәрдән файдаланганнар, кием-салымны да чигеп бизәргә яратканнар. Нәтиҗәдә татар халкына гына хас милли чигү сәнгате барлыкка килгән. Хәзерге көндә әлеге һөнәр тагын активлашып китте. Әмма, шуны әйтергә кирәк, чигү осталары әлеге кәсепкә караган аерым терминнарны татарча атаганда кыенлыклар кичерә. Элек булган күп кенә лексик берәмлекләр җуелып бара.

Татар теленең сүзлек составында татар милли һөнәрчелек һәм кәсепчелегенә караган лексика аерым бер урын били. Чигү эше атамалары халкыбызның тарихы, мәдәнияте белән тыгыз бәйләнгән. Өйрәнелә торган лексик катламда милләтнең дөньяга карашы турында кыйммәтле мәгълүмат сакланып калган дип тә әйтергә мөмкин, чөнки әлеге һөнәр – татар халкының традицион мәдәниятенең үзенчәлекле бер өлеше.

Мәкаләдә чигү эшенә караган лексик берәмлекләрне өйрәнү татар теленең аңлатмалы, этимологик һәм башка төр сүзлекләре нигезендә алып барылды. Бүгенге көндә лексиканы фәнни яктан тикшерүдә сүзлек дефиницияләре аркылы өйрәнү методы аерым урын

алып тора. Әлеге метод ярдәмендә төрле типтагы сүзлекләрдә китерелгән тәгъбирләрдә чагылыш тапкан материалны анализлау күздә тотыла. Шулай ук сүзлекләр сүзнең семантик структурасында урын алган үзгәрешләрнең динамикасын да күзалларга ярдәм итә [Сагдеева, 2019, с. 212].

Чигү терминнарын өйрәнүне халыкның милли мәдәниятенең үсеш этаплары белән берлектә карарга кирәк. Чигү эшенә караган лексемалар системасы, тарихи-этнографик чыганак булу белән беррәттән, тел ягыннан да кызыклы бер катламны тәшкил итә.

Татар телендә һөнәрчелек лексикасының чигү атамалары төрлелек белән характерлана. Ул үз эченә әлеге өлкәгә караган тар һөнәри терминнарны, шулай ук профессиональ лексиканың башка катламнарына кергән сүз һәм сүз формаларын, термин функциясендә йөргән гомумкулланылыш сүзләрен берләштерә. Әлеге катлам лексиканы берничә кечерәк тематик төркемгә бүлеп өйрәнергә мөмкин.

Чигү дигәндә без кул яки машина белән төрле төстәге җепләр, сәйлән, ука һ.б.ш. белән тукыма яки башка өслекләргә бизәк төшерүдән гыйбарәт булган гамәли бизәлеш төрен күздә тотабыз [Булатова, 2021, с. 198]. Әлеге кул эшендә төрле эш әсбаплары һәм кирәк-яраклары файдаланыла.

Татар телендә *кайчы* сүзе номинатив мәгънәдә ‘кара-каршы китереп уртадан тоташтырылган үткен йөзле ике пычактан гыйбарәт, очларындагы балдаксыман боҗраларын баш һәм урта бармакларга киеп хәрәкәтләндерелә торган кискеч корал’ны аңлата [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2017, т. 3, б. 64]. Мәсәлән, *җепне кайчы белән кисү*. Сүз төрки телләргә монгол теле аша борынгы кытай теленнән кергән дип санала (*kiap toi* – ‘чалыштырылган пычаклар’) [Әхмәтьянов, 2015, т. 1, б. 346]. Татар теленең урта диалектының балтач, дөбьяз, бөре һәм минзәлә сөйләшләрендә *қанчы* диалекталь варианты яшәп килә [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 2009, б. 387]. Кул эшләрендә кайчының берничә төре файдаланыла. Чигү эшендә гадәттә *җеп кайчысы* яисә *кечкенә кайчы* дигән атамалар кулланыла [Рәхимова, 1983, б. 62]: *Чикәндә җепләремне җеп кайчысы белән кисеп бардым.*

*Киерге* сүзе ‘чигү чиккәндә, тукыманы тарттырып куя торган рам формасындагы җайланма’ мәгънәсенә ия [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2017, т. 3, б. 242]. Әлеге сүз *киерү* фигыленнән ясалган дип карала. Урта диалектның кама тамагы сөйләшендә сүзнең *кирги* диалекталь варианты, тубыл-иртыш диалектында *қыса* диалектизмы (әдәбия телдә – рама, рамка) файдаланыла [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 2009, б. 313, 448]. Чигү чиккәндә гадәттә төрле форма һәм зурлыктагы киергеләр кулланыла, татар телендә *агач киерге, зур киерге*, *түгәрәк киерге, шакмак киерге* һ.б. сүзтезмәләр бар. Кайбер чигү осталары *киерге* сүзен *боҗра* сүзе белән алмаштыралар.

*Җеп* лексик берәмлеге йон, мамык, ефәк, җитен һ.б.ның җепселләрен бер-берсенә кушып, нечкә итеп сузып, бөтереп эрләнгән эшлән-

мәне аңлата [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2016, т. 2, б. 312–314] һәм ул гомумтөрки *йип* берәмлегенә кайтып кала [Әхмәтьянов, 2015, т. 1, б. 265]. Татар теленең кайбер диалектларында *йеп* формасы кулланыла. Чигү эшендә төрле җепләр файдаланыла: мулине, наруз, ефәк җепләр, йон җепләр һ.б.

*Ыргак* – эләктереп тарту яки элеп кую өчен башы кәкре агач яки тимер [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2005, 698]. Килеп чыгышы ягыннан әлеге сүз борынгы төрки *ыргай* ‘бөгелү, кәкрәю’ фигыленнән ясалган дип фаразлана [Әхмәтьянов, 2015, т. 1, б. 505]. Урта диалектның минзәлә сөйләшендә һәм мишәр диалектының чистай сөйләшендә бу мәгънәдә *шөлдермә* диалектизмы файдаланыла [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 2009, б. 789]. Шулай ук кайбер чигү осталары *ыргаклы энә*, яисә *тамбур энәсе* сүзтезмәсен кулланалар.

*Энә* – ‘бер башы очлы, икенче башында җеп кертү өчен тишеге булган тегү, чигү, бәйләү һәм үрү коралы’ [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2005, б. 708]. Лексик берәмлек борынгы төрки *йәги* ‘тегү’ сүзеннән килеп чыккан [Әхмәтьянов, 2015, т. 2, б. 511]. Аның күптөрле диалекталь вариантлары актив кулланыла: *инә, ивнә, инйә, ийнә, ийенә, үнә, эзнә, эҗнә* [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 2009, б. 210–212, 691, 802]. Чигү чиккәндә, гадәттә кечкенә зурлыктагы энәләрдән файдаланалар, алар телдә *чигү энәсе* сүзтезмәсе белән бирелә. Чигү эшенең төрле техникаларында махсус энәләр кулланыла, алар, төрләренә карап, аерым терминнар белән атала: *тамбур энәсе , сәйләнэнәсе, келәм энәсе* һ.б.

Чигү осталары тарафыннан энәләр махсус йомшак өслекләрдә саклана, татар телендә алар *энәкадагыч, энә мендәре*, энәләр саклана торган футляр – *энә савыты* лексик берәмлекләре белән бирелә.

*Уймак* – ‘энә тишмәсен өчен бармак очына киелә торган эче куыш металл әйбер’ [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2005, б. 606]. Сүз төрки *ой* ‘тегү’ лексемасыннан килеп чыкан. Диалектларда аның *бармакча, бармакса* дигән диалекталь вариантлары актив кулланыла, мәсәлән, мишәр диалектының тау ягы керәшеннәрне сөйләшендә [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 2009, б. 101].

Чигү осталарын шулай ук энәгә җеп саплый торган махсус җайланманы да актив кулланалар, ул телдә *энә саплагыч, саплагыч* яки *күзләгеч* берәмлекләре аша бирелә.

Соңгы вактыта кул эшендә чигү өчен төрле энәләрне киертеп куела торган насадкалар белән җиһазланган махсус эш коралы файдаланыла башлады, ул телгә *чигү коралы* сүзтезмәсе белән кереп бара.

Күргәнебезчә, татар телендә чигү эшенә караган эш әсбаплары һәм кирәк-яраклары гомуми кулланылышта булган лексим берәмлекләр белән бирелгән. Гомумхалык сүзләре белән беррәттән телдә диалекталь вариантлар да үз урынын ала. Алда китерелгән лексемалар кулдан чигүнең барлык төрләренә дә карый.

**Әдәбият**

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. Т. 1. 543 б.; Т. 2. 567 б.

*Булатова* А.К. Этнолингвистический пласт в отраслевой лексике татарского языка (на примере наименований инструментов, используемых в вышивальном деле) // Функциональная грамматика: теория и практика. Чебоксары: Чуваш. гос. пед. ун-т, 2021. С. 198–200.

*Рәхимова Р.К.* Татар теленең һөнәрчеклек лексикасы (туку, өс-баш, аяк киемнәре тегү, шәл бәйләү, итек басу буенча). Казань: Татар. кит. нәшр., 1983. 160 б.

*Сагдеева Ф.К.* Отражение концептуализации яхшылык в семантической структуре многозначного слова // Тюркское языкознание XXI века: тюркская лексикология и лексикография. Казань: ИЯЛИ, 2019. С. 212–214.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 6 томда. Казан: ТӘҺСИ, 2015. Т. 1. 712 б.; 2016. Т. 2. 748 б.; 2017. Т. 3. 744 б.; 2018. Т. 4. 760 б.; 2019. Т. 5. 908 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

***Булатова Әлфия Кәрим кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Сәгъдиева Фәүзия Кәбир кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми тел белеме бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 82-2

*Ә.М. Закирҗанов*

# XXI ГАСЫР БАШЫ ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ МИЛЛИ ЯШӘЕШ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Статья посвящена раскрытию особенностей развития татарской драматургии начала XXI века. Последовательно выявляются художественные искания в сценической литературе, подчеркивается специфика освещения вопросов истории и личности, сохранения национальных ценностей и традиций. На основе анализа произведений ведущих драматургов раскрывается многообразие способов и приемов создания национального характера, а также поиски авторов в области художественных приемов, средств изображения действительности.

**Ключевые слова**: татарская драматургия, тематика, национальное своеобразие, проблематика, характер, поэтика.

The article is devoted to the disclosure of the peculiarities of the development of Tatar drama at the beginning of the XXI century. The artistic quest in stage literature is consistently revealed, the specificity of the coverage of issues of history and personality, the preservation of national values and traditions is emphasized. Based on the analysis of the works of leading playwrights, a variety of methods and techniques for creating a national character is revealed, as well as the search for authors in the field of artistic techniques, means of depicting reality.

**Keywords:** Tatar drama, themes, national originality, problems, character, poetics.

XXI гасыр башы татар драматургиясе форма һәм эчтәлек өлкәсендә, заманча сәнгати алым-чараларда, тема һәм жанр төрлелегендә уңышлы эзләнүләр алып бара. Аның яңалыгын яшәешне фәлсәфи планда чагылдыру, милли һәм гомумкешелек кыйммәтләренең үзара тыгыз керешеп китүе, төрле юнәлеш-агымнарның синтезы күзәтелү кебек сыйфатлар билгели. Бу исә тематик төрлелеккә, әдәби-эстетик эзләнүләрнең төрле яссылыкта алып барылуына китерә. Яңа гасыр башында Т. Миңнуллин, Р. Батулла, Ф. Садриев, Р. Хәмид кебек өлкән буын һәм З. Хәким, Аманулла, Р. Сәгъди, Д. Салихов, М. Гыйләҗев, Ф. Галиев, Г. Каюмов, Р. Зәйдулла, Ш. Фәрхетдин һ.б. кебек урта буын драматурглар актив иҗатта кала. Моңа кадәр әдәбиятның башка төрендә уңышлы эшләгән Э. Яһүдин, Х. Ибраһим, Л. Лерон, Р. Бохараев, З. Хөснияр, Н. Кәримова, З. Минһаҗева, С. Юзеев, А. Әхмәтгалиева һ.б. драматург буларак та танылу ала. Ә инде И. Зәйниев, Р. Сабыр, Р. Мөхсинова, С. Гаффарова, Й. Миңнуллина, Н. Исмәгыйлева, А. Шәйдуллин исемнәре сәхнә әдәбиятына яңа буын килү турында хәбәр итә.

Җәмгыять ихтыяҗларына җавап эзләп, драматургия яшәешнең төрле якларына мөрәҗәгать итә, иҗтимагый, милли һәм шәхси мәсьәләләр заманча яссылыкта, тема-мотивлар байлыгында чагылыш

таба. Кеше бәхете, яшәү һәм үлем, гомер агышы, яшәү мәгънәсе турында уйланып, драматурглар ерактагы һәм якындагы тарихны, совет җәмгыятендәге, тоталитаризм дәверендәге гаделсезлекләрне, әфган һәм чечен сугышы кайтавазын, авылларның бетүе һәм глобальләшү күренешен, җәмгыятьтә барлыкка килгән яңа гадәтләрне, гомумкешелек кыйммәтләренең киму һәм шәфкатьсезлек билгеләренең арту сәбәпләрен, милли традицияләргә янаган куркынычны һ.б. тасвирлауга киләләр [Закирзянов, с. 159–160]. Чор татар драматургиясендә, яшәешнең җитди мәсьәләләрен сурәтләүдә төрле әдәби-эстетик концепцияләргә нигезләнүгә бәйле, реализм һәм романтизм иҗат принципларының модернизм һәм постмодернизм юнәлешләренә хас элементларның, алым-чаралар белән үзара кушылып, үзенчәлекле синтез хасил итүе күзәтелә. Яшәешнең серле якларын ачуның юлларын эзли барып, драматурглар яңадан-яңа алым-чараларга – көтелмәгән метафорага, архетипларга, фантастик күренешләргә, параллель дөнья сурәтенә, бер әсәр эчендә төрле текстлар үрелеп баруга, яңа миф тудыруга һ.б. – киң мөрәҗәгать итәләр. Бу яссылыкта драматургия татар әдәбиятында постмодернистик эзләнүләрне әйдәп бара [Загидуллина, с. 12]. Т. Миңнуллин, З. Хәким, И. Зәйниев, Р. Зәйдулла, Д. Салихов, Р. Сәгъди, Х. Ибраһим һ.б. пьесалары гыйбрәтле сюжеты, төрле жанрларга хас алым-чараларның үрелеп баруы, автор фикеренең еш кына метафора булып килгән күренешләрдә, үзенчәлекле символларда, әдәби детальләрдә, архетипик образларда чагылуы белән күптөрле укылышка ия әсәрләр буларак игътибарга лаек.

Үткән гасыр ахырында сәхнә әдәбиятының үзәген тәшкил иткән милләт язмышы мәсьәләсе бу чорда да киң урын алып, эчтәлек-фикердә генә түгел, сәнгати яктан да уңышлы пьесалар языла. «Иң җитди үзгәреш татар милли тарихын чагылдыруда» [Ханзафаров] булып, Аттила, Кубрат хан, Алмыш хан, Кол Гали, Идегәй, Сөембикә, Колшәриф, Мөхәммәдьяр, Алтын Урда ханнары, Батырша, Сәет батыр кебек танылган шәхесләрнең әдәби образы тудырыла. Батулланың «Җимерелгән бәхет» (2004), З. Хәкимнең «Кайда син, Атилла?» (2010), Ф. Галиевнең «Сәйдәш вальсы» (2010), Р. Зәйдулланың «И минем яктыртучым» («Шулай булды шул», 2013), «Үлеп яратты» (2010), Ю. Сафиуллинның «Йосыф-Зөләйха» (2014) пьесаларында данлы һәм фаҗигалы тарихның аерым сәхифәләре заман фәлсәфәсенә төшенергә мөмкинлек бирә. XVI гасыр уртасында Рус дәүләтенең Казан ханлыгын басып алуы фаҗигасы, мәңге төзәлмәслек яра булып, гасырлар дәвамында әдипләрнең игътибар үзәгендә тора. М. Маликованың «Сөембикә» (2003), Р. Зәйдулланың «Соңгы татар» (2006), Г. Гыйльмановның «Сөембикә» (2007) трагедияләрендә әлеге тарихи вакыйгалар урын ала [Еникеев, с. 116]. М. Маликованың «Сөембикә» пьесасында Казан ханбикәсенең Казандагы соңгы көннәре, гаять хәвефле вакыты тасвирлана. Хәрәкәтне тудыручы каршылык, бер яктан, ханлык эчендәге я ачыктан-ачык, я яшертен рәвештә барган бәрелешкә ишарә ясый, икенче яктан, Казан ханлыгы белән рус

дәүләте арасындагы конфликт рәвешендә бирелә. Ул ханбикәне һәм улын Мәскәүгә алып китү белән тәмамлана. Вакыйгалар аша язучы кешедәге рухи бөеклек һәм түбәнлекнең асылын аңларга омтыла. Киләчәкнең бәясе дә ачык сиземләнә: Сөембикә халкыбыз күңелендә азатлыкка омтылу символы булып урын алса, Шаһгали, Нурали морза кебекләр түбәнлек, хурлык, хыянәт үрнәген хасил итә. Р. Зәйдулланың «Соңгы татар» пьесасында Казан ханлыгының фаҗигалы тарихы, моңа китергән сәбәпләр контекстында ханлыкта дин башлыгы булып хезмәт иткән Кол Шәриф образы алгы планга чыгарыла. Сөембикә-ханбикәгә яшерен сөю белән янучы герой туган җиренә янаган куркынычны ачык сизә һәм моны булдырмас өчен бөтен көчен куя, әмма хыянәт-мәкергә каршы тора алмый. Сөембикәне Мәскүгә биреп җибәрүне Кол Шәриф ил фаҗигасы дип кабул итә, җан газабы кичерә. Р. Зәйдулла сурәтләгән күренешләр аша бүгенгенең җитди мәсьәләләре калкып чыга һәм укучыны мәхәббәт һәм нәфрәт, бөеклек һәм түбәнлек, батырлык һәм хыянәт төшенчәләре турында уйлануга этәрә.

Татар әдәбиятында чагылыш тапкан тарихи шәхесләр арасында шагыйрь Г. Тукай образы үзгә урын били: аның исеме, иҗаты татар милләтенең идеалы рәвешен ала. Тукай образына татар драматурглары еш мөрәҗәгать итә. XX гасыр ахырында И. Юзеевнең «Очты дөнья читлегеннән», Р. Ишморатның «И мөкатдәс, моңлы сазым», Т. Миннуллинның «Без китәбез, сез каласыз», Р. Батулланың «Сират күпере», Ә. Гаффарның «Соңгы сәгать» пьесалары аеруча киң яңгыраш алып, җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнә. Әгәр И. Юзеев шагыйрьне үз чорының улы буларак романтик-символик сурәтләлек аша тасвирласа, Т. Миннуллин Тукайның Идел буенча сәяхәтен, аның фабрикант Акчуриннарда кунак булуын үзәк вакыйга итеп ала һәм тормышка капма-каршы позициядә торган шәхесләр каршылыгы кебек ача. Ә. Гаффар драмасында исә Тукай фәлсәфи планда, яшәү мәгънәсен, иҗат асылын аңларга омтылучы, шулар аша халык тормышына якынаючы шагыйрь буларак бирелә. Әлеге традицияләрне дәвам итеп, Р. Зәйдулланың «И минем яктыртучым» («Шул булды эш», 2013) драмасында Тукайны шәхес буларак аңларга омтылу алга чыга. Шагыйрьлек әсәрдә сөю утында янучы «мәҗнүн» мотивы белән бәйләнә. Тукай халык язмышын кайгыртып, аның бүгенгесенә һәм киләчәгенә борчылып яши, аны бердәм, дус-тату, мәдәниятле милләт итү өчен бөтен көчен куя. Р. Зәйдулла бөек әдип иҗатына шәхси тормышы аша килә һәм аны романтик гражданин-милләтпәрвәр образ итеп тергезә.

Әдәбиятта дини сюжетка яисә риваять-легендаларга нигезләнгән драмалар да билгеле бер урын ала (Р. Батулла «Мур кырылышы» (2004), Э. Яһүдин «Олуг хан фәрманы» (2007), «Тәхет» (2008), Ю. Сафиуллин «Йосыф-Зөләйха» (2014) һ.б.). Мондый әсәрләрдә «поэтик символлар, аллегорик метафоралар өстенлек итә. Алар халыкның тарихи-эстетик мирасы, этнокультурасы традицияләрендә

булулары белән дә әһәмиятле» [Ханзафаров]. Бу яктан Р. Батулланың «Мур кырылышы» фаҗига-хроникасы игътибарга лаек булып, драматургның эзләнүләре төрки-татар тарихы белән чикләнмичә, Европа киңлекләренә үтеп керә. Иҗтимагый-сәяси һәм көнкүреш мәсьәләләре дини, фәлсәфи, әхлакый сораулар белән үрелеп барган пьеса үткәннәр аша бүгенгенең күп сорауларына җавап эзләргә этәрә. Ю. Сафиуллин «Йосыф-Зөләйха» музыкаль риваятендә Кол Гали әсәре эчтәлегенә салынган фәлсәфи һәм әхлакый фикерләрне гаять уңышлы тотып ала, эзлекле, бөтенлекле рәвештә яңа әсәр кысасында укучы-тамашачыга җиткерә. Иманлы Йосыф, кешелеклелек, ата-ананы, туган җирне ярату, сабырлык, ярдәмчеллек кебек сыйфатларны һәрдаим яклавы белән бүгенге укучы-тамашачыга да үрнәк һәм гыйбрәт буларак ачыла. Автор драматик вакыйгаларны музыкаль бизәлеш һәм хореография элементлары белән баета, эмоциональ тәэсирле, тамашалы һәм, иң мөһиме, заманча яңгырашлы итә.

Милли тематиканың тагын бер чагылышы буларак, милли эчтәлекне халыкның асылын билгеләүче традицияләр, гореф-гадәтләр, тел-моң төшенчәләренең герой характерында, эш-гамәлендә биреле-ше аша ачу белән Т. Миңнуллинның «Саташу» (2001), «Галиябану, сылуым, иркәм» (2005), Р. Зәйдулланың «Пачпортлы шүрәле» (2002), З. Хәкимнең «Телсез күке» (2003), Ф. Садриевның «Без китәбез, ахры» (2007), С. Гаффарованың «Килмешәк» (2017) һ.б. пьесаларда очрашабыз. Сурәтләнгән тормыш материалы белән төрле булсалар да, аларны милли бердәмлек идеясе, аның халыкчан яшәү рәвеше, җыр-моң, тел уртаклыгы аша чагылышы үзара якынайта.

Т. Миңнуллин «Саташу» драмасында буыннар арасында бәйләнеш югалу, социаль каршылыкларны үтеп чыга алырлык рухи көч булмау кешене саташулы халәткә китерүен сызлану фәлсәфәсе аша ача. З. Хәким «Телсез күке»сендә халкыбызның милли асылын саклап калуның нигезе итеп гаделлекнең җиңүенә ышану, дин, гореф-гадәт аша гына түгел, бәлки җыр-моң буларак җанда урын алган яшәү рәвешен саклау һәм нинди генә шартларда, кайда гына яшәгәндә дә бердәмлеккә омтылуны алга чыгара. Ф. Садриевның «Без китәбез, ахры» драмасы хәзерге татар авылында барган катлаулы, каршылыклы процессларны күрсәтүе белән кызыклы. «Капитал мөнәсәбәтләргә күчкәннән соң барлыкка килгән яңа хуҗалар – кемнәр алар?» дигән сорауга җавап эзләгәндә, кешенең кеше булып калуы, ата-бабалар рухына тугрылыгы, туган ил, туган җир, халык каршында җаваплылыгы калкулана. Әсәр укучы-тамашачы күңелендә гаделлекнең җиңеп чыгачагына ышаныч уята.

Милли сыйфат-билгеләрнең юкка чыга баруын Р. Зәйдулла аерым геройларның эш-гамәленнән көлү, тәнкыйтьләү аша күрсәтә. «Пачпортлы шүрәле» комедиясендә XX гасыр ахыры татар авылының эчке хәле чагылыш таба. Җәмгыятьтәге гаделсезлек, ялган, үзара көнләшү, һәрнәрсәнең сату-алуга корылуы – болар татар халкына хас иң матур сыйфатларның югала баруына, кешелек кыйммәтләрен

әхлаксызлык күренешләре алыштыруга китерә. Р. Зәйдулла татарның милли психологиясен алга куя, яшәү рәвешен, телен, традицияләрен сакламавына, киләчәге өчен көрәштән читләшүенә тирән борчыла. Шүрәлегә «пачпорт» ясатып, аны Россия гражданины итү, М. Җәлил һәйкәле белән газетадагы Шүрәле сурәтен тәңгәлләштерү яисә партиягә алып, Шүрәлене депутат итәргә җыенуда һәртөр җитәкче алдында баш иярга әзер татар өчен әрнү чагыла.

Ил буйлап таралып яшәгән, чит илләрдә гомер кичергән татарларның тормышы, чит җирләрдә телне, гореф-гадәтләрне саклап яшәү мөмкинлеге әдипләрне, шул исәптән драматургларны да даими кызыксындыра. С. Гаффарованың «Килмешәк» драмасында сугышта әсирлеккә төшеп, концлагерь газаплары үткән кешенең Канададагы көнитеше сурәтләнә. Чит илдә яшәп калган кеше бәхетлеме? Читтән килеп төпләнгән килмешәк – кем ул? Мескен җанмы, әллә бу җир аның өчен дә якын-кадерлеме? Туган җир, яшьлек, беренче сөйгән яр, әти-әни кадере кебек төшенчәләр ни дәрәҗәдә кыйммәт? Әлеге мәсьәләләр һәм Дәрдемәнднең һәркемгә таныш «Сөт калыр, ватан китәр...» дигән гыйбарәсе турында да уйландырып, драматург төп герой Нәкыйпнең истәлек-хатирәләре аша күңел халәтен, җан сызлануларын тергезә. Нәкъ менә милли яшәеш үрнәкләре, сыйфатлары аны гомере буе, таяныч буларак, озата баралар. Төп герой чит илдәге йортын үз җире дип кабул итсә дә, аның туган җирен сагынып, сызланып яшәве аңлашыла. Авторның «туган җир – чит ил» антиномиясе аша кайда гына яшәсәң дә, милли асылыңны саклау сине шәхес итеп таныта дигән карашы төп идея булып яңгырый.

Заман героен, татар милли характерын тудыруның уңышлы үрнәкләре дип З. Хәкимнең «Телсез күке»сендә Зариф, «Легионер»ында Яббар, Ф. Садриевның «Без китәбез, ахры»сында Баян, Т. Миңнуллинның «Алты кызга бер кияү»ендә Рәхмәтулла, И. Зәйниевнең «Мәхәббәт турында сөйләшик»ендә Ногман карт, Р. Зәйдулланың «Үлеп яратты»сында Мөхлисә Буби кебек персонажларны күрсәтергә мөмкин. Шуның белән бергә, татар драматургиясенең бер үзенчәлеге буларак, милли геройларның күңел дөньясында фаҗигалылык төсмере киң урын алып тора. Бу исә, тарихыбызның үткәне генә түгел, бүгенгесе дә каршылыклы, катлаулы булуын аңлаган хәлдә, халыкны коллык, мескенлек психологиясеннән арындыру омтылышы белән бәйле.

Татар милли характерының гаять үзенчәлекле бирелеше белән З. Хәкимнең «Телсез күке» театраль романында очрашабыз. Татар сәхнә әдәбияты өчен яңа жанрда язылган әсәрдә романга тиң вакыйга-күренешләр, гаҗәеп язмышлар, аерым шәхесләр аша халык тормышы чагылыш таба, «нәтиҗәдә катлаулы, күппланлы, күпмәгънәле әсәр килеп чыга» [Заһидуллина, Йосыпова, б. 134]. Бөек Ватан сугышы алды чорыннан алып XX гасыр ахырына кадәрге вакытны үз эченә алган вакыйгаларда милләт язмышы рухи ныклык, бердәмлек, иманлы булу, халыкчан гореф-гадәтләрне саклап яшәү кебек сыйфат-

ларга бәйле ачыла. Пьесаның сюжеты нигезендә гыйбрәтле вакыйга ята: СССР белән Финляндия арасында 1939–1940 еллардагы сугыш вакытында Татарстанның Чулман төбәгендә туып үскән Зариф Финляндия ягыннан торып сугышучы Зыятдин исемле татар егете белән очраша. Әмма бу гади очрашу түгел. Снайпер Зыятдин, мөмкинлеге булса да, татарча җырлап утыручы Зарифка атмый. Алай гына да түгел, әлеге ике «дошман» үзара танышып, бергә халык җырын җырлый башлыйлар һәм совет солдатлары тарафыннан кулга алыналар. Геройлар язмышын кискен үзгәртеп җибәргән, аларга әйтеп-сөйләп бетермәслек кайгы-хәсрәт алып килгән әлеге хәлгә бәйле сораулар калкып чыга: «Дошман солдаты татарча җырлап утыручы Зарифка нигә атмаган?», «Фронт сызыгының ике ягында сугышучы ике татар егете ни өчен бер-берсенең язмышын җиңеләйтү юлларын эзли?» Бу сорауларга җавапны автор әлеге геройларның эш-гамәлләре, характер сыйфатлары, бер-берсенә, әйләнә-тирәдәгеләргә, халкының яшәү рәвешенә, бөтен язмышына мөнәсәбәтләре аша эзли.

Телсез Күке кушаматлы Зариф образы тормышчанлыгы белән көчле. Урман йортында үсеп, табигать яратучы, аннан көч һәм тынычлык алучы егеттә горурлык һәм гаделлек, сабырлык һәм кыюлык кебек характер сыйфатлары аеруча калку чагыла. Вакыйгалар барышында егетнең җыр-моңга бай нечкә күңеле, ярдәмчел, миһербанлы олы йөрәге булуы да ассызыклана. Иң мөһиме – яхшылыкны, изгелекне аңлый белү, шуны яшәү принцибы итү Зарифның бөтен асылын билгели. Боларның җирлеге булып туган җире, туган халкы, аның иң матур традицияләре, гореф-гадәтләре тора. Ул – «чынбарлыкның рәхимсез һәм кешелексез кануннарын танымыйча, бары тик йөрәк авазын тыңлап яшәргә күнеккән кеше» [Габәши]. Автор концепциясен ачу-аңлауда мөһим урынны Зыятдин образы алып тора. Үзен татар милләтенең бер вәкиле дип санаган егет өчен ата-баба телен белү, җыр-моңын өйрәнү җан-рух терәге булып тора. Шуңа да татар җыры – Зыятдин өчен, чикләрне белми торган изге төшенчә: ул ата-баба каны тамган җир ямен, халыкның фаҗигалы язмышын, теләк-омтылышын үзенә сыйдырган. Әнә шуны аңлау Зариф белән Зыятдинны үзара якынайта, туганлаштыра, бер-берсенә ярдәм итүнең намус эше, иман ныклыгы булуын раслауга китерә. Шул рәвешле, заманның фәлсәфи, милли, әхлакый, сәяси мәсьәләләренә нисбәтле гыйбрәтле вакыйга-күренешләрдә гаять үзенчәлекле милли характерлар мәйданга чыга.

Д. Салиховның «Узып барышлый» (2002), «Өзелгән йөзем» (2003) пьесаларында Бөек Ватан сугышы кайтавазы бөтенхалык фаҗигасын, аның аерым кеше, милләт тормышында чагылышын ачуга хезмәт итә. Сугыш вакыйгаларына бәйле рәвештә милләт язмышы, кешенең рухи иреге-азатлыгы мәсьәләләре калкытып куела. Пьесалар «моңсу аһәңе, йөрәкләрне чеметтереп ала торган хакыйкате белән җәлеп итәләр» [Гыйльманова, б. 132]. Драматург беренче әсәрдә алгы планга чыгарган Шәйхулла карт үзенең дөньяга карашы,

рухи дөньясы белән милли характер буларак ачыла. Ул беркатлылыгы, гади-гадәтилеге, бөек төшенчәләр турында тормышчан уйлавы, кешеләргә ышануы һәм үз инануларының дөреслегенә шикләнмәве белән аерылып тора. Милләтне милләт итеп яшәтә торган сыйфатлар рәвешендә Шәйхулла карт үзара, бигрәк тә өлкән буын кешеләренә хөрмәтне, җыр-моң белән рухланып яшәүне, телне онытмауны алга куя.

Милли сыйфат-билгеләре белән аерылып торган, шул ук вакытта гомумкешелек кыйммәтләренә хезмәт итүче әсәрләрнең бер өлешендә яшәеш фәлсәфәсе, әхлакый кыйммәтләр дини караш-тәгълимат белән үрелеп бара, ягъни «меңьеллык ислам мәдәниятенең халкыбызга яңадан әйләнеп кайтуы» [Арсланов] күренә. Андый әсәрләрне ике төркемгә бүлеп карарга мөмкин. Кайберләрендә ислам дине кыйммәтләре тормыш-яшәеш мәсьәләләре белән кушылып китә һәм әсәр геройлары Аллаһы Тәгаләгә сыенып, иман ныклыгы аша максатларына ирешә яисә алар яклаган башка төрле яшәү рәвешенең киләчәге юклыгы дәлилләнә (Т. Миңнуллин, «Саташу»; З. Хәким, «Телсез күке», «Гасыр моңы»; Р. Батулла, «Җимерелгән бәхет»; И. Зәйниев, «Мәхәббәт турында сөйләшик» һ.б.). Икенчеләрендә дини яшәү рәвешенә, ислам дине яклаган һәм саклаган тәгълиматның чынбарлык белән ярашуына бәйле бәхәсләр урын алып, алар киң планда әсәрнең нигезенә салынган каршылыкны билгели (Т. Миңнуллин, «Мулла»; Р. Зәйдулла, «Үлеп яратты» һ.б.).

Шулай итеп, яңа гасыр башы драматургиясендә татар халкы язмышы ерактагы һәм якындагы тарих, сугыш кайтавазы, авыллар тормышы, җәмгыятьтә барлыкка килгән яңа гадәтләр, рухи кыйммәтләр үзгәреше, милли яшәү рәвеше кебек гаять мөһим мәсьәләләр аша чагылыш таба. Сәхнә әдәбиятында милли характер буларак нәсел тамырларыннан аерылмаган, халык язмышын үз язмышы иткән, заман сынауларына бирешмәгән геройлар урын ала. Глобальләшү шартларында милләтне саклап калу омтылышы аерым кешенең һәм халыкның табигать дөньясы, галәм һәм космос, мөселман һәм христиан цивилизацияләре һ.б. белән катлаулы мөнәсәбәтен ачыклауга китерә. Милли һәм гомумкешелек кыйммәтләрен раслау барышында драматурглар шартлы образларга, яңа жанр формаларына мөрәҗәгать итә. Сәнгати планда вакыйгаларның җыр-музыка белән үрелеп баруы, геройларның күңел халәтен психологизм алымнары ярдәмендә чагылдыру, лирик-эмоциональ сурәтлелек, символик-метафорик күренешләр, мифологик дөнья сурәтләре һ.б. әлеге төр пьесаларның поэтик нигезен тәшкил итә.

**Әдәбият**

*Арсланов Г.* Татар драматургиясе, хәлең ничек? // Мәдәни җомга. 2004. 17 декабрь.

*Габәши А.* «Телсез күке» күпне сөйли // Мәдәни җомга. 2005. 21 гыйнвар.

*Гыймранова Д.* Сәхнәбездә ниләр бар? // Казан утлары. 2005. № 9. Б. 131–134.

*Еникеев И.А., Ганиева А.Ф., Миннуллина Ф.Х.* Аспекты эстетической коммуникации в татарских трагедиях XX века // Современные исследования социальных проблем, Красноярск, 2019. Т. 11. № 1–2. С. 109–117.

*Загидуллина Д.Ф.* Татарская литература и национальный театр: одна дорога на двоих // Театр XXI века и вызовы Нового времени: материалы Международной научно-практической конференции, посвященной 110-летию татарского театра / под ред. Э.М. Галимовой. Казань: ИЯЛИ, 2016. С. 4–13.

*Закирзянов А.М.* История и личность в современной татарской драматургии // Материалы XII Международной научно-практической конференции «Ашмаринские чтения» (20 ноября 2020 г.). Чебоксоры: ЧГУ, 2020. С. 159–161.

*Заһидуллина Д.Ф., Йосыпова Н.М.* XX гасыр татар әдәбияты: дәреслек. Казан: Казан ун-ты, 2011. Т. 2. XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. 198 б.

*Ханзафаров Н.* Яңа гасыр татар драматургиясе // Мәдәни җомга. 2010. 8 окт.

***Закирҗанов Әлфәт Мәгъсүмҗан улы***,
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге мөдире*

УДК 82-21

***Г.И. Каюмова***

# РИЗВАН ХӘМИДНЕҢ «ХАН КЫЗЫ» ДРАМАСЫНДА ТАРИХИ ШӘХЕС КОНЦЕПЦИЯСЕ

В статье дается полный анализ исторической драмы «Ханская дочь» одного из активных и плодотворных драматургов конца XX – начала XXI веков Р. Хамида. В образе Сююмбике, как объекта национальной гордости, символа свободы, воплощается концепция исторической личности, рассматриваются образы и других исторических личностей, которые также оставили глубокий след в судьбе нации, показывается значительная роль в судьбе народа неомифического образа Язгюле, что определяет новаторство драматурга.

**Ключевые слова:** Р. Хамид, драматургия, история, драма, историческая личность, Сююмбике, неомиф, неомифический образ.

The article provides a complete analysis of the historical drama «The Khan's Daughter» by one of the active and productive playwrights of the late 20th – early 21st centuries R.Hamid. The concept of a historical person is embodied in the image of Syuyumbike, as an object of national pride, a symbol of freedom, the images of other historical figures who also left a deep mark on the fate of the nation are examined, the significant role of the neo-mythical image of Yazgule in the fate of the people, which determines the playwright's innovation, is shown in the article.

**Keywords:** R. Hamid, dramaturgy, history, drama, historical personality, Syuyumbike, neo-myth, neo-mythical image.

XX гасырның соңгы чирегендә, ягъни үзгәртеп кору еллары килгәч тә, галимнәр милли тарихыбызны, шул исәптән Казан ханлыгының руслар тарафыннан басып алыну кебек экспансив сәясәтен бары тик аклау һәм яклау позициясеннән чыгып аңлатуда җибәрелгән хаталар, төгәлсезлекләр турында ачыктан-ачык яза башладылар. Ф. Урманче, мәсәлән, «Чын тарихны азлар белә» мәкаләсендә рус шовинистлары тарафыннан бик тырышып пропагандаланган «Казан ханлыгы, һичшиксез, Алтын Урданың бер өлеше булган һәм ул, XV гасырның 80 нче елларында Алтын Урда таркалгач, үз өстенә әнә шул таркалган дәүләтнең вазифасын ала. Нәтиҗәдә, табигый, сәясәттә һәрвакыт Русиянең дошманы булып тора» дигән фикерне кире кага [Урманче, 1995]. «Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV–XVI вв.» (1995) хезмәтендә С. Алишев Казан – Мәскәү мөнәсәбәтләренә багышланган мәсьәләгә төрле тарафтан якын килгән хезмәтләргә җентекле күзәтү ясый, аларда хөкем сөргән фикер аерымлыкларын шәрехләп, үзенең төгәл позициясен ачыклап бирә. Хезмәттә Казан белән Мәскәү дәүләтләре арасындагы сәяси мөнәсәбәт, шул исәптән Мәскәү кенәзлегенең Казан ханлыгына карата алып барган басып алу сәясәте төгәл күрсәтелә [Алишев, 1995, с. 158].

Мәгълүм булганча, Казан шәһәре 1552 елның октябрь аенда залим, мөдһиш Иван IV тарафыннан басып алына. Мәмләкәтнең, бу зур шәһәрнең халкы күпләп юкка чыгарыла. Казан ханлыгы яшәүдән туктый.

Казан ханлыгы тарихын үзенең зирәк акылы, ханлыкның бәйсезлеген саклау өчен күрсәткән иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге белән гасырлар буе халык хәтерендә сакланган соңгы ханбикәсе – мәшһүр Сөембикәдән башка күз алдына китереп тә булмыйдыр, мөгаен. Әлеге шәхескә багышлап, ул алып барган сәясәтне яктыртып, ватандаш һәм чит ил язучы-галимнәр, тарихчылар, әдәбият һәм тел белгечләре шактый мәкаләләр бастырып чыгардылар, аерым хезмәтләр яздылар. Сөембикә образын өйрәнүгә күп көч һәм вакыт сарыф иткән профессор Ф. Урманче исеме аеруча игътибарга лаек. И. Рәмиеваның әлеге образга багышлап «Әдәбиятта Сөембикә образы» дип исемләнгән диссертациясе зур казаныш булып тора. Хезмәтнең өйрәнү объекты – рус, татар һәм төрек язучыларының төрле жанрларда Сөембикәгә багышлап язылган әсәрләре. А. Саттарова «Современная татарская драматургия: 1985–2000 гг.» дип исемләнгән кандидатлык диссертациясенең бер бүлегендә Сөембикә ханбикә шәхесенең әдәби гәүдәләнешен драматург Р. Хәмиднең «Хан кызы» драмасы мисалында тәкъдим итә.

Рус әдәбиятында Сөембикә образы беренчеләрдән булып XVI гасырның икенче яртысында иҗат ителгән «Казан тарихы» («Казан елъязмачысы») тарихи-публицистик әсәрендә чагылыш таба. Казан ханлыгы һәм аның ханбикәсе Сөембикә белән тирәннән кызыксыну 1779 елда М. М. Херасковның «Россиада» эпик поэмасы язылу уңаеннан башланып китә. Моннан соң XIX гасырның беренче яртысында С.Н. Глинка, А.Н. Грузинцев, Г.Р. Державин, М.С. Рыбушкин, В.И. Лапинның әсәрләре дөнья күрә. И. Рәмиева үзенең фәнни хезмәтендә әлеге әсәрләрдә сурәтләнгән Казан ханбикәсе Сөембикә образына тулы анализ бирә.

Татар әдәбиятында бу образга беренчеләрдән булып Һ. Атласи, Г. Исхакый, М. Гафури, Ф. Әмирхан, Ф. Туйкин һ. б. мөрәҗәгать итә. Алар тарафыннан иҗат ителгән тарихи әсәрләрдә Сөембикә, нигездә, «милли азатлык һәм рус баскынчылыгына каршы көрәш символы буларак сынландырыла» [Измайлов, 2012, б. 349]. Татар әдипләренең романтик рухтагы әсәрләрендә татар ханбикәсенең идеаллаштырылган образы тудырыла. Әйтик, Ф. Әмирханның «Сөембикә» хикәясендә Сөембикә халык язмышын кайгыртучы «ил анасы», «халык кызы» буларак тасвирлана [Әмирхан, 1995]. Татар әдәбияты аша «милләт анасы» сыйфатында бу образ соңрак төрек әдәбиятына да үтеп керә. И. Нәүрүзхан, Х. Туган, Л. Каран һәм башка төрек язучыларының Сөембикәгә багышлап язылган әсәрләрендә бу ачык күренә.

Күп кенә тарихи чыганакларда һәм аерым мәкаләләрдә Сөембикәнең бик матур, акыллы, нык характерлы, зур дәүләт белән идарә итәрлек дәрәҗәдә тапкыр, зирәк һәм кешеләр белән игелекле мөнәсәбәттә булуына басым ясала. Рус елъязмаларында да Сөембикәнең

чибәр һәм акыллы булуы турында әйтелә. Татар риваятьләрендә («Сөембикә», «Патша хәйләсе» һ.б.), әдәби әсәрләрдә дә ханбикәнең гүзәллеге һәм кешелеклелеге чиксез мактала. Әдәби әсәрләрдә ул еш кына Явыз Иван уздырган рәхимсез сәясәтнең чарасыз корбаны һәм хәйләкәр дошманның ялган сүзләренә беркатлы ышанучанлык күрсәтеп ялгышкан газиз халкының хыянәтенә юлыккан бәхетсез ил башлыгы сурәтендә бирелә.

Р. Батулла «Сөембикә кыйссасы» романында ханбикәне милләтебез азатлыгы, аның бәхетле киләчәге өчен җан атып яшәүче ватанпәрвәр, кешелекле, миһербанлы, батыр шәхес, зирәк акыл иясе итеп сурәтли. Әлеге әсәрдә Сөембикә – «азатлык өчен көрәш билгесе генә түгел, бәлки, әйдәүче байрак билгесе буларак та кабул ителә» [Галимуллин, 1993].

М. Хәбибуллин 1996 елда дөнья күргән «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» романында «урыс, татар, Нугай урдасы тарихын, бу халыкларның көндәлек тормышын, караш-ышануларын, милли характерларын ярыйсы ук яхшы белеп» [Урманче, 1997, б. 93] яза. Романны шартлы рәвештә ике мөстәкыйль бүлеккә бүлеп карарга мөмкин. Аның берсендә сүз, нигездә, рус патшалыгы, Мәскәү кенәзлеге һәм андагы сәяси вакыйгалар, көндәлек тормыш турында булса, икенчесендә исә Казан ханлыгы һәм Сөембикә язмышы хакында бара. Язучы Мәскәү тарихын, андагы сәяси һәм көндәлек тормыш вакыйгаларын җентекле яктырта. Романның баш геройлары Сөембикә ханбикә белән Иван Грозный билгеле бер дәрәҗәдә бер-берсенә каршы куеп сурәтләнә. Барыннан да элек аларның фаҗигалы язмышлы тарихи шәхесләр булуы ассызыклана.

1990 елларда Р. Хәмид әлеге тарихи-легендар шәхесне сәхнә биеклегеннән яктыртырга алына. 1995 елда драматургның «Хан кызы» (1993) тарихи драмасы [Хәмид, 1995] басылып чыга. Казан ханлыгы һәм Сөембикә турында бу бердәнбер сәхнә әсәре түгел. Әлеге чор һәм ханбикә турында 1900–1918 елларда ук пьесалар языла. Аларның беренчесе 1910 елда сәхнәгә куела, аннан Ф. Туйкин тарафыннан 1912 елда тагын берсе иҗат ителә. Шул ук елны ул «Шәрык клубы»нда сәхнәләштерелә. Соңрак төрек драматургы Г. Хәйдәр «Шаһгали» пьесасын иҗат итә. Әлеге пьеса «Сәйяр» труппасы репертуарында урын ала һәм уңыш казана. Күрәбез: мөселманнарны милли бәйсезлек мәсьәләсе бервакытта да битараф калдырмаган.

Р. Хәмиднең «Хан кызы» драмасында Казан халкы һәм, гомумән, татар халкы тарихында дәһшәтле вакыйгалары, фаҗигалы язмышлары белән тирән эз калдырган 1550–1553 еллар тасвирлана. «Драматург, тарихи фактларга һәм Казан ханбикәсе Сөембикәнең үлеме турындагы мифларга һәм легендаларга таянып, неомиф иҗат итә» [Саттарова, 2004, с. 15]. Әлеге неомифта Казан ханлыгы һәм аның ханбикәсенең аяныч язмышы яктыртыла. Әсәрдән аңлашылганча, төп каршылык ил азатлыгы, аның бердәмлеге һәм халык бәхете өчен көрәштән гыйбарәт.

Әдәби әсәрдә тарихи чынбарлык, тарихи шәхес образы белән беррәттән уйлап чыгарылган фактлар һәм образларның да урын алуы табигый. Бу уңайдан пьесада Сөембикәнең «язмышын һәм эшен дәвам итүче» Язгөле образы игътибарга лаек. Шул рәвешле, драматург «тарихи фактларга үзенең иҗат фантазиясен кушып, XVI гасыр вакыйгалары фонында Сөембикә ханбикәнең һәм аңа тышкы кыяфәте белән бик тә охшаш төстәшенең якты образларын тудыра» [Саттарова, 2004, с. 16].

Пьесада Сөембикә – татар язмышын билгеләүдә идея-фәлсәфи юнәлеш бирүче халыкчан, югары трагик образ, нык ихтыяр көченә ия көчле шәхес; шул ук вакытта ул – баласын өзелеп сөюче нечкә күңелле ана да, дәүләт эшенә аек акыл белән караучы, ил язмышы өчен хәлиткеч мизгелләрдә үзен тыныч тотарга тырышып, ыгы-зыгы куптармый гына дөрес һәм гадел карарлар кабул итәргә омтылучы кырыс һәм җитди сәяси эшлекле дә. Газиз халкын, илен өзелеп яратучы, милләтенең ачы язмышы, киләчәге өчен чын күңелдән борчылучы, аның иминлеге, бәхете өчен үзен аямыйча көрәшүче, халык ихтирамын казанган тугры милләт анасы да ул.

1552 елда казанлыларның мәскәүлеләргә бирешүләренең төп сәбәбен тарихчы галим И. Таһиров татар элитасында бердәмлек булмауда, җитәкче даирәләрнең татардай батыр һәм сугышта үз-үзен аямаучы халыкны дошманга каршы оештыра алмауларында күрә [Таһиров, 2004, б. 72]. «Казан дәүләтенең җитәкче даирәләре, тәхет тирәсендә тупланган көчләр череп-таркалып, үзара низагка кереп беткән була... Көнчелек, үзара дошманлык шулкадәр көчле була ки, мирзаларның шактый өлеше үз мәнфәгатьләрен өстенрәк куеп, дошман ягына күчүдән дә баш тартмый» [Таһиров, 1994, б. 161], – дип яза ул.

Пьесада да моның шулай булуы аңлашыла. Ханлыкның Камай морза, Нургали бәк, Ходайкол би, Сөембикә хадимәсе Гәүһәршат кебек ханбикәгә идарә эшендә терәк булырга, дошман көчләрне кире кайтару өчен дәүләтне бер учка туплауда ярдәм күрсәтергә тиешле кешеләре дошман ягына авышып, ханбикәләрен аның кулына тапшыруда зур инициатива күрсәтәләр, халыкка, ил иминлеге өчен тырышучы дәүләт башлыгына каршы яшерен, астыртын көрәш алып баралар.

Дуслыкны ныгыту һәм дошманга каршы көрәштә ярдәм алу өчен, зирәк акыллы ил башлыгы Кырым, Нугай, Хаҗитархан һәм Себер ханнарына ашыгыч рәвештә илчеләр җибәрә. Тик сатлык шымчылар аркылы ханбикәнең әлеге ниятен алдан белеп өлгергән Явыз Иван ханлыктан чыгу юлларын яптырта, илчеләрнең һәммәсе дә кулга алынып, Мәскәү патшасына озатыла, әмма Сөембикә югалып калмый. Ул Казан халкын шундый авыр, киеренке мизгелләрдә, үзара ызгыш-талашларны, ачу-үпкәләрне онытып, «бер тән, бер йодрык» булып берләшеп, дошманга каршы нык торырга, Идел йортны дошман керүдән сакларга чакыра. Ханбикәнең халыкка мөрәҗәгате ялкынлы, кайнар, хисләре чик дәрәҗәдә киеренке, югары пафослы, Сөембикәнең һәр сүзендә халык язмышы, аның киләчәге өчен тирән

борчылу сизелә. Драматургның Сөембикәне туган иленә карата чиксез мәхәббәт иясе итеп сурәтләве әлеге образның иҗтимагый-сәяси, әхлакый-этик кыйммәтен тагы да арттыра төшә.

Драмада шагыйрь Мөхәммәдьяр образы ханбикәнең эчке кичерешләрен, рухи дөньясын ачуда, иҗтимагый әһәмияткә ия мәгънәне җиткерүдә зур роль уйный. Алар арасындагы диалогка игътибар итик:

*Ир.* Казан үзен арысланга саный ахры, гамьсез йоклый, бөек ханбикә! Төше матурдыр, димим. Ләкин иртәгә көтүчесез калачагын сизми сыман: чынлап та, без синең белән икәү генә йоклый алмый бәргәләнәбез бугай. Караңгылыкта ваемсыз мышнау гына ишеттем мин!

*Сөембикә.* Тагын бер сорау белән борчыйм мин сине, чичән: үз башлыгын дошманына тотып биргән илне ничек атарга була?

*Ир.* Соравыңа сорау белән җавап бирергә рөхсәт ит, ханбикә: шагыйрен кабер сакчысы иткән ил башлыгын ни дип атарга була?..

*Сөембикә.* Җавабың ошады миңа, бөек чичән... Калдыр Мөхәммәт Әмин хан каберен: тереләрне саклар заман килде. Салкын кабер киңәшче түгел.

*Ир.* Рәхмәт, бөек ханбикә! Мөхәммәт Әмин төрбәсендә мин ялгыз булмадым: ил башлыгы өстенә чичән дә иде бит ул. Хуш, ханбикәм!

*Сөембикә.* Озын гомер телим сиңа, шагыйрьләрнең шагыйре!

*Ир.* Теләмә, ханбикә... Бүген мин үлгәннәрдән көнләшәм!

*Сөембикә (үз-үзенә әйткән кебек).* Күңелемдәгене телең белән әйттең, чичән...

Әлеге диалогта ике бөек шәхеснең ил, милләт язмышы белән бәйле тирән күңел ярасы ачыла. Р. Батулла романында да Мөхәммәдьяр образы «күренекле акыл иясе, философ итеп бирелә. Ул татулык, бердәмлек, ярдәмләшү җитмәүнең, киресенчә, үзара тарткалаш, сугышларның төрки-татар дәүләтен афәткә китергәнлеген башкаларга караганда да тирәнрәк тоя» [Хатипов, 1993, б. 157; 2003, б. 180].

Әдәби тәнкыйть тарихи шәхесне әсәрдә кардиналь вакыйгалар, халык тормышы һәм язмышы үзәгендә бирүне таләп итә... Шәхес никадәр генә талантлы, бөек булмасын, ул – үз халкының баласы, вәкиле, аның язмышы халык язмышы белән тыгыз бәйләнгән [Әшрәфҗанов, 2000, б. 193]. Менә ни өчен ханбикәнең фаҗигалы язмышы – ул татар милләтенең дә фаҗигасы. Ханбикәнең намуслы йөрәге явыз дошман кулына тоткын булып төшү хурлыгын күтәрә алмый. Дөрестән дә, бөтен көчен, яшьлеген халкына, аның бәхетле киләчәгенә багышлаган ил башлыгын дошман кулларга биреп җибәрү һәм аның моңа каршылык күрсәтә алмавы – хурлык, рухи фаҗига. Язгөленең сөйгән егете Таңайга әйткән сүзләре дә раслый моны: «Зур дәүләтнең башлыгын улы белән бергә дошман кулына коллыкка биреп җибәрәләр! Чөнки ул моңа каршы тора алмый: сарык кебек карусыз буйсынырга тиеш, шушы хурлык түгелме?!.. Аның исеме мәңге тарихта каласы! Кем дип искә алачаклар аны мондый хәлләрдән соң?!

Зирәк акыллы ил хөкемдары булган, дипме? Моңа кадәр тоткан данына карапмы? Һичкайчан да! Дошманыннан мәрхәмәт көтәргә мәҗбүр ителгән куркак һәм бичара хатын көненә төшкән бер мескен, диячәкләр! Яки – кызганулары мөмкин!»

Шәригать законнарын бозып, дәүләт башлыгының үз-үзенә кул салуы, ягъни биек манарадан егылып төшеп, үз гомеренә чик куюы – аның дошман көчләргә каршы көрәшә алмау чарасызлыгыннан туган эчке көрәше нәтиҗәсе; рухи фаҗигасының чик дәрәҗәгә җитүе. Әлеге гамәле белән горур ханбикә дошманнарына тирән нәфрәтен, алардан бәйсезлеген, бөек халкына тугрылыгы белән аңа булган үпкәсен дә белдерә. Бу ханбикәнең гаделсезлекләргә, түбәнсетелүләргә, кимсетелүләргә протесты һәм ялгыз көрәше дә булып аңлашыла.

Сөембикәнең милләт язмышы белән бәйле бәхетсезлеге дә, үлеме дә тирән трагизм белән сугарылган. Ул үзе дә – трагик шәхес. «Трагик герой, – дип яза К.В. Шохин, – игътибар үзәгеннән читтә калучылардан түгел, киресенчә, ул кай ягы белән булса да игътибарны җәлеп итә, я нәфрәт, яки мәхәббәт уята» [Шохин, 1961, с. 9]. Пьесада физик һәм, иң мөһиме, рухи матурлыгы, халкына тугры хезмәте, ватанпәрвәрлеге белән газиз халкының гына ихтирамын казанып калмаган, дошманнарында да нәфрәт катыш соклану хисе тудырган Сөембикә дә укучыда үзенә карата хөрмәт һәм мәхәббәт хисләре уята. Шул рәвешчә, «Сөембикә язмышы, бер үк вакытта, милләтебезнең йөз аклыгын һәм драматик тарихын да гәүдәләндерә. Аның яшәешендә мәһабәтлелек белән ачы фаҗига аралаша... Сөембикә – татар халкының йөзек кашы, сөекле кызы, ихлас горурлыгы, шул ук вакытта йөрәгенең төзәлмәс ярасы да ул» [Хатипов, 1993, б. 152].

Пьесада дәүләт башлыгын фаҗигалы язмышка дучар итүдә, күргәнебезчә, хыянәт мотивы зур роль уйный. Бу – ханбикәнең иң якын, ышанычлы кешеләренең хыянәте буларак күзаллана. Әсәрдән аңлашылганча, болар – Сөембикәнең кайгы-шатлыгын «бүлешүче» киңәшче хадимәсе Гәүһәршат; дәүләт аппаратын җитәкләүче, ханбикәгә идарә эшендә зур терәк булырга тиешле Камай, Бәхтияр морзалар, Нургали бәк, Ходайкол би.

Тарихта туган илгә хыянәте белән мәгълүм кырыс, явыз Камай морзага пьесада аеруча зур урын бирелә. Морзаның кылган гамәлләре, сөйләгән сүзләре һәрдаим аның миһербансызлыгын ассызыклый. Язгөлене тотып, Казанга китертү өчен, үзенең йорт сакчыларын, хезмәтчеләрен бер гөнаһсызга үтертүе, шыгавыллары[1] белән мәрхәмәтсез кылануы, гомумән, гади халык белән тупас мөгамәләсе, ялган сөйләве бу кешенең чын асылын фаш итә.

Фаҗигага сәбәпче булган икенче бер мотив – битарафлык. Бу – Казан халкының ханбикәсе язмышына битарафлыгы. Ханбикәнең язмышы хәл ителгәндә, «халыкның гамьсез йоклавы» шуны раслый. Димәк, ул үз язмышына да битараф.

---

[1] *Шыгавыл* – ишек сакчысы.

Драмада Сөембикәгә «ике тамчы су кебек охшаш» Язгөле Казан ханбикәсе Сөембикәнең тормышын «дәвам итүче» социаль-иҗтимагый әһәмияткә ия образ буларак калка. Әлеге образның мәгънә йөге – фаҗигалы рәвештә гомере өзелгән ханбикәсе өчен үч алу. Язгөле әсәрнең буеннан буена игътибар үзәгендә. Ул – ятим дала кызы, Камай морзаның җариясе. Әсәр башында ук бу кыз үткен телле, чая, курку белмәс, нык ихтыяр көченә ия дала кыргые булып күзаллана. Камай морза, Казан ханлыгының кырымлылар белән бәйләнешен өзү өчен, чын ханбикәне вакытлыча яшереп торып, аның урынына төстәше Язгөлене куеп, үзе һәм аның даирәсе теләгәнчә идарә итү максатын күздә тота. Ил иминлеге, тынычлыгы һәм бердәмлеге өчен көрәшәсе урында, ханбикәне Мәскәү патшасы Явыз Иванга тотып бирүдә актив инициатива күрсәтергә җыенган Камай морза шулай да хирыс теләгенә ирешә алмый. Гади халык кызы Язгөле аннан күпкә хәйләкәррәк һәм җитезрәк булып чыга. Сөембикәгә дөресен сөйләп биреп, әлеге кешенең явыз ниятләрен җимерү һәм ханбикә белән «рольләрне вакытлыча алмашу» максатын күздә тотып, кыз качып китә.

Хәлләр шушы ук хәлләрне җимерүгә юнәлтелгән характерлар формалаштыра. Әсәрдә Язгөле дә шундый характер булып ачыла. Вакыйгалар кыз көтмәгән якка борылыш ала. Сөембикәнең аның күз алдында манарадан егылып төшеп һәлак булуы кызның язмышын бөтенләй үзгәртә. «Әсәрдә төп игътибар Сөембикә образыннан Язгөле образына күчә... Берсе тоткын хәлдә яшәүдән үлемне артыграк күрә, икенчесе, ялган юл белән дошманнан үч алу, аннан көлү өчен, үз теләге белән тоткын ролен кабул итә» [Нигматуллина, 2002, с. 140]. Шул рәвешле, төгәл тормышчан хәлләрдән төгәл тормышчан шартларда героик характер туа.

Ремаркада күрсәтелгәнчә, 1552 елның 2 октябрендә Казан ханлыгы яшәүдән туктый. Ә 1553 елда Мәскәү патшасы Явыз Иван Казанны тар-мар итүдә күрсәткән «олы эшләре» өчен Касыйм ханы Шаһгалигә «Сөембикәне» кияүгә бирә. Мәскәүдә шаулатып уздырылган туйның «атасы» Явыз Иван үзе була.

Казан ханлыгы һәм Сөембикәгә багышланган башка әсәрләрдән аермалы буларак, М. Хәбибуллин үз әсәрендә әлеге образны сурәтләүгә аеруча зур игътибар бирә. Язучы романда рус патшасының холкын, кыланышларын тәфсилләп бәян итә. Аның балачактан ук коточкыч бер авыру зат булып, гомере буена якын кешеләренең бер дә юкка канын коюын, ачуын чыгарган кайбер кешеләрне этләрдән яки аюлардан ерткычларча талатуын, үзенең шул кыланышларыннан, кылган гамәлләреннән чиксез ләззәт алып, күп еллар үз халкын һәм башка халыкларны рәхимсез талап яшәвен этрафлы сурәтли.

Күп кенә тарихи чыганаклардан мәгълүм булганча, Казанны дошман кулына бирүдә Шаһгали зур инициатива күрсәтә. Драмада да ул Иван IV каршысына тезләнеп: «Гаскәр бир миңа! Бер айдан мин

синең аягың астына Казан тәхетен китереп салачакмын! Синең изге эшең өчен тәнемдә аккан канымның һәр тамчысы шаһит китсен! Гаскәреңне һәм фатихаңны бир миңа!» – ди.

Ризаэддин бине Фәхреддиннең «Шаһ Гали хан» язмасына карата искәрмәсендә Р. Әмирхан Шаһгалинең тышкы кыяфәтенә мөнәсәбәтле барлык чыганакларның да уртак фикердә булуларын телгә алып, аның турында «тышкы кыяфәтендә шыксыз, җирәнгеч бер бәндә була» [Фәхретдинов, 1995, б. 89], – ди. Чордашлары аның хакында: «...беркем дә яратмый, аның белән аралашмый, кансыз, холыксыз бер кеше иде» [Гариф, 1996, б. 93], – дип язалар. Ул хәтта Мәскәү яклы татарлар өчен дә күңел кайтаргыч бер кеше була [Фәхретдинов, 1999, б. 116]. Рус чыганакларында да Шаһгали турында шуңа охшаш фикерләр хөкем сөрә [Худяков, 1990, с. 177].

Шаһгалинең физик яктан кимчелекле булуы Р. Хәмид драмасында да персонажның үз сүзләрендә искәртелә. Шаһгали белән «Сөембикә»нең ачыктан-ачык әңгәмәсендә әлеге хыянәтченең рухи фаҗигасы ачыла: «Кешенең кыяфәте – аның язмышы ул», – ди Шаһгали. Бу персонажның иләмсез зур, ямьсез тышкы кыяфәте аның рухи дөньясының чагылышы булып тора. Шунысын да билгеләп үтү кирәктер: Шаһгалинең тышкы кыяфәте белән бәйле кимсенүләрен, газап тулы эчке кичерешләрен калку сурәтләү образны тормышчан, җанлы итә, хәтта аңа карата кызгану хисе уята.

Сөембикә дип кабул итеп, ихластан күңелен бушаткан әлеге кешегә Язгөле үзенең Шаһгали гомере буе хыялланган ханбикә түгеллеген, ә гади бер дала кызы булуын әйтә. Һәм моның белән шушындый явызлар аркасында якты дөнья белән хушлашырга мәҗбүр булган Сөембикәнең үчен кайтара. Үч алу мотивының пьесада үзенчәлекле чагылыш табуын күрәбез. Халкына үчлеккән Шаһгалигә халык үче, бәҗра сыман, кире әйләнеп кайта. Гап-гади бер дала кызын ханбикә дип белеп «шау» итү Явыз Иванга Казанның төп терәге булган Сөембикәне тереләй тотып бирәм дип ант эчкән Шаһгалинең дә, Мәскәү патшасының да чын йөзләрен ачарга ярдәм итә.

Шул рәвешчә, үзен Сөембикә ханбикә итеп таныта алган халык кызы Язгөле безнең күз алдыбызга зирәк акыллы, кыю, халык дошманнарына карата мәрхәмәтсез, дөреслек һәм гаделлек хакына үзен корбан итәргә дә сәләтле саф күңелле, нык ихтыяр көченә ия шәхес булып килеп баса. Ә Сөембикәнең һаман да «гүзәлләрдән гүзәл» булып саклануы әлеге образның тарих битләренә мәңгегә кереп калырлык яшьлек, матурлык, батырлык, зирәклек символы булуын ассызыклый. «Сөембикә белән Язгөленең рухи бердәмлегендә, якынлыгында халыкның ханбикәгә булган мөнәсәбәте, уртак максатка омтылышы чагыла» [Закирҗанов, 2011, б. 114].

Романтик пафос белән сугарылган «Хан кызы» драмасының ахыры да үзенчәлекле романтик чишелеш ала: Язгөле белән аның егете Таңайның яратып җырлый торган «Хан кызы» җыры яңгырый:

*Таңай:*

Хан кызы, ач ишегең, мин керием,
Мине сөйсәң, миңа дисәң, бер үбием!

*Язгөле:*

Сине генә сөйгәнемне белмиемсең?
Сөям диеп алдап кына йөрмиемсең?!

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: югарыда каралган сәхнә әсәрендә шәхес концепциясенең шәхес һәм җәмгыять бәйләнеше рәвешендә тарихи аспектта чагылыш табуын күрдек. Автор игътибарын халык тормышында якты эз калдырган Сөембикә шәхесенә юнәлтә. Пьесада Сөембикә – матурлык һәм зирәклек алиһәсе, азатлык символы, «милли горурлык объекты, милли эстетик идеал гәүдәләнеше» [Саттарова, 2004, с. 196], «татар халкының язмышы, иманы, фаҗигалы бер чор булган тарихы да» [Хәбибуллин, 2004, б. 20]. Язгөле исә иленә һәм халкына тугры неомифик образ буларак үзенчәлекле. А. Саттарова билгеләп үткәнчә, халыкның сөекле кызы өчен үч алу күренешен биргәндә неомифология тудыру язучының новаторлыгы булып тора [Саттарова, 2004, с. 196]. Шунысын да әйтеп китү кирәк: автор үзе әсәрне «тарихи драма» дип атаса да, жанр үзенчәлекләрен күздә тотып, әдәби тәнкыйтьттә бу әсәрне «трагедия» буларак тикшерү хупланыла (Ә. Закирҗанов).

**Әдәбият**


*Алишев С.Х.* Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV–XVI вв. Казань: Татар. кн. изд-во, 1995. 160 с.

Әмирхан Ф. Халык кызлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. 106 б.

Әшрәфҗанов Х. Ә. Тарихка әдәби сәяхәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 288 б.

*Галимуллин Ф.* Сөембикә һәм Каракош шәүләсе // Шәһри Казан. 1993. 4 сент.

*Гариф Н.* Казан каргышы // Мирас. 1996. № 9. Б. 91–94.

*Закирҗанов Ә.М.* Драматургның сурәтле дөньясы (Ризван Хәмид) // Рухи таяныч: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 104–118.

*Закирҗанов Ә.М.* Рухи таяныч: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 287 б.

*Измайлов И.Л.* Сөембикә // Татар энциклопедиясе: 6 томда / баш мөх. Ә.М. Мазһаров, җаваплы мөх. Г.С. Сабирҗанов. Казан: «ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты» дәүләт учреждениесе, 2012. 5 т.: Р–Т. Б. 349.

*Нигматуллина Ю.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. Казань: ФЭН, 2002. 176 с.

*Рамеева И.Р.* Образ Сююмбике в литературе (Эпоха и литературный герой): автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2002. 29 с.

*Саттарова А.М.* Современная татарская драматургия: 1985–2000 гг. (Концепция эпохи и героя): автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2004. 24 с.

*Таһиров И.* Безгә тарих сабак бирә // Мирас. 1994. № 11–12. Б. 161–165.

*Таһиров И.* Казан – 1552: фаҗига һәм киләчәккә өмет (фәнни-популяр мәкалә) // Мирас. 2004. № 6. Б. 66–72.

*Урманче Ф.* Чын тарихны азлар белә // Татарстан яшьләре. 1995. 6 июль.

*Урманче Ф.* Тарихи хәтеребезне терелтүче // Мирас. 1997. № 12. Б. 93.

*Фәхретдинов Риза.* Шаһ Гали хан // Мирас. 1995. № 3. Б. 86–91.

*Фәхретдинов Р. Г.* Казан ханлыгы // Казан утлары. 1999. № 10. Б. 111–117.

*Хатипов Ф.* Романнарда Сөембикә образы // Казан утлары. 1993. № 12. Б. 172–183.

*Хатипов Ф.* Романнарда – Сөембикә образы // Мөлкәтебезне барлаганда: Иҗат портретлары, тәнкыйди-теоретик мәкаләләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. Б. 172–183.

*Хәбибуллин М.* Сөембикә ханбикә һәм яман чор // Сөембикә. 2004. № 3. Б. 20.

*Хәмид Р.* Хан кызы: Тарихи драма // Мирас. 1995. № 1–2. Б. 102–114; № 3. Б. 44–50; № 4. Б. 52–61; № 5. Б. 59–72. Өземтәләр шушы чыганаклардан алынды.

*Худяков М.Г.* Очерки по истории Казанского ханства. Репринтное воспроизведение издания 1923 г. Казань: Фонд ТЯК, 1990. 310 с.

*Шохин К.В.* О трагическом герое и комическом персонаже. М.: Искусство, 1961. 56 с.

***Каюмова Гөлия Илдус кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты Энциклопедистика үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 82-311.6

***И.Г. Закирова,***
***С.Б. Даутова***

# И. ЕСЕНБЕРЛИННЫҢ «АЛТЫН УРДА» РОМАНЫНДА ХӨКЕМДАР ОБРАЗЫ. ЭПИК ТРАДИЦИЯЛӘР ҺӘМ ЗАМАН ИДЕОЛОГИЯСЕ

Статья раскрывает своеобразие концепции исторической личности, образ правителя, воина в пространстве художественного универсума Ильяса Есенберлина. Образы правителей Золотой Орды – Чингизхана, Бату хана, Берке хана и др. рассматриваются в контексте социодинамики развития государства и общества, в связи с идеей государственности. Историческое мышление писателя также несет в себе влияние идеологического контекста. Несмотря на значимость эпохи Золотой Орды, в общественном сознании существует противоречие, связанное с малоисследованностью этой темы. Противоречие наблюдается и в восприятии исторических личностей Золотой Орды. Автор воссоздает события прошлого, опираясь на исторические источники, факты, не противореча научно-объективному изображению истории.

**Ключевые слова:** исторический роман, Золотая Орда, Чингизхан, образ правителя, воинская культура, художественное своеобразие.

The article reveals the originality of the concept of a historical personality, the image of a ruler, a warrior in the artistic universe of Ilyas Yesenberlin. The images of the rulers of the Golden Horde – Genghis Khan, Batu Khan, Berke Khan, Uzbek Khan, Tuktamysh and others are considered in the context of the sociodynamics of the development of the state and society, in connection with the idea of statehood. The writer's historical thinking is also influenced by the ideological context. Despite the significance of the era of the Golden Horde, there is a contradiction in the public consciousness associated with little research on this topic. A contradiction is also observed in the perception of the historical figures of the Golden Horde, Batu Khan, Berke Khan and others. The author recreates the events of the past, relying on historical sources, facts, without contradicting the scientific and objective depiction of history.

**Keywords:** historical novel, Golden Horde, Genghis Khan, the image of the ruler, military culture, artistic originality.

Алтын Урда чоры тарихи вакыйгалары һәм шул чорның тарихи шәхесләре турында мәгълүмат теркәлгән язма чыганаклар аз түгел. Алтын Урда ханнарына һәм тарихта эз калдырган башка шәхесләргә багышланган язма истәлекләрнең иң борынгылары һәм әһәмиятлеләре – XIV йөз монгол язма истәлеге – «Юань-чао би-ши», XIII йөз кытай язма истәлеге – «Мэн-да бэй-лу», авторлыгы галим лама Лубсан Данзанга нисбәт ителгән XVII йөзгә караган «Алтан тобчи», фарсы тарихчылары Җүвәйни (XIII йөз), Рәшидеддин (XIII гасыр ахыры – XIV гасыр башы), гарәп тарихчысы Ибн-әл-Асир (XII гасыр ахыры – XIII гасыр башы), италияле де Плано Карпини, Марко

Поло, фламанд Вильгельм Рубрук һ.б. хезмәтләре. Төрки, рус, әрмән, әфган, грузин һ.б. елъязмачыларының язмаларында да бу чор турында мәгълүмат китерелә.

Бу төр язма чыганаклар, нигездә, тар даирәдә, махсус әлеге чорны өйрәнгән яки тарих белән кызыксынган кешеләргә генә мәгълүм булып, киң катлау укучылар игътибарыннан читтә кала. Тарихи романнарның функциясе һәм әһәмияте дә укучыларга билгеле бер чор, ул чордагы вакыйгалар турында мәгълүмат бирү белән билгеләнә. Тарихи роман тарих фәнен алыштыра алмый, әмма ул ерак үткәндәге вакыйгаларны сурәтләү аша, укучыга халыкның тарихи үткәнен күзалларга һәм бу тарихта үз урынын аңларда ярдәм итә.

Язучы тарихи вакыйгаларны документаль характердагы язма чыганакларга, елъязмаларга, сәяхәтнамәләргә таянып күрсәтергә тиеш. Әмма бу чыганаклар тарихи темага әдәби әсәр иҗат итү өчен нигез булган очракта да, үткән заман турында җитәрлек мәгълүмат бирмиләр. Тарихи роман жанрының үзенчәлекләреннән берсе – тарихи үткәнне әдәби чаралар ярдәмендә сурәтләү. Язучы үзе файдаланган фактик материалны, шул вакыйгаларны, чорның вазгыятен, яшәеш-көнкүрешне мөмкин кадәр тулырак һәм тирәнтенрәк ачу өчен, иҗади тулыландыра. Шул рәвешле, бу төр әсәрләр тарихи һәм иҗади башлангычларның синтезын хасил итә. Фольклорда исә тарихи шәхесләрне сурәтләүдә мифологик, эпик һәм реалистик элементлар үрелеп бара. Һәр әсәрдә берәр элемент көчлерәк була, калганнарына азрак урын бирелә. Дастаннарда да, тарихи риваятьләрдә дә мифологик яки эпик һәм реалистик элементларның нисбәте тотрыклы. Образның фольклорлашу процессы реалистик элементларга, фольклор традицияләренә таянып формалаша, мифологик һәм эпик элементлар төп рольне уйный. Образга аннан алда шул ук функцияне башкарган образларның сыйфатлары күчерелә. Тарихи романнарга килгәндә, биредә төп игътибар иҗади башлангычка бирелә, фольклордан аермалы буларак, сюжетны мавыктыргыч итү һәм образны тулырак ачу максатыннан, фантастик элементлар да очрый. Шул ук вакытта язучылар язма чыганакларга гына түгел, халык иҗатына да мөрәҗәгать итәләр.

Алтын Урда ягъни Җүчи Олысы дәверен тасвирлаган тарихи романнарда, кагыйдә буларак, төп геройлар – Монгол империясенә нигез салган Чыңгыз хан, аның олы улы, Алтын Урданың башында торган Җүчи, Җүчинең олы улы Бату образлары. Шулай ук Бәркә хан, Үзбәк хан, Туктамыш хан образлары да шактый тулы яктыртыла. Әлеге әсәрләр, кайсы дәвердә иҗат ителүләренә бәйле рәвештә, тарихи чынбарлыкны нинди идеалогик яссылыкта яктыртулары белән бер-берсеннән шактый аерыла. Бу яктан караганда, совет дәверенә караган иҗатны бәяләү дә, анализлау да шактый катлаулы. Чөнки Алтын Урда чорын берьяклы гына, төгәлрәге бары тискәре яктан гына бәяләгән совет идеологиясе фикер төрлелегенә урын калдырмый, бу дәүләт белән бәйле күренешләргә карата уңай фикерне уздырмый.

Моңа нисбәтән төрки халыклар, шул исәптән татар һәм казакъ халыклары фольклорының йөзек кашы булган «Идегәй» дастанына мөнәсәбәтне, һәм бу дастан белән бәйле вакыйгаларны искә төшерү дә җитә. Нәкый Исәнбәт 1940 елда «Совет әдәбияты» журналының ике санында «Идегәй эпосының җыелма текстын бастыра [Исәнбәт, 1940]. Анда Идегәй шәхесенә уңай характеристика бирелә һәм Җүчи Олысының (Алтын Урданың) татар халкы тарихына һәм мәдәниятенә зур өлеш кертүе билгеләп үтелә. Шушы вакыйгаларга кайтаваз буларак, ВКП(б) ҮКның 1944 елның 9 августындагы карары чыга. Алтын Урда басып алулар һәм талаулар хисабына яши торган «паразит» дәүләт дип игълан ителә. Шуның белән бәйле рәвештә кабул ителгән карар озак елларга Алтын Урда темасына табу сала: «ВКП (б)ның Татарстан өлкә комитетына Татарстан тарихын фәнни яктан эшләүне оештырырга, аерым тарихчылар һәм әдәбиятчылар тарафыннан җибәрелгән җитди кимчелекләрне һәм милләтчел характердагы хаталарны бетерергә (Алтын Урданы бизәп күрсәтү, Идегәй турында ханнар эпосын популярлаштыру) тәкъдим итәргә». Шул рәвешле «Идегәй» дастаны да, Алтын Урда чоры фольклоры да фәнни контексттан йолкып алына. Советлар берлегендә яшәгән бөтен халыкларның Алтын Урда тарихы белән бәйле фәнни тикшеренүләре, шул исәптән фольклорны өйрәнү дә XX гасырның 90 нчы елларына кадәр туктап кала. Бу табу матур әдәбиятта да чагылмый калмый. Әлеге карарга бәйле рәвештә Алтын Урда дәүләтенең тарихын бозып күрсәтү өстенлек иткән совет дәверенә караган әдәби әсәрнең идея юнәлеше бер генә була ала. Бу – Монгол империясенең һәм алар төзегән Алтын Урданың фәкать басып алучы, ә яуланган территорияләрнең гасырлар дәвамында икътисади һәм мәдәни яктан артта калуына китергән көч булуын исбатларга омтылу.

Без бу мәкаләдә, совет дәвере тарихи романнар авторы Ильяс Есенберлинның «Алтын Урда» трилогиясендә тасвирланган Алтын Урда ханнары образларына тукталабыз. Анализда романда чор вазгыятенә бәйле рәвештә туган каршылыкны да игътибарсыз калдырмаска тырышабыз. Алтын Урда ханнарының язма чыганакларда һәм фольклорда тасвирланган эпик биографияләре белән әлеге шәхесләрнең әдәбиятта тудырылган образларын чагыштырып, уртак якларын һәм үзенчәлекләрен ачыкларга омтылабыз. Алтын Урда ханнарын тасвирлаганда аларның хөкемдар һәм шәхес буларак нинди сыйфатлары ачылуын эпик традицияләр һәм заман идеологиясенә мөнәсәбәттә өйрәнәбез.

Ильяс Есенберлинның «Алтын Урда» трилогиясе 1979 елда башланып, 1983 елда тәмамлана. Бу әсәрнең басылып чыгуы казакъ халкы өчен генә түгел, Алтын Урда варислары булган башка халыклар өчен дә көтелгән вакыйга була.

Ильяс Есенберлин төрки халыклар әдәбиятында беренче тапкыр, әлеге гаять катлаулы чорга караган тарихи материалларны билгеле бер системага салып кулланып, Алтын Урданың чәчәк ату һәм

җимерелү чорын сурәтли. Язучы тарихи вакыйгаларның, ул чордагы шәхесләрнең җанлы образларын тудыра. Алтын Урданың төрки халыкларның этногенезын үстерүдәге һәм аларның булачак дәүләтчелеген булдырудагы ролен күрсәтә.

Автор трилогиядә Алтын Урда хөкемдарлары Чыңгыз ханны, аның уллары Җүчи, Бату, Бәркә ханнарны, бөек гаскәр башлыклары Сүбәдәй-баһадир, Җәбә һәм башкаларны «бөек» дип атауга карамастан, бу шәхесләрнең эш-гамәлләрен уңай яктан гына күрсәтә дип әйтеп булмый. Ильяс Есенберлин – совет чоры әдибе, шуңа бәйле рәвештә, чор идеологиясенә буйсынган рәвештә, бөек ханнарның шәфкать белмәү, икейөзлелек, астыртынлык һәм мәкерлелек кебек сыйфатларын калкытып күрсәтә. Шул ук вакытта, бу хөкемдарларның күпчелеге идарә иткән чорда бердәм дәүләт төзелә, фән-мәгърифәт, һөнәрчелек үсә, ислам дине ныгый, шәһәрләр төзелә, мәдәният үсә, таркау территорияләр берләшә. Трилогиянең күзгә ташланмаган икенче катламында Бөек империя – чәчәк аткан Алтын Урда дәүләтен төзегән ханнарның җимерүче түгел, төзүче булуын да ачып бирә. Тарихи роман авторы буларак, Ильяс Есенберлин да тарихи чыганакларга һәм тарихи мәгълүматларга нигезләнә, тарихи хакыйкать идеологик постулатлардан көчлерәк булып, ул шушы чыганаклар нигезендә татар-монголларның дәүләтчелеккә нигез салган халык булуын да күрсәтә ала.

Автор яулап алу сугышларының никадәр шәфкатьсез, канкойгыч булуларын сурәтләү белән бергә икенче бер күренешне дә игътибарсыз калдырмый. Басып алынган территорияләрнең, шул исәптән Русьның да таркау булуы, үзәкләштерелгән власть булмау, кенәзләрнең үзара тәхет бүлешүе һәм үз араларында барган канкойгыч бәрелешләр, гаять зур территорияләрнең яулап алынуында гына түгел, соңрак та хәлиткеч роль уйный. Бу кенәзләр, бер-берсен юк итәр өчен, Алтын Урда ханнарына якынаерга омтылалар, үзара яу белән чыгалар. Тәхет өчен барган көрәш туктап, Русьның таркау территорияләре берләшкәнгә кадәр, алар Урда ханнары кул астында кала. Шушы таркаулык һәм тәхет өчен барган, Чыңгыз нәселеннән булып, бер-берсенә кул күтәргән тәхет варисларының көрәше, ахырда Алтын Урданың да җимерелүенә китерә. «Алтын Урда» трилогиясенең башында Бату хан улына сөйләгән Алты башлы Айдахар турындагы хикәят романда бәян ителәсе вакыйгаларны хәбәр итә.

Алтын Урда дәүләте төзелү иң бөек империяләрнең берсе булган Монгол империясенә нигез салган Тимучин, ягъни Чыңгыз хан исеме белән бәйле. Чыңгыз ханга багышланган төрки һәм монгол халык иҗатының нигезендә бөек ханның гадәти кеше булмавына инану ята [Закирова, 2011, с. 142–185]. Чыңгыз ханның культын өйрәнүче галимнәр дә аның гадәти булмаган ихтыяр көчен, талантын, популярлыгын ханның харизмасы белән бәйләп аңлаталар [Скрынникова, 1997]. Алла тарафыннан туганда ук бирелгән харизмага бер кеше дә үз тырышлыгы белән ирешә алмый. Харизматик авторитет та

халыкның властька килүченең гадәти булмавына, Алла тарафыннан сайланган булуына инануыннан формалаша. Чыңгыз ханның харизмасы нәселендә кабатланмый, дип әйтергә мөмкин. Беренче буын – улы Җүчи тәхеттә бик аз утырып, аның исеме генә Алтын Урданың икенче исеменә кереп кала, башка ханнар да Чыңгызның данын кабатлый алмый. Шулай да бу ханнарның күбесе Алтын Урда тарихында үз эзен калдыра. Җүчине тарихи чыганаклар көчле полководец буларак сурәтли. Гаять зур территорияләрне буйсындырган Җүчинең максаты яңа яулап алулар һәм басып алынган территорияләрдә халыкны кыру түгел, бәлки андагы халыкка яшәргә дә мөмкинлек бирү, аларны үз олысы халкы итеп күрү була. Тарихи чыганаклар нәкъ менә шушы максатның ата белән ул, ягъни Чыңгыз хан белән Җүчи арасында конфликт китереп чыгаруын фараз итәләр. Алар арасындагы конфликтның сәбәбе Рәшидеддиннең «Җәмигъ эт-тәварих» хезмәтендә дә шул рәвешле аңлатыла [Рашид-ад-Дин, 1952, с. 71–72]. Хәзерге тарихчылар бу мәсьәләдә башка фикердә тора, мәсәлән, И.В. Антонов ата белән ул арасында нормаль мөнәсәбәтләр булуын яза. «Аларны бары һәрьяклап Чагатай бозарга тырыша, ул әтисенең Җүчинең законлы тууы турындагы шикләрен белеп, йогынты ясарга омтыла» [Антонов, 2013, с. 63].

Язма чыганаклар Чыңгыз ханны хөкемдар буларак кына түгел, кеше буларак та сурәтлиләр. Хөкемдарның кешелек сыйфатлары аның гаилә әгъзаларына, бигрәк тә хатыны һәм улларына булган мөнәсәбәтен тасвирлаганда ачыла. Фольклор да, язма чыганаклар да бөек ханга кешеләргә хас хис-кичерешләрнең дә ят булмавын, аның ярата, нәфрәтләнә, кайгыра белүен төрле вакыйгаларга бәйле рәвештә ачалар.

Ильяс Есенберлин «Алтын Урда» трилогиясенең «Алты башлы Айдахар» дигән беренче китабында Чыңгыз хан образын аның оныклары Бату һәм Бәркә ханнар истәлеге һәм хәтере аша тудыра. Бату хан да, Бәркә хан да һәр гамәлләрен бөек бабаларының эшчәнлеге белән чагыштыралар һәм Чыңгыз хан законнарына никадәр яраклашулары турында уйлыйлар. Чыңгыз ханның иң элек Бөек империяне ныгытуга юнәлдерелгән закон һәм васыятьләре оныкханнарга киләчәккә юнәлешне билгеләргә ярдәм итә. Мисалга, Бату хан улы Улакчыга бабасы Чыңгыз хан киңәшләренең гомер буе үзенә ярдәм итүен түбәндәгечә бәян итә: «Кайвакыт бабай миңа киңәшләрен бирә иде. Аларның өчесе тормыш дип аталган төн караңгылыгында якты йолдыз булып юлымны яктыртты. Канлы яу вакытында Чыңгыз ханның киңәшләре йөрәгемне җылытып, үз үземә ышаныч һәм куәт биреп тора иде» [Есенберлин, 1999]. Чыңгыз ханның кануннары (бөек хакимият кануны), алар фәнни әйләнешкә Яса яки Бөек Яса исеме астында кергән, риваятьләр буенча, Бөек корылтайда дөньяга чыгарыла һәм аның варислары тарафыннан даими раслана [Вернадский, 2013, гл. II, § 6]. Яса текстлары хәзерге вакытка килеп җитмәгән, алар турында мәгълүмат фарсы һәм гарәп тарихчылары хезмәтләрендә саклана. Романда Чынгыз хан чыгарган кануннарда, Бөек Ясада, аның тормышка

мөнәсәбәте, дөнья картинасы бәянләнә. Автор Бату ханның да, Бәркә ханның да гамәлләрен дә шушы кануннар аша бәяли: «Чыңгыз хан шулай кушкан иде», «Чыңгыз хан кушканча», «Чыңгыз хан законнары буенча», «Чыңгыз ханның сүзләре шулай иде», «Чыңгыз хан васыятендә әйтелгәнчә».

Ильяс Есенберлинның хан образын тудырганда Бөек Ясага мөрәҗәгать итүе очраклы түгел. Автор бу образны беренче чиратта зирәк акыллы шәхес, бөек стратег буларак тасвирларга омтыла. Чыңгыз ханның үз янына зирәк һәм галим кешеләрне туплавы, алар белән аралашып яшәве, ханның совет эшчәнлегенә, галимнәргә булган игътибары да бу шәхеснең асылын ачарга булыша: «Советка лаеклыларның да иң лаеклылары керде. Аларның зирәклеге һәм фидакярлеге һәркемгә билгеле иде. Совет җыела торган махсус көннән тыш, тугыз орликның (киңәшченең) һәрберсенең галәм хакиме белән әңгәмә кора торган үз көне һәм сәгате билгеләнгән» [Есенберлин, 1999].

Бату хан һәм аның үлеменнән соң Бәркә хан идарә иткән дәвердә дәүләт бөтенлеген саклап калу һәм олысның мөстәкыйльлеген ныгыту сәясәте дәвам иттерелә. Алтын Урданың бу ике ханы да җирдәге бурычларын Чыңгыз ханның эшен дәвам итүдә күрәләр. Бату бу турыда: «Без, Чыңгыз ханның нәсел варислары, бабабыз төзегән бөек монгол ханлыгының һаман үсүе һәм ныгуы турында уйларга тиешбез», – ди [Есенберлин, 1999]. Монгол һәм төрки халыклар яшәү рәвешенең бер асылы – борынгы ата-бабалар культы. Бу – өлкәннәргә, ата-бабаларга хөрмәт, аларның эш-гамәлләре һәм батырлыкларына соклану, уй-фикерләрен һәм эшләрен дәвам итү. Трилогиядә ата-бабалар культы, беренче чиратта, Чынгыз ханга мөнәсәбәттә ачыла. Монгол халыкларының ата-бабалар культы һәм Чыңгыз ханның кануннар җыелмасы – Яса турындагы мәгълүмат фарсы тарихчысы Рәшидеддиннең «Җәмигъ эт-тәварих» хезмәтендә теркәлгән. Ул ата-бабалар культы турында: «Аларның барысының да нәсел шәҗәрәсе билгеле, монголларның гореф-гадәтләре шундый: алар үзләренең ата-бабаларының килеп чыгышын онытмыйлар; һәр яңа туган сабыйга, башкалар әйтмешли, «нәкъ шул милләттән» дигән кебек, аның килеп чыгышын аңлаталар», – дип яза [Рашид-ад-Дин, 1952, с. 13]. Трилогиянең сюжеты белән «Җәмигъ эт-тәварих» хезмәте арасында параллельләр шактый уздырырга мөмкин. Ильяс Есенберлин үзенең «Алтын Урда» трилогиясен язганда, төп чыганакларның берсе буларак, Рәшидеддиннең «Җәмигъ эт-тәварих» хезмәтеннән дә файдаланган.

Трилогиянең «Алты башлы Айдахар» дигән беренче китабында Бату, Бәркә ханнарның идарә итүе, аларның гаиләсе, ханнар арасындагы һәм аларның гади кешеләргә мөнәсәбәте төрле ситуацияләр аша ачыла. Алар арасында XIV гасыр «Юань-чао би-ши», «Мэн-да бэйлу», «Атан тобчи», фарсы тарихчылары Җүвәйни (XIII гасыр), Рәшидеддин (XIII гасыр ахыры – XIV гасыр башы) хезмәтләрендә тасвирланган вакыйгалар да, авторның иҗади фантазиясе тудырганнары да очрый.

Мәсәлән, Барак исеме Алтын Урда тарихында берничә тапкыр кабатланса да, Бату ханның кече улы Барак турында тарихи мәгълүмат сакланмаган. Шуңа күрә, бу дүрт-биш яшьлек баланы бөркет алып китү эпизоды автор тарафыннан Бату хан образын тирәнрәк ачу өчен иҗат ителгән, дип фаразларга мөмкин. Соңгы көннәрен яшәгән Бату хан, шушы трагедия уңаеннан үзенең гамәлләрен барлый, беренче тапкыр ул да үзе халыкка китергән кан-яшьнең ачысын тоя.

Бату исән чакта ук Алтын Урда мөстәкыйльлек ягына авыша, шулай да Җүчи Олысы рәсми төстә империя эчендә яшәгәнлектән, ханнарны каган куя һәм акча да каган исеменнән суктырыла. Бәркә хан хакимлегенең соңында бөек ханлык бәйсез дәүләт була. Бәркә ханның тарихта калган эзе дә шуның белән бәйле. Ул яңа территорияләр яулап алудан бигрәк, булганнарын сакларга омтыла. Бәркә хан идарә иткән чорда Алтын Урдада ислам дине төп диннәрнең берсенә әверелә, исламга күчкән халык арта һәм Алтын Урда бәйсез дәүләткә әйләнә. Ильяс Есенберлин да, ханның төп сыйфаты буларак, идарәнең шушы ягын күрсәтә: «Бәркә хан Бату кылган гамәлләрне кабатламады, ул Урдага яңа җирләрне буйсындырмады, әмма үзе идарә иткән елларда аңа мирас булып күчкәнне саклый белде»; «Бәркә Алтын Урданың көчен генә түгел, аның байлыгын да арттыра алды. Ул сәүдә, һөнәрчелеккә булышлык итте һәм үзенә буйсындырылган җирләрдә яшәүче бер генә кеше дә салымнан котылып кала яки кача алмады. Хәйләкәр, мәкерле Бәркә дөньядан китте» [Есенберлин, 1999]. Үзенең акчасы булган дәүләт кенә мөстәкыйль дәүләт булып санала ала. Алтын Урданың беренче тәңкәләре Бәркә хан вакытында хәлифә Ән-Насретдин профиле белән Болгарда сугыла.

Трилогиянең икенче китабы – «Айдахарның алты башы» Алтын Урданың Үзбәк хан идарә иткән дәверен тасвирлаудан башлана. Тарихи чыганакларда Үзбәк хан иң көчле ханнарның берсе генә түгел, белемле, зирәк акыллы шәхес, хәтта тышкы күренеше белән дә матур, көчле һәм гайрәтле ир-егет буларак тасвирлана. Үзбәк хан идарә иткән еллар Алтын Урданың чәчәк аткан чоры булып, бу ханның үлеме белән, ил дә юкка чыгу ягына атлый.

Ильяс Есенберлинның үз героена мөнәсәбәте шактый каршылыклы. Автор Батуның хан буларак эшчәнлеген гаять югары бәяли: «Үзбәккә кадәр дә, аннан соң да Алтын Урданың мондый кодрәтле, чәчәк аткан чоры булмады, мондый бердәмлекне дә күргәне юк иде» [Есенберлин, 1999]. Ул Бату ханның идарә иткән чорын түбәндәгечә сурәтли: «Шәһәрләрдә һөнәрчелек үсте, дехканнар куркусыз үз кырларына чыктылар, бу елларда беркем дә аларның су аккан арыкларын җимермәде. Үзбәк хан заманында да һөнәрчеләргә дә, дехканнарга да ясак аз салынмады. Алар әүвәлгечә үк югары булып калдылар, остаханәләрдә эшләнгән яки басуларда үстерелгәннең күп өлеше хан казнасына китте. Ләкин кешенең баш очында комсыз һәм шуңа күрә дә аяусыз сугышчының кылычы эленеп тормавын тою тормышны үзгәртте. Үз тормышлары өчен курку китү белән кешеләр үзләрен

бәхетле итеп тойдылар, кечкенәдән дә канәгать булдылар» [Есенберлин, 1999].

Автор Үзбәк ханны хөкемдар буларак никадәр генә югары бәяләмәсен, берничә вакыйгага мөнәсәбәтле рәвештә, аның кеше буларак мәкерле, икейөзле һәм шәфкатьсез булуын да күрсәтә. Сюжет Үзбәк ханның үзенең тәхет көндәшен – Илбасмышны мәкерле рәвештә үтерүен тасвирлау белән башланып китә. Үзбәк ханның Үргәнечтә коралсыз колларны кыру вакыйгасы да ханның төрле була алуын ача.

1341 елда Үзбәк ханның үлеменнән соң, тәхеткә аның олы улы Тәнибәк утыра. Ильяс Есенбирлин Үзбәк ханның өч улы арасындагы вакыйгаларга шактый тәфсилле туктала. Бер ата, бер ана балалары бер-берсен генә үтереп калмый, бер-берсенең яңа туган балаларын да ерткычларча юк итә. Шушы вакыйгалар ук Алтын Урданың һәлакәте якынаюын кисәтә. Урданың ата улны, ул атаны үтергән, кан коюлардан торган этабы башлана. Җанибәк ялгышлык белән кардәшен, яраткан энесе Хызырбәкне үтерә. Тәхеткә утырып өлгергән Танибәк белән Җанибәк арасындагы бәрелештә Танибәк үтерелә. Җанибәк хан дәверендә Алтын Урдада фән-мәгариф системасы алга китә. Мәдрәсәләрдә дөньяви белемнәр укытыла. Хан үз янына галим-голәмәне туплый. Автор, тарихи чыганакларга таянып, Җанибәк ханга югары бәя бирә. Әмма ул да ханнар үтерешкәндә кул җылыткан Түрә бинең мәкере алдында көчсез булып чыга. Үз куллары белән атасын үтергән Бирдебәк тә, бер-берсен алыштырган башка ханнар да Алтын Урда тәхетен бәхетле итә алмыйлар. Алдагы ханны үтереп тәхеткә менгән ханнар арасында да үзенең явыз гамәлләре белән Бирдебәк башкалардан аерылып тора. Татар халкының «Гайсә улы Амәт» дастаны нәкъ шушы шәхесләр арасындагы мөнәсәбәтне бәян итә.

Трилогиянең өченче китабы – «Айдахарның һәлакәте» Алтын Урданың соңгы сәхифәләрен тасвирлый. Тарих сәхнәсенә өч ир күтәрелә. Бу – Аксак Тимер, Туктамыш һәм Идегәй. Бу өч шәхеснең роле дә, урыны да тарихи чыганакларда кат-кат яктыртыла, шушы өч зат Алтын Урданың җимерелүенә сәбәпче була. Ильяс Есенберлин Аксак Тимернең юлбасар буларак башлаган юлын гомере буе дәвам итүен, тәхеткә утыргач та үзгәрмәвен күрсәтә. Автор Туктамыш ханның, тәхеткә менүенә карамастан, идарәгә һәм гомумән бернәрсәгә сәләтсез кеше булуын күрсәтә. Шушы кешенең буш урында барлыкка килгән амбицияләре Урданы соң чиккәчә какшата. Аксак Тимер образын автор төрле яктан ача. Әмма бу образ, никадәр генә явыз шәхесне сурәтләсә дә, көчле, харизматик шәхес буларак ачыла. Харизма, ягъни *кот* сүзен Алтын Урданың башында торган Чыңгыз ханга һәм «явыз даһи» Аксак Тимергә карата кулланып була.

Төрки халыкларның уртак мирасы булган «Идегәй» дастанында да шушы өч шәхес белән бәйле вакыйгалар яктыртыла. Һәм дастан нәкъ Идегәйне дә харизматик, ягъни каты котлы итеп тасвирлый.

Алты олыстан торган Урда – Алтын Урда шул рәвешле тарихтан кичә.

Ильяс Есенберлин «Алтын Урда» трилогиясендә бер-бер артлы тәхеткә менгән һәм дөньядан киткән бөек ханнарның тулы галереясын иҗат итеп, укучыларга тарихның күпләргә билгеле булмаган сәхифәләрен ача. Тарихи чыганакларга таянып, һәр шәхес турында тулы мәгълүмат бирергә омтыла. Ханнарның үзара мөнәсәбәте, башка мәмләкәтләр белән багланышлар, бигрәк тә Русь кенәзләре белән аралашулары тасвирлана. Урданың иминлеге өчен башкарылган гамәлләре тарихи чыганаклар, елъязмалар аша торгызылса, трилогиядә чагылган мәхәббәт тарихлары, хатын-кыз образлары язучының иҗат фантазиясе аша ачыла. Алтын Урданың җимерүче һәм баскын дәүләт булмыйча, прогрессив карашлы, үзе яулап алган территорияләргә дә уңай яңалыклар алып килгән дәүләт булуы хәзерге вакытта галимнәр тарафыннан инкяр ителми. Ильяс Есенберлин шушы хакыйкатьне совет идеологиясенә хилафлык китермичә күрсәтә алган.

**Әдәбият**

*Антонов И.В.* Чингис-хан и Джучи: проблема взаимоотношений // Вестник Челябинского государственного университета. 2013. № 12 (303). История. Вып. 55. С. 58–63.

*Вернадский Г.В.* Монголы и Русь. М.: Ломоносовъ. Серия: История. География. Этнография. 2013 г. 512 с.

*Есенберлин И.* Золотая Орда. Роман-трилогия. Алматы: Фонд им. И. Есенберлина,1999. 428 с.

*Закирова И.Г.* Эпическое творчество периода Золотой Орды: мифологические и исторические основы. Казань, 2011. 268 с.

*Исәнбәт Н.* Татар халык эпосы «Идегәй» дастанының 500 еллыгы // Совет әдәбияты. 1940. № 11. Б. 39–92; № 12. Б. 34–82.

*Рашид-ад-Дин.* Сборник летописей / пер. Л.А. Хетагурова; ред. и прим. проф. А.А. Семенова. М.; Л.: Изд-во АН СССР. 1952. Т. 1. Кн. 2. 317 с.

*Рашид ад-Дин.* Сборник летописей. Т. II. М., Л.: Изд-во АН СССР, 1960. 316 с.

*Скрынникова Т.Д.* Харизма и власть в эпоху Чингиз хана. М.: Издательская фирма «Восточная литература» РАН, 1997. 216 с.

*Публикация статьи осуществлена в рамках выполнения научно-исследовательского проекта АР0 9261068 «Идея государственности и концепция исторической личности эпохи Золотой Орды в контексте художественной литературы»*

*Мәкалә «Әдәбият контекстында Алтын Урда чорының дәүләтчелек идеясе һәм тарихи шәхесе концепциясе» АР0 9261068 фәнни-тикшеренү проектын үтәү кысаларында әзерләнде*

***Закирова Илсөяр Гамил кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

***Даутова Сауле Баттал кызы,***
*филология фәннәре докторы,*
*Казакъ милли педагогия университеты профессоры*

УДК 81′25

***Р.Р. Мусабәкова***

# ТӘРҖЕМӘ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕНӘ КАРАТА: РӨСТӘМ КУТУЙ

В статье рассматривается особенности переводов Рустема Кутуя. В качестве языкового материала использованы произведения татарских поэтов С. Хакима, С. Баттала, Р. Файзуллина и др., а также проза Амирхана Еники. Опираясь на высказывания К. Миннибаева по поводу его переводов, делаются определенные выводы: в чем состоит их особенность и уникальность, что отличает переводы Р. Кутуя от переводов других переводчиков.

**Ключевые слова:** оригинал, художественный перевод, адекватность, вольный перевод, подстрочник.

The article examines the features of Rustem Kutui's translations. The works of Tatar poets S. Khakim, S. Battal, R. Faizullin and others, as well as the prose of Amirkhan Yeniki were used as linguistic material. Based on K. Minnibaev's statements about his translations, certain conclusions are drawn: what is their peculiarity and uniqueness, what distinguishes them from R. Kutui's translations from other translators.

**Keywords:** original, literary translation, adequacy, free translation, word-forword translation.

«Тәрҗемә – кабиләләрне, халыкларны берләштерүгә юнәлтелгән бөек миссияне башкаручы кешеләрнең үзенчәлекле эшчәнлеге. Без аны милли-сәнгати һәм лингвистик тәҗрибә буларак кабул итәбез. Кешелек тәрҗемәне язма тарих дәвамында, бер яктан, мәдәни интеграция, икенче яктан, тәрҗемә юлында киртә булып торган, ерып чыкмаслык күптеллелек йогынтысы астында башкара», – дип яза П.И. Копанев [Копанев, с. 64].

Сәнгати тәрҗемә тарихы бик борынгы заманнарга барып тоташа. Ул Бабил манарасы чорыннан ук кешелекне гасырдан гасырга озата бара. Тәрҗемә тарихы – ирекле һәм сүзгә-сүз тәрҗемәнең соңгы дәрәҗәдәге тәңгәллеккә ирешү омтылышында ярышуы һәм каракаршы торышы. Аерым чорларда я ирекле, я сүзгә-сүз тәрҗемә өстенлек ала. Ләкин XX гасыр тәрҗемә тарихы – тәңгәл тәрҗемәгә ирешү юлында, гадәттә, ике ысулны да кире кагу ул.

Тәрҗемә бер милли әдәбият әсәрен бүтән милли әдәбият әсәренә әйләндерергә ярдәм итә. Ахыр чиктә әдәби әсәр тәрҗемә рәвешендә, башлангыч тел формасыннан аермалы буларак, мөстәкыйль яши башлый. Н.И. Конрад язганча: «...андый үзгәрешләр аркасында, тәрҗемә күпмедер югалта, ләкин күпмедер ота да. Югалтулар арасында – кабатланмас индивидуальлек...» [Конрад, с. 339].

Ирекле тәрҗемә язма практикада примитив сүзгә-сүзлелеккә реакция рәвешендә үзләштерелә, эчтәлекне гади генә бүтән телгә аударуга кайтып кала, ахыр чиктә ул оригиналның тел формасыннан мөстәкыйльлеген тәшкил итә. Шуңа да карамастан, әдәбиятларның эчтәлек ягыннан якынаю чарасы буларак, ул мәдәни кыйммәтләр алмашуда зур роль уйный.

Р. Кутуй иҗатында поэзия һәм проза бер-берсенә комачауламыйча, шул ук вакытта бер-берсен тулыландырып, гаҗәеп тату яши. Шушы ук күренеш аның тәрҗемәләрендә дә чагыла. Р. Кутуй үзен поэзиядә дә, прозада да сыный. Поэзия, гадәттә, тәрҗемә өчен авыр өлкә булып санала, әмма шагыйрь С. Хәким, С. Баттал, Н. Арсланов, Р. Фәйзуллин, Р. Әхмәтҗанов, М. Әгъләмов шигырьләрен тәрҗемә итә. Бу мәкалә кысаларында без аның проза тәрҗемәләренә тукталырбыз.

Язучы һәм тәрҗемәче К. Миңлебаев Р. Кутуй турында болай дип яза: «…шигъри күңелле кеше, үзе искиткеч проза авторы... Аңа кулына оригиналны алу файдасыз: барыбер берни аңламаячак, ул белгән татар сүзләренең саны уннан да артмый – ул замана нәтиҗәсе. Бөтен нечкәлекләрне (әгәр алар анда урын алса) ул бары тик сүзгә-сүз тәрҗемә (подстрочник) буларак кына кабул итә. Оригиналны укыганнан соң, уйлана, һәм ахыр чиктә бөтенләй икенче, яңа әсәр тудыра. Әйе, русча укыганда ул искиткеч матур яңгырый, ләкин бу инде тулаем Еники түгел (дөресен әйткәндә, бу бөтенләй Еники түгел). Бу үзенә күрә бер вариация, Р.Кутуй әсәре, ләкин Ә. Еникигә нигезләнеп, зур осталык куеп язылган вариация…» [Миннибаев, с. 78–79].

Һәр тәрҗемә артында автор гына түгел, ә тәрҗемәче шәхесе дә тора. Р. Кутуй хәреф артыннан түгел, фикер артыннан бара. Тәрҗемәченең интуициясе яхшы эшләргә, автор һәм тәрҗемә арасындагы чикне атлап чыгарга ирек бирмәскә тиеш. Авторның сәләте тәрҗемәченекеннән ким булырга тиеш түгел. Тәрҗемә текстындагы аерым урыннар вакыт-вакыт уйдырмага да барып җитә. Бу урында XIX йөзнең танылган тәрҗемәчесе И.И. Введенский искә төшә, аның турында К.И. Чуковской болай дип яза: «Ни генә булмасын, аның тәрҗемәләре миңа охшый. Әйе, күп хаталар җибәрә, ләкин аннан башка бездә Диккенс булмас иде: өлкән тәрҗемәчеләр арасында ул беренче булып безне аның иҗатына якынайтты, безне аның атмосферасы белән урап алды, аның темпераментын йоктырды... Әйе, уйдырма – һич тә ярамый торган нәрсә, ләкин Введенскийның аерым уйдырмалары текст белән гармония тәшкил итәләр, аларны сызып ташларга кул күтәрелми. Кем белә, Диккенс үзе, әгәр алар аның кулына килеп керсәләр, сызып ташлый алыр иде микән» [Чуковский, с. 546].

Ч. Айтматов: «...Тәрҗемәче, максималь төгәл булып, автор эзеннән барып, аз гына да оригиналдан тайпылмыйча эш итәргә тиешме, яки оригинал белән эш иткәндә, үзен күпмедер дәрәҗәдә ирекле

тотып, тәрҗемә ителә торган әсәргә үзен “кертергә” тиешме?..» – дип сорау куя һәм үзе үк җавабын да бирә: «Мин болай уйлыйм: тәрҗемәче бер генә очракта чын гөнаһ кыла – оригиналның рухын, җанын бозганда, ягъни әсәрнең тема һәм идеясен тышкы яктан охшаш әйберләр белән алыштырганда...» [Айтматов, с. 172–173]. Тәрҗемә мәсьәләсендә Ч. Айтматов күздә тоткан принцип Р. Кутуй иҗатында да күзгә ташлана: ул да оригиналга зыян китерми генә, текстка үзенекен кертә.

Төгәллек принцибыннан, оригиналга якынлык дәрәҗәсеннән чыгып, җөмләләп, абзацлап, бүлекләп тәрҗемәне оригинал белән традицион чагыштыру (Кутуй очрагында) – оттырышлы ысул. Туры килмәү очраклары (төшереп калдыру, өстәмәләр кертү, алмаштыру һ.б.) күп. Билгеле, ул – ирекле тәрҗемәче. Кайвакыт классик дип әйтерлек тәрҗемәдә ситуациянең кискенлеген көчәйтүгә юнәлтелгән образлы мәгънә, тел характеры юкка чыга. Кутуйның исә, киресенчә, болар барысы да өстәмә тирәнлек, үткенлек белән баетыла. Аның тәрҗемәсе – шул ук оригинал, ләкин ул тәрҗемәче йөрәге, хисләре, темпераменты аша уздырылган. Бүтәнчә, ул тәрҗемәгә алынмас та иде. Ул оригиналга якын булу максатын куймый да. Оригинал аның өчен күчереп кую (переложение), күз алдына китерү (видение), трактовка өчен үзенә күрә бер башлангыч пункт кына булып тора. Бу очракта Р. Кутуйның тәрҗемәче генә түгел, ә шагыйрь һәм прозаик, димәк, иҗади шәхес булуы да зур роль уйный. Иҗади шәхес – гади тәрҗемәче генә түгел. Менә кая барып тоташа аның тәрҗемә белән ирекле эш итү тамырлары, чөнки тәрҗемә – ул сәнгать. Р. Кутуй – нәкъ менә шундый тәрҗемәче.

Тәрҗемә практикасында, оригиналга якынрак килү максатыннан, кайвакыт автор сүзләреннән ерак китү хуплана, ягъни тәрҗемәдә сүзгә түгел, ә бәлки фикергә якынаю кирәк. Р. Кутуй да шулай эшли.

«Һәр текст – уникаль әйбер, шул ук вакытта ул бүтән телдән тәрҗемә. Бер текст та тулаем оригиналь була алмый, чөнки тел – ул үзе үк тәрҗемә: беренчедән, ул дөньяны чагылдыра, икенчедән, аның һәр билгесе, һәр фразасы – ул яңа билге, яңа фраза. Ләкин бу фикерне капма-каршыга алыштырып була, һәм ул мәгънәсен югалтмаячак: бар текстлар да оригиналь, чөнки һәр тәрҗемә калганнардан аерылып тора. Һәрбер тәрҗемә күпмедер дәрәҗәдә – уйдырма, һәм бу яктан уникаль текст булып тора» [Октавио, 159].

И.С. Тургеневның «Иң дөрес тәрҗемәдә дә тәрҗемәче рухы сизелеп тора» дигән фикере белән килешми мөмкин түгел. Тәрҗемәче тәрҗемәдә эреп бетәргә тиеш, диләр. Р. Кутуй тәрҗемәләре бу принципка да тулысынча яраша. Хикмәт һич кенә дә аның татар телен белү дәрәҗәсенең аксавында түгел, ә аңа гына хас булган манерада: Р. Кутуй иҗат процессына кереп чума һәм үзе язган кебек тәрҗемә итә. Аның тәрҗемәләрен оригинал текст белән чагыштырып өйрәнгәндә, ирексездән, тәрҗемәченең тәрҗемә белеме дигән фән барлы-

гын белүенә шикләнәсең, чөнки тәрҗемә фәне принциплары, кагыйдәләре аның тәрҗемәләрендә сакланмый кебек. Икенче яктан, бу кагыйдәләрне махсус өйрәнгән булса, Р. Кутуй бер нәрсәне дә тәрҗемә итмәс иде дигән фикер дә туа, чөнки бу белемнәр иҗади шәхеснең кулын бәйләп торырлар иде. Тәрҗемәче хезмәте җиңелләрдән түгел, ләкин Р. Кутуй өчен ул – рәхәтлек дөньясы. Р. Кутуй бу дөньяда эреп, иҗатка чумып, яңа текст барлыкка китерә. Р. Кутуйның тәрҗемә әсәрләрен чын мәгънәсендә ирекле тәрҗемә дип атарга мөмкин.

Ә. Еникиның «Тынычлану» хикәясен һәм «Гөләндәм туташ хатирәсе» романын чагыштыргач, хикәянең романга караганда оригиналга якынрак булуы сизелә. Моның сәбәбе – беренчесенең Р. Кутуй тарафыннан (С. Хозина белән берлектә) тәрҗемә кылуындадыр. Ә икенчесе – Р. Кутуй үзе генә башкарган тәрҗемә. Р. Кутуй жанрын – тәрҗемә-күчереп кую (перевод-переложение), ияру (подражание) дип тә атарга мөмкин булыр иде.

К. Миңлебаев фикерләренә әйләнеп кайтсак, «Автор үзе (Ә. Еники – *Р.М.*), – дип яза ул, – мин аңлаганча, башта бәргәләнде, әсәрләренең һәр тәрҗемәсе хакында, аларның куйган хезмәтләрен бәяләгәндә, берсенә өстенлек биреп, икенчесен үпкәләтүдән шикләнде. Хәтердә, кайчандыр ул Р. Кутуйның поэтик табышларына соклана иде. Ләкин аңа соңрак барып җитте: болар бары тик вариацияләр генә булган икән» [Миннибаев, с. 78–79].

Киләчәктә тәрҗемәче хезмәте югалткан үрләрен кабат кайтарыр, кирәк дип табылыр һәм тиешле дәрәҗәдә бәяләнер дип ышанасы килә. Дөньяда бар нәрсә дә, шул исәптән тәрҗемәләр дә, картая, искерә. Классик әсәрләр 100 елга бер яңадан тәрҗемә ителергә тиеш санала. Моны яңа буын вәкилләренең ихтыяҗлары таләп итә. Күрәсең, Р. Кутуй тәрҗемә иткән әсәрләр яңадан тәрҗемә ителер. Ә бүген алар Р. Кутуй тәрҗемәсендә яши бирәләр, җиңел укылалар, үзләренең төп вазифасын үтиләр – рус телле укучыны татар әдәбиятының иң гүзәл әсәрләре белән таныштыралар.

Әлеге мәкаләдә Р. Кутуйның тәрҗемәләренә бәя бирү максаты куелмады. Шуны ышанып әйтәбез: Р. Кутуй тәрҗемәләренең татар әдәбиятында үз урыны бар, алар үз вазифасын үтәп яши. Бүген аларны үзгәртеп булмый. Элегрәк без студентларга (тәҗрибә рәвешендә) Ә. Еники язган «Тынычлану» хикәясенең ике тәрҗемәче тарафыннан эшләнгән (Р. Кутуй һәм профессиональ тәрҗемәче) биреп карадык. Р. Кутуй тәрҗемәләренең укучыга тәэсирен ачыклау җәһәтеннән бу бик тә әһәмиятле. Нәтиҗә шул: студентлар текстка мавыгып анализ ясады, бәя бирде; алар тәрҗемәләрнең хәтта исемнәре белән дә аерылып торуына («Умиротворение» һәм «Успокоение») игътибар иттеләр; шул ук вакытта профессиональ тәрҗемәченең эшен төгәлрәк тәрҗемә дип таныдылар. Ахыр килеп, Р. Кутуй тәрҗемәләре һәркемне әсир итә, аның иҗаты укучыга һәрьяклап ошый дигән тәэсир кала.

**Әдәбият**

*Копанев П.И.* Вопросы и теория художественного перевода. Минск: Изд-во БГУ, 1972. 295 с.

*Конрад Н.И.* Запад и Восток. М., 1966. 496 с.

*Миннибаев К.С.* Перевод – это искусство. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2004, 196 с.

*Айтматов Ч.* Перевод – дитя любви // Перевод – средство сближения народов. М.: Прогресс, 1987. С. 172–179.

*Октавио Пас.* Перевод // Перевод – средство сближения народов. М.: Прогресс, 1987. С. 160–177.

*Чуковский К.И.* Собр. соч. в 6-ти томах. Т. 3. М., 1966. 646 с.

***Мусабәкова Рәйсә Рәшит кызы,***
*филология фәннәре кандидаты*

УДК 39

*Р.В. Шәйдуллин*

# 2002 ҺӘМ 2010 ЕЛЛАРДАГЫ БӨТЕНРОССИЯ ХАЛЫК САНЫН ИСӘПКӘ АЛУЛАРДА ТАТАРСТАН ХАЛЫКЛАРЫ

Данная статья публикуется в преддверии новой Всероссийской переписи населения, намеченной на октябрь-ноябрь 2021 г., в которой на основе результатов всероссийских переписей населения 2002 и 2010 гг. предпринята попытка системного исследования динамики этнодемографического и языкового развития народов Татарстана. Отмечается, согласно этим переписям, сокращение численности ряда народов республики. При этом утверждается, что в 1970–1980-е гг. доля татар с родным языком своей национальности была одной из высоких по сравнению с аналогичными показателями других национальностей, проживающих в Татарстане. Комплексный анализ этнодемографического и языкового развития коренного населения республики более чем двадцатилетнего периода показал, что идет процесс постепенного сокращения численности башкир, марийцев, мордвы, чувашей и удмуртов и уровня признания ими в качестве родного языка своего этноса не только в Татарстане, но в целом по России. Причиной такого сокращения, возможно, является то, что определенная часть татарстанских народов, православных по своему вероисповеданию, особенно из межэтнических семей, в городах, поселках и населенных пунктах с преобладающим русскоязычным населением стали идентифицировать себя русскими с родным русским языком. Многонациональный состав населения Татарстана, смешанное расселение разных этнических групп, преобладающая языковая среда и тесное языковое взаимодействие способствовало не только формированию своеобразной модели речевой компетенции, но и познанию разных языков индивидами. Такая модель и этнонигилистическое языковое поведение характерна для представителей коренных народов Татарстана, в том числе для татар.

**Ключевые слова:** Россия, Татарстан, переписи населения, народы, национальная принадлежность, родные языки, этнонимы, этнолингвистическая и этнокультурная унификация, ксенофобия, гражданский и политический суверенитет народов, научно-практическая значимость переписей.

In this article, based on the results of the All-Russian population censuses of 2002 and 2010, an attempt is made to systematically study the dynamics of the ethnodemographic and linguistic development of the peoples of Tatarstan. According to these censuses, there is a decrease in the number of peoples of the republic. At the same time, it is argued that in the 1970s and 1980s, the percentage of tatars with their native language of their nationality was one of the highest compared to similar indicators of other nationalities living in Tatarstan. A comprehensive analysis of the ethnodemographic and linguistic development of the indigenous population of the republic for more than twenty years has shown that there is a process of gradual reduction in the number of bashkirs, mari, mordvins, chuvash and udmurts and the level of recognition of their ethnic group as their native language not only in Tatarstan, but in Russia as a whole. The reason for this reduction, perhaps, is that a certain part of

the Tatarstan peoples, orthodox in their faith, especially from interethnic families, in cities, towns and settlements with a predominant Russian-speaking population began to identify themselves as Russians with their native Russian language. The multinational composition of the population of Tatarstan, the mixed settlement of different ethnic groups, the prevailing language environment and close language interaction contributed not only to the formation of a peculiar model of speech competence, but also to the knowledge of different languages by individuals. This model and specific ethnonigilistic language behavior are characteristic of representatives of the indigenous peoples of Tatarstan, including the tatars.

**Keywords**: Russia, Tatarstan, population censuses, peoples, nationality, native languages, ethnonyms, ethnolinguistic and ethno-cultural unification, xenophobia, civil and political sovereignty of peoples, scientific and practical significance of censuses.

Хәзерге Татарстан Республикасы – ул күпмилләтле, моно- һәм полиэтник торак пунктлар арадаш утырган республика; этносларның урнашуында аңа хас факторлар һәм үзенчәлекләр, Татарстан җәмгыятенең этнодемографик структурасындагы (һәрдаим җанлы фәнни һәм иҗтимагый-сәяси дискурста торучы) үзгәрешләр республиканың бүгенгесе һәм киләчәге, аның социаль-икътисади даирәсе, мәдәнияте, дәүләт төзелеше системасы өчен гаять зур әһәмияткә ия һәм алар, шул контексттан чыгып әйткәндә, закончалыклы рәвештә этнолингвистик анализның иң мөһим объектын тәшкил итәләр һәм шул юнәлештәге төрле язмаларга юл ачалар. Шунысын искәртү кирәк, Россия һәм Татарстанның полиэтник киңлекләрендәге милли үзбилгеләнү мәсьәләләре – инде байтактан бирле илебездәге фәнни бергәлекнең [Абрамов, 2008, 2011; Бойко, 2007, 2017; Васина, 2013; Воронцов, 2019; Демографическая история...; Исхаков, 2002; Марийцы, 2013; Мкртчян, 2001; Народы Башкортостана..., 2016; Национальный состав..., 2013; Особенности современной...; Сафин, Мухтасарова, Халиуллина, 2018; Столяров, Тишков, 2013; Татарская нация..., 2002; Шапиева, 2014] игътибар үзәгендәге объект, ә бу – һичшиксез, әлеге проблеманың актуальлеген билгеләүче күрсәткеч. Югарыда санап үтелгән күп кенә фәнни тикшеренүләрдә, этнодемографик һәм этнолингвистик контексттан чыгып, соңгы ике халык санын алу (2002, 2010 елларда) нәтиҗәләре анализлана. Бәхәс объекты буларак, Башкортстанда яшәүче иң күпсанлы милләтләр, аерым алганда, төп милләт вәкилләре – башкортлар мисалында республика халкының социаль-демографик һәм социаль-икътисади хәле тасвирланган мәгълүмати-статистик «Народы Башкортостана в переписях населения» басмасы аерым кызыксыну уята.

Демографик җанисәп материаллары – Россия халкының, аның төбәкләренең үсеш динамикасы һәм торышы буенча кыйммәтле статистик мәгълүмат. Ил халкының этник составын ачыклау күп кенә социомәдәни һәм этносәяси бурычларны хәл итү өчен мөһим. Әлеге мәсьәлә барлык Бөтенсоюз һәм Бөтенроссия җанисәпләре өчен дә диярлек хас. Халыкның этник составын исәпкә алу – (бигрәк тә Россия

кебек күпмилләтле илдә) катлаулы статистик чара. Әлбәттә, җанисәп статистикасында хилафлыклар – күрәләтә юл куелган яки махсус эшләнмәгән хаталар, билгеле бер сәяси конъюнктура яки кеше факторы белән бәйле, алдан ук дөрес булмаган номенклатур һәм этносәяси мәгълүматлар очрый. Мәсәлән, 2010 елгы Бөтенроссия халык санын исәпкә алу вакытында нинди милләттән булу турындагы сорауга 1620 дән артык варианттагы җаваплар алынды [Богоявленский]. Өстәвенә, 2010 елгы халык санын исәпкә алуның рәсми мәгълүматлары буенча, Россия Федерациясендә 193 халык вәкиле яшәгән. Шуңа да карамастан, халык санын исәпкә алу – күпмилләтле Россия җәмгыяте турындагы тарихи һәм социологик белемнәрнең уникаль чыганагы, ул анализларга, нәтиҗә ясарга, планлаштырырга, төпле карарлар кабул итәргә мөмкинлек бирә.

2021 елның октябрь-ноябрендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының өр-яңа тарихында өченче Бөтенроссия халык санын исәпкә алуны үткәрү планлаштырыла. Башта аны 2020 елның октябрендә уздыру күздә тотылды, ләкин ул коронавирус пандемиясе нәтиҗәсендә 2021 елның апреленә, соңрак октябренә күчерелде. Әлеге чараның девизы сыйфатында «Киләчәкне төзибез!» шигаре игълан ителде, бу исә Россиядәге этнодемографик сәясәтнең логик дәвамы булып тора. Җанисәпнең логотибы – «киләчәккә омтылышны һәм халык санын исәпкә алуның яңа санлы электрон форматын гәүдәләндерүче якты образ». 2002 елда Бөтенроссия халык санын исәпкә алуның «Үзеңне Россия тарихына яз!», 2010 елдагысының «Россия өчен һәркем мөһим!» шигарьләре астында уздырылуын хәтерлибез. Россиядә 11 гомуми җанисәп алу үткәрелүе мәгълүм, аларның һәркайсының үз лозунглары һәм бурычлары булган. СССР-да халык санын исәпкә алу мәгълүматларына караганда, ил халкының саны елдан-ел арта барган: 1926 елда – 147 млн, 1939 елда – 170,6 млн, 1959 елда – 208,8 млн, 1970 елда – 241,7 млн, 1979 елда – 262,4 млн, 1989 елда – 286,7 млн кеше теркәлгән [Ермакова]. Шул ук вакытта СССРдагы татар халкы санының да артуы күзәтелә: 1926 елда – 3369,4 мең, 1939 елда – 4314 мең, 1959 елда – 4967,7 мең, 1970 елда – 5930,7 мең, 1979 елда – 6317,5 мең, 1989 елда – 6920,3 мең кеше [Татары..., с. 724]. Шулай итеп, 1926 һәм 1989 еллар арасында, 63 ел эчендә татарлар саны 2 тапкыр арткан (3369,4 меңнән 6920,3 мең кешегә кадәр). Татар халкының еллык табигый үсеше уртача 56,4 мең кеше тәшкил иткән.

Бөтенсоюз халык санын исәпкә алу еллары арасында Татарстанда яшәүче милләтләр саны артуның уңай динамикасы күзәтелде. Иң күп үсеш татарлар, рус һәм чувашларга туры килә. 1989 елда җанисәп алу нәтиҗәләре буенча республикада иң күп халыклар татарлар (1765,4 мең кеше), аннары руслар (1575,4), чувашлар (134,2 мең кеше) булган. Башкорт, мари, мордва һәм удмуртлар Татарстан халкының 0,5– 0,8% тәшкил иткән (1 нче диаграмманы карагыз).

Диаграмма 1

Татарстанда яшәүче җирле халыкларның үсеш динамикасы (1926–1989 еллар) [Республика Татарстан..., с. 12]




Үзгәртеп кору елларында СССР халыкларының этносәяси хөрлеге, сәясиләшү һәм этносларны номенклатур дәрәҗәләргә бүлү принципларына корылган партиячел-бюрократик тозактан арыну процессы башланды. «Суверенлыклар парады» чорында совет сәяси технологларының берничә буыны алга сөргән «СССРда милли мәсьәлә юк, фәкать милли мөнәсәбәтләр генә бар» дигән шактый тотрыклы идеологик стереотип кинәт генә җимерелде. Халыклар арасында үзара ышанычның һәм дуслыкның ныгуы нигезендә совет җәмгыятендә милли һәм социаль үзенчәлекләрнең югалуын, мәдәниятнең, әхлакның һәм көнкүрешнең уртак коммунистик сыйфатларын булдыруны күздә тоткан «милләтләрнең үзара якынаюы» төшенчәсе дә заман сынавын уза алмады. СССР таркалганнан соң, 1990 елларда «этник грюндерлык» дип аталган, ташкын сыман процесс кабынды, ул чакта халыкларның этносәяси суверенлыгын, шулай ук аерым этник төркемнәрне мөстәкыйль этнос буларак рәсми тануны таләп иткән милли хәрәкәтләр һәм оешмалар барлыкка килә башлады. Бериш очракларда алар – халык санын исәпкә алудан юкка чыккан, «онытылган» халыклар, башка очракларда – моңарчы беркайчан да аерым халыклар буларак билгеләнмәгән, моңа әлләни дәгъва да итмәгән этник бергәлекләр.

Б.Н. Ельцин җитәкчелеге Россия халыкларының «суверенлыклар парады»н туктата алмады. Күпчелек автомияле республикалар «милли суверенитетлары турында декларацияләр» кабул иттеләр. Бу

«милли парадның» әйдәп баручылары арасында Татарстан да булды. Хәзерге җитәкчелек көч алгач, яңадан милләтләргә карата сәясәт үзгәрде, бердәм Россия халкын төзү башланды. 1997 елда «гражданнар мәнфәгатьләрендә» яңа паспортларда «милләт» графасы гамәлдән чыгарылды. Күп кенә милли-территориаль берәмлекләрдән бары тик Татарстанда гына паспортларда милләт турында татар телендә язылган аерым кушымта-бит өстәлде. 2000 еллар башыннан милли күрсәткечләр эш башкару һәм статистик документларда исәпкә алынмый башлады. 2008 елда дәүләт статистикасы халыкның саны һәм миграцион хәрәкәте хакындагы мәгълүматларны эшкәртүдән туктады. Хәер, аңарчы да җанисәп чынбарлыкны тулысынча чагылдырмады. Шәхси документларда милләт турындагы язма юкка чыккач, аны гражданлык хәле актларына мәҗбүри яздыру да гамәлдән чыкты. Шул сәбәпле, милләт буенча теркәүнең тулылыгы елдан-ел кими бара: әйтик, 2003–2008 елларда Россия гражданнары арасында туучыларның 44% ында һәм вафат булганнарның 50% ында милләтләре күрсәтелмәде [Богоявленский]. Шул ук вакытта 1989–2010 еллар эчендә Россиядә һәм Татарстанда төп халыклардан булган кайбер фин-угор һәм төрки халыкларның саны арту темпларының сизелерлек кимүе күзәтелә (1 нче таблицаны карагыз, мең кеше).

Таблица 1

Россия һәм Татарстанда яшәүче милләтләрнең үсеш динамикасы 1989, 2002, 2010 еллар Бөтенроссия җанисәпләре буенча [Богоявленский; Республика Татарстан..., б. 12]

| Халыклар | 1989 ел | | 2002 ел | | 2010 ел | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Россия | Татарстан | Россия | Татарстан | Россия | Татарстан |
| Башкортлар | 1345,3 | 19,1 | 1673,4 | 14,9 | 1584,6 | 13,7 |
| Марилар | 643,7 | 19,4 | 604,3 | 18,8 | 547,8 | 18,8 |
| Мордвалар | 1072,8 | 28,9 | 843,4 | 23,7 | 744,2 | 19,2 |
| Руслар | 119 866 | 1575,4 | 115 891 | 1492,6 | 111 017 | 1501,4 |
| Татарлар | 5522,1 | 1765,4 | 5564,9 | 2000,1 | 5310,6 | 2012,6 |
| Удмуртлар | 714,8 | 24,8 | 640 | 24,2 | 554,5 | 23,5 |
| Чувашлар | 1773,6 | 134,2 | 1637,1 | 126,5 | 1435,9 | 116,3 |
| РФдә һәм ТРда барлыгы | 147 022 | 3641,7 | 145 167 | 3779,3 | 142 857 | 3786,5 |

Таблицадагы мәгълүматлардан күренгәнчә, 1989 һәм 2010 еллардагы җанисәпләр арасындагы чорда Россиядә мордвалар саны – 30,7% ка (Татарстанда – 33,6% ка), удмуртлар – 22,4% ка (5,2% ка), чувашлар – 20,1% ка (17,1% ка), башкортлар – 15,1% ка (28,3% ка), марилар – 14,9% ка (3,1% ка), руслар – 7,4% ка (4,7% ка), татарлар 3,9% ка (арту – 11,4%) кимегән. Шул ук вакытта, Россиянең кайбер төп халыклары шактый кимүгә карамастан, россиялеләрнең гомуми саны нибары 2,9% ка (1989 елда 147022 мең кешедән 2010 елда

142857 мең кешегә кадәр) азайган. Татарстанда халык саны 10,4% ка (1989 елда 3641,7 мең кешедән 2010 елда 3786,5 мең кешегә кадәр) арткан. Татарстан халкы артуның уңай балансы, беренче чиратта, республикадагы социаль-икътисади вазгыятьнең тотрыклылыгы, аның мигрантларны, бигрәк тә Урта Азия һәм Кавказ дәүләтләрендәге татарларны, шулай ук әлеге милли-территориаль берәмлекләрдәге төп (титуллы) халыкларны (азәрбайҗаннар, әрмәннәр, казакълар, кыргызлар, таҗиклар, үзбәкләрне һ. б.) җәлеп итүе белән бәйле.

Россиялеләрнең хәзерге шартларда халык вәкиле булу – тумыштан бирелә торган аерылгысыз һәм үзгәрешсез сыйфат. Күп кенә совет документларында милләт турындагы рәсми язма бу фикерне ныгыта килде. Хәтта 1990 елларда Россия паспортында милләт хакындагы язу юкка чыкканнан соң да, этник үзтәңгәллек факторы сәяси мәсьәлә булып кала бирә, халыкның күпчелеге үз милләтен ачыклауда кыенлык кичерми. Әмма милли үзаңнары тәгаенләнеп бетмәгән этник төркемнәр дә бар; алар җанисәп алу вакытында нинди милләттән булулары хакындагы сорауга ара-тирә төрлечә җавап бирәләр. Гадәттә, андый очракларда сәяси технологлар этник тәңгәлләшүнең үзгәрүе турында сүз йөртәләр һәм моны Россия халыклары арасында катнаш никахларның интенсив рәвештә арта баруы белән аңлаталар. Бүген бу – Татарстанның барлык халыклары өчен дә диярлек хас күренеш.

Катнаш гаиләләрдә туган балалар, бер җанисәп алу барышында әниләре милләте буенча язылып, җитлегә төшкәннән соң киләсе халык санын исәпкә алу вакытында үзләрен әтиләренең милләте вәкиле итеп (һәм киресенчә) күрсәтергә мөмкин. Шул ук вакытта Татарстанда милли үзаңнары гаилә этикасының төгәл кысаларына сыймаган этник төркемнәр бар. Шуның ачык мисалы – чиста татар гаиләләрендә шәхси документларда балаларның берсе – татар, икенчесе башкорт буларак язылуы. Исәпкә алу битләрендә дә шундый ук күренешләр күзәтелде. Боларга күрәләтә мәгълүмати һәм административ басым шартларында юл куелды.

Россия Федерациясе халкының 2002 һәм 2010 еллардагы җанисәп алуларда чагылдырылган этник картинасы күптөрлелекле, аның динамикасы еш кына көтелмәгән факторларга бәйле. Аларның мәгълүматларына караганда, Россиядә 100 гә якын төп халык, ягъни төп этник территорияләре илебездә урнашкан халыклар яши. Моннан тыш күбесе Россиядән читтә яшәүче 60 тан артык милләт һәм этник төркем вәкилләре булган. Ил халыкларының саны әһәмияткә ия. Узган алты Бөтенсоюз җанисәбендә алар саны гел үзгәреп торган. 1926 елда – 194, 1939 елда – 97, 1959 елда – 126, 1970 елда – 122, 1979 елда – 123, 1989 елда – 128 халык күрсәтелә [Население России..., с. 67]. 2002 елгы I Бөтенроссия җанисәбенә шартлы рәвештә «кертелгәннәр» дип аталган «аерым» халыклар эчендә этник төркемнәрне аерып күрсәтү хакында принципиаль карар кабул ителде. Шушы яңалык аркасында 2002 елда 776 этник үзатамадан 182 халык (шул исәптән 40 ы «кер-

телгән» халыклар сыйфатында), 2010 елда исә 1620 үзатамадан 193 халык һәм шул сан эчендә 48 «кертелгән» халык бүлеп чыгарылды [Богоявленский]. Өстәвенә, 20 ел дәвамында Россиядә этносларның үзатамалары саны 2 тапкырдан арткан (1989 елда 800 дән 2010 елда 1620 гә кадәр). Бу еллар арасында этник үзатамаларның саны шулкадәр арту һич тә демографик сәбәпләр белән түгел, этник үзбилгеләнешнең этномәдәни факторлары сәясиләштерелү белән аңлатыла. Шул ук вакытта җанисәп алу кәгазендә милләтне күрсәтмәгән затлар саны моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә – 362,8 тапкыр (1989 елда 15513 кешедән 2010 елда 5629429 кешегә кадәр) арткан [Богоявленский]. Соңгы җанисәпләрдә үз милләтен күрсәтмәгән затлар санының нык артуын аңлату җиңел түгел. Әлеге катлаулы мәсьәлә көтелмәгән аяныч нәтиҗәләргә китерергә мөмкин.

Кайбер россиялеләрнең этнонигилистик протест йөзеннән һәм «акыллы башлылык» күрсәтеп, җанисәп кәгазендәге «милләт» графасында мәгънәсез «хоббитлар» яки «неандерталецлар» дип язулары хәзерге сәяси технологлар тегермәненә су коюга тиң. Чынлыкта исә бу – милли мәнфәгатьләргә йөз чөерүдән, милли үзенчәлектән, ата-бабалар мәдәниятеннән һәм традицияләреннән баш тартудан гыйбарәт космополитизм чагылышы. Бу күренеш җанисәп кәгазендәге сорауны шул рәвешле җаваплау зур милләтләрнең үзтәңгәлләшү процессы өчен куркыныч тудырмаса да, аерым гражданнарның шундый битараф гамәлләре аз санлы халыкларның киләчәгенә зур хәвеф китерү белән яный, чөнки милли үзенчәлек онытылу белән аларның милли телләре дә югала, туган тел урынына кулланышка рус теле керә. Моның төп сәбәпчесе – бүгенге телләр вазгыяте; хәзерге вакытта ил халыклары 277 телдә һәм диалектта сөйләшсәләр дә, шулардан нибары 105 тел генә дәүләт мәгариф системасында файдаланыла, шул исәптән 24 тел – укытудагы тел сыйфатында кулланыла, 81 е исә мәктәпләрдә предмет буларак өйрәнелә [Россия Федерациясе Президентының «Россия...].

Мәгариф системасында милли телләрне куллану дәрәҗәсе һәм аларның формалары Россия Федерациясенең рус булмаган халыкларның күпчелеге туган телләрендә тулы күләмдә белем алмавын дәлилли. Моның сәбәбе – үзенчәлекле ксенофобия, ул күп кенә сәясәтчеләр, мәдәният вәкилләре аңында яшәп килә. Россиянең кайбер сәясәтчеләре этник һәм социаль инстинктларны дәүләт бердәйлеген, төп рус этносының мәнфәгатьләрен саклау һәм яклау өчен бердәм «Россия милләте»н булдыру буенча дәүләт сәясәте чаралары сыйфатында кулланалар. Яманаты чыгарылган «милләтчелек янавы»на карата хакимият еш кына чит телнең һәм этник мәдәниятнең русларга йогынтысын чикләү һәм мөселман халыкларының милләтчелегеннән өркү кебек бер-берсен тулыландырган «тыюлар» системасын файдалана. Биредә руслашу һәм катнаш никахлар да, мәктәптә укытуның түбән дәрәҗәдә булуы һәм милли мәктәпләрнең ябылуы белән бәйле рәвештә телнең позицияләре йомшару да үз ролен уйный.

Россия хакимиятенең шундый сәясәтенең этномәдәни нәтиҗәләренең берсе – ил халыкларының интенсив руслашуы (2 нче таблицаны карагыз).

Таблица 2

Россиядә җирле кайбер Идел Урал буе халыкларының туган телләре күрсәткечләренең 1989 һәм 2010 еллардагы динамикасы [Социально-демографический..., с. 79–80].

| Халыклар | Туган тел турындагы сорауга җавап биргән 1000 кешедән туган тел дип санадылар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | милләткә тәңгәл тел | | рус теле | | башка тел | |
| | 1989 ел | 2010 ел | 1989 ел | 2010 ел | 1989 ел | 2010 ел |
| Башкортлар | 728 | 716 | 101 | 137 | 171 | 147 |
| Марилар | 819 | 747 | 178 | 250 | 3 | 3 |
| Мордвалар | 690 | 647 | 308 | 352 | 2 | 1 |
| Татарлар | 856 | 792 | 142 | 205 | 2 | 3 |
| Удмуртлар | 798 | 622 | 289 | 377 | 3 | 1 |
| Чувашлар | 775 | 709 | 223 | 290 | 2 | 1 |

1989 һәм 2010 еллардагы җанисәпләр нәтиҗәләре җавап бирүчеләрнең туган телләрен билгеләү-танудагы үзгәрешләрне ачык чагылдыра: таблицада күрсәтелгән алты халык арасында рус телен үзләренең туган теле итеп санаучыларның өлеше арткан. Иң зур күрсәткечләр татар арасында күзәтелә; рус телен туган тел сыйфатында күрсәтүчеләр – 44,3% ка, мариларда – 40,4% ка һәм башкортларда 35,6 % ка күбәйгән. Рус телен туган тел дип удмуртларның, мордваларның һәм чувашларның өчтән бер өлеше чамасы атаган. Милләткә тәңгәл телне туган тел буларак таныган затлар өлеше татарлар (79,2%), марилар (74,7%) һәм башкортлар (71,6%) арасында аеруча югары. Шул ук вакытта һәр 1000 башкортка башка телләрдә сөйләшүчеләрнең шактый зур өлеше туры килеп, әлеге күрсәткеч 14,7% тәшкил итә. 1989 һәм 2010 еллар аралыгында аларның саны 1,2 тапкыр (171 кешедән 147 кешегә кадәр) кими. Бу күренеш Башкортстанда яшәгән татарларны башкорт итеп яздыру һәм, өлешчә, Россиянең башка төбәкләрдәге татарларның руслашуы нәтиҗәсе булса кирәк.

Хәзерге Россиядә рус теле кабат төп берләштерүче факторга әверелә, әмма ул һәрвакытта да илнең башка төп халыкларының этномәдәни, рухи һәм сәяси мәнфәгатьләре белән туры килеп бетми. Ел саен туган телен белүче татарлар азая бара. Аерым алганда, Россиядә сан җәһәтендә икенче урынны биләүче халык булган татарларның нибары 68,6% ы (5,31 млн кешедән 3,64 млн кеше) гына туган телдә сөйләшә [Тем временем в Татарстане...]. Татарстанда рус теле белән беррәттән татар теле дә дәүләт теле булуга карамастан, республикада да татарча сөйләшүче татарлар санының кимүе күзәтелә.

Рус халкы белән чагыштырганда, милли республикадагы титуллы халыкның тел, рухи һәм сәяси тормыш-эшчәнлегенең аерым

өлкәләрендә хокукларны чикләүче юридик нормалар да интенсив рәвештә руслашуга булышлык итә. Шундый юридик нормаларның берсе – 2012 елда кабул ителгән «Россия Федерациясенең дәүләт милли стратегиясе»; аның нигезендә «Россия Федерациясе күпмилләтле халкының («Россия милләте»нең) гомумроссия гражданлык үзаңын һәм рухи бергәлеген» ныгыту идеясе ята [Социально-демографический...]. Россия милли иминлек стратегиясе «Гомумроссия гражданлык бердәйлеге барлык халыкларга хас рус мәдәни доминантасын (өстенлеген. – *Р.Ш.*) саклауга нигезләнә» аксиомасына таяна [Россия Федерациясе Президентының 2012...]. Әлеге дәүләт стратегиясенең көтелгән нәтиҗәләренең берсе – «Россия Федерациясе күпмилләтле халкының (Россия милләтенең) бердәмлеген һәм гомумроссия гражданлык бердәйлеген ныгыту, илнең бердәм мәдәни киңлеген формалаштыру» [Россия Федерациясе Президентының 2012...].

Шулай итеп, халык санын алу – уникаль тарихи вакыйга. Сан алуларның нәтиҗәләре бергә караганда илнең, төбәкләрнең һәм шунда яшәүче халыкларның үсеш елъязмасын хасил итә. Бу – миллионлаган ватандашларыбызның һәм милләттәшләребезнең язмышлары кушылып үрелгән җыелма тарихи документ. 2002 һәм 2010 елларда уздырылган Бөтенроссия җанисәпләре мәгълүматларын тикшереп, түбәндәге нәтиҗәгә килергә мөмкин: аларның нигезенә ил халыкларын эзлекле рәвештә этнолингвистик бердәйләштерү һәм киләчәктә бер үк телгә һәм мәдәнияткә ия «Россия халкы»н («рус милләте»н) булдыру сәясәте яткан державачыл номенклатур күрсәтмәләр салынган. Материаллар шулай ук халык санын исәпкә алулар максатларының билгеле бер сәяси ниятләрне күздә тотуын, сәяси технологларның беренчел документлар (җанисәп кәгазьләре) белән түбән дәрәҗәдә ихлас эш итүләрен һәм этнослар турындагы мөһим статистик нәтиҗәләрнең номенклатур рәвештә билгеләнүен күрсәтә. Шуңа да карамастан, җанисәп материаллары аз һәм зур санлы халыкларның этник тәңгәллеген саклау һәм үстерү параметрларын эшләү мөмкинлеген бирә, шулай ук аерым этнослар арасында барган иҗтимагый-сәяси һәм этнолингвистик шаукымнарны басарга, Россия бөек державачыл шовинизмы ташкынын туктатырга һәм халыкларны сәяси җәһәттә «уллар»га һәм «үксезләр»гә бүлү сәясәтенә чик куярга җирлек тудыруга сәләтле.

**Чыганаклар һәм әдәбият**

*Абрамов В.К.* Демографическая динамика мордовского населения России в XX в. // Финно-угорский мир. 2011. № 1. С. 64–61.

*Абрамов В.К.* Динамика численности мордовского народа по материалам переписей 1926–2002 гг. // Проблемы новейшей истории и этнографии финно-угров России: Балашовские чтения. Саранск, 2008. Вып. 2. С. 4–17.

*Богоявленский Д.Д.* Перепись 2010: этнический срез [Электрон ресурс]. Режим доступа: http://www.perspektivy.info/print.php?ID=193983 (файдалану датасы: 05.02.2021).

*Бойко И.* Перепись 2002 года в Чувашской Республике: этническая и языковая идентичности // Лик. 2007. № 3. С. 98–110.

*Бойко И.И., Долгова А.П., Харитонова В.Г.* Этнокультурные предпочтения, родные языки населения Чувашии // Этнокультурное содержание образования, российская идентичность и гражданское согласие в Приволжском федеральном округе. Экспертный доклад / ред. В.А. Тишков, В.С. Воронцов, В.В. Степанов. М.; Оренбург; Ижевск: Ин-т компьютерных исследований, 2017. С. 127–147.

*Васина Т.А.* Динамика численности удмуртов в структуре населения Татарской АССР и Республики Татарстан в XX – начале XXI в. // Финно-угорский мир. 2013. № 3. С. 105–110.

*Воронцов В.С.* Этнический состав населения Удмуртии (по материалам переписей населения 1989 2010 гг.) // Этнопанорама. 2012. № 3–4. С. 64–66.

*Воронцов В.С.* Этнолингвистические характеристики жителей Удмуртии (по данным переписей населения) // Вестник Удмуртского университета. Социология. Политология. Международные отношения. 2019. Т. 3. Вып. 4. С. 516–522.

Демографическая история России и регионов: Динамика численности городского и сельского населения России / Межрегиональный научный сборник. Сыктывкар, 2018. 160 с.

*Ермакова С.* Население СССР по годам: переписи населения и демографические процессы [Электронный ресурс]. Файдалану режимы: https://www.syl.ru/article/367896/ (файдалану датасы: 30.01.2021).

*Исхаков Д.М.* Перепись населения и судьба нации // Татарстан. 2002. № 3. С.18–23.

Марийцы. Историко-этнографические очерки. Изд. 2-е, доп. Йошкар-Ола, 2013. С. 145–147.

*Мкртчян Н.В.* Динамика населения регионов России и роль миграции: критическая оценка на основе переписей 2002 и 2010 гг. // Известия РАН. Серия географическая. 2001. № 5. С. 28–41.

Народы Башкортостана в переписях населения: статистический сборник: в 2 ч. / А.М. Ганиев, Р.Ш. Гатауллин, И.Б. Утяшева и др.; Территориальный орган Федеральной службы государственной статистики по Республике Башкортостан (Башкортостанстат). Уфа: Китап, 2016. Ч. 1. 2016. 329 с.; Ч. 2. 341 с.

Население России за 100 лет (1897–1997): Стат. сб. / Госкомстат России. М., 1998. 222 с.

Национальный состав и владение языками, гражданство: Статистический сборник по итогам Всероссийской переписи населения 2010 года – Казань: Издат. центр Татарстанстата, 2013. Т. 4. 162 с.

Особенности современной межнациональной и этнокультурной ситуации в Республике Татарстан. Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2008. 236 с.

Республика Татарстан: Природа, история, экономика, культура, наука / Ин-т татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ. 2-е изд., доп. Казань, 2015. 194 с.

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең 2025 елга кадәрге чорга Дәүләт милли сәясәте стратегиясе турында» 2012 ел 19 декабрь №1666 Указы [Электрон ресурс]. Файдалану режимы: http://www.kremlin.ru/acts/bank/36512/page/ (файдалану датасы: 20.01.2021).

*Сафин Ф.Г., Мухтасарова Э.А., Халиулина А.И.* Этнодемографические и этноязыковые проблемы чувашского населения Башкортостана // Вестник Чувашского университета. 2018. № 4. С.152–164.

«Россия Федерациясе Президентының 2012 ел 19 декабрь №1666 Указы белән расланган Россия Федерациясенең 2025 елга кадәрге чорга Дәүләт милли сәясәте стратегиясенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 ел 6 декабрь. № 703 Указы [Электрон ресурс]. Файдалану режимы: http://www.kremlin.ru/acts/bank/43843 (файдалану датасы: 20.01.2021).

Социально-демографический портрет России: По итогам Всероссийской переписи населения 2010 года / Федер. служба гос. статистики. М.: ИИЦ «Статистика России», 2012. 183 с.

*Столяров В., Тишков В.* Этническое измерение переписи – 2010 // Этнодиалоги. 2013. №1 (42). С.31 – 37.

Татарская нация: история и современность / Академия наук Татарстана. Ин-т истории им. Ш. Марджани; науч. ред. и сост. Д.М. Исхаков. Казань: Магариф, 2002. 222 с.

Татары. Приложения // Татарская энциклопедия. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2010. Т. 6: Р–С–Т. 736 с.

Тем временем в Татарстане отменяют татарский язык [Электрон ресурс]. Файдалану режимы: https://rusinfo.info/24-10-17/73301-otmena-tatarskogo-yazyka-v-shkolah-2017-poslednie-novosti-za-oktyabr.html (файдалану датасы: 30.01.2021).

*Шапиева Н.Н.* Этнодемографические процессы у восточных марийцев во второй половине XX – начале XXI в. // Исторические, философские, политические и юридические науки, культурология и искусствоведение. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота, 2014. № 10. Ч. 1. С. 200–203.

***Шәйдуллин Рафаил Вәли улы,***
*тарих фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының энциклопедистика үзәге мөдире*

УДК 394.9

***А.Н. Рәсүлов,***
***Р.А. Рәсүлова***

# ТАТАРЛАР ТӨРКЕСТАН АВТОНОМИЯСЕНДӘ (1917–1918 еллар)

В статье освещаются факторы формирования, развития и ликвидации Туркестанской автономии, деятельность татар в системе управления автономией, формы их материальной и моральной поддержки через национальные общественные организации новому государственному образованию.

**Ключевые слова:** татарское общество, автономия, Шураи Ислам, «Иттифақ», федерация, Дом свободы, «Жәмияти исламия».

The article describes the factors of formation of Turkestan autonomy, the activity of Tatars in the system of autonomy and their attitude to it. Attention is also drawn to the attitude of the region's Muslims to the Turkestan autonomy.

**Keywords:** Tatar society, autonomy, Shuroi Islom, Ittifoq, Federation, freedom House, Zhamiyati islomiya.

1917 елгы Февраль революциясе турындагы хәбәрне Россиянең ерак төбәге саналган Төркестанда башта халыктан яшерәләр, һәм ул биредә нибары 3 мартта гына игълан ителә. Соңгы генерал-губернатор А.Н. Куропаткин (1916–1917), Россия императоры Николай II нең тәхеттән ваз кичүе турында Манифест игълан ителгәнче, хакимият кабат торгызылыр дип өметләнә. Төркестанның киң җәмәгатьчелеге һәм зыялылары Февраль революциясен шатланып каршылый. Революция төбәкнең төрки-мөселман халыклары арасында демократик процесслар башлануга өмет уята. Аерым алганда, татарлар Февраль революциясен хуплыйлар һәм илнең төрле төбәкләренә, Вакытлы хөкүмәткә һәм Дәүләт Думасына телеграммалар җибәрәләр. Мәсәлән, Кокандта татар җәмгыяте Вакытлы хөкүмәтне шатланып кабул итә һәм чын күңелдән башлаган эшне тәмамлауларын тели, Казалыдан килгән белдерүдә «без, татарлар, шулай ук сезгә милли һәм дини чикләүләрдән азат итүегез өчен ихлас рәхмәтебезне белдерәбез» [Усманова, 1997, с. 168–169] диелгән.

Февраль революциясеннән соң Төркестанның иҗтимагый-сәяси тормышында милли зыялыларның төрле катлаулары үз хокукларын, сәяси ирекләрне, дәүләт корылышын, мәдәният һәм мәгариф өлкәләрендә реформалар үткәрүне яклап актив чыгыш ясый башлый. Татарлар аеруча актив булулары белән аерылып торалар. Мәсәлән, 1917 елның 14 мартында Ташкентта «Шураи Ислам» җәмгыятенең беренче оештыру җыелышында өстәмә рәвештә 48 җирле халык вәкиле, шул исәптән 13 татар һәм казакъ сайлана. Анда барлыгы 61 кеше исәпләнә. Бу җәмгыять Төркестан мөселманнары арасында

сәяси, фәнни һәм социаль реформалар үткәрү, ил халыклары арасында низагларны һәм каршылыкларны бетерү, аларның бер-берсе белән якынаю мәсьәләләрен күтәреп чыга. «Шураи Ислам» җәмгыяте, үз эшчәнлегенең дәрәҗәсен күтәрү максатында, исемен «Төркестан Шураи Ислам җәмгыяте» дип үзгәртә. Әлеге җәмгыять үз эшчәнлегендә төбәк масштабы белән генә чикләнеп калмый, Үзәк Россиядәге «Алаш», «Иттифак» (җитәкчесе Б. Шәрәф) татар-башкорт җәмгыятьләре белән дә багланышлар урнаштыра [Иттифоқ жамияти]. 1917 елның 4 апрелендә Ташкенттагы рус-татар мәктәбе бинасында узган җыелышта, Төркестанда татар зыялыларының гражданлык статусын күтәрү максаты белән, «Иттифак» җәмгыяте оештырыла [Туркестан в начале..., с. 21–22; Ўзбекистон совет.., б. 24; Абдурашидханов, 2003, б. 43–44].

1917 елның 14 маенда әлеге җәмгыятьнең гомуми җыелышында аның Уставы кабул ителә, шулай ук яшерен тавыш бирү юлы белән Хәйрулла Рәхмәтуллин, Әбдерәшидов, Хәлил Ширинский, Абдуллаҗан Сәфәров, Ибраһим Таһири, Рәхим Ногманов, С. Нуреддин, Сабирҗан Йосыпов, Рәхимҗан Худайбиргәнов, Искәндәр Чанышев, Әбдерәхим Әбдехаликов, Садыйк Габдесаттаров, Кадыйр Булатов, Шәмседдинов, Гази Юнысов һ.б. составында аның җитәкчелеге раслана, барлыгы 21 кеше сайлана.

Төркестанның иҗтимагый-сәяси тормышында татарларның актив катнашуы 1917 елның 26–28 ноябрендә узган Төркестан мөселманнарының чираттан тыш IV корылтаенда да сизелә. Корылтай Төркестан автономиясен игълан иткәннән соң, аның идарә системасына түбәндәгеләр кертелә: Автономия парламенты – Халык Җыелышына татар һәм башкортлардан Ислам Шаһиәхмәтов, Абдулла Дорбисалин, Муса Акчурин, Мостафа Мансуров, Ибраһим Дәүләтшин, Хәлил Ширинский һәм Сабирҗан Йосыпов.

Төркестан автономиясенең Милли җыелышы идарәсе составына Гобәйдулла Хуҗаев, Ташпулат Норбутабәков һәм Мәхмүдхуҗа Бәхбуди белән бергә казакъ Мостафа Чокаев һәм татарлар Муса Акчурин, Ибраһим Дәүләтшин һ.б. керә. Төркестан автономиясе игълан ителү хәтта татар шагыйре Сәгыйть Сүнчәләйне дә битараф калдырмый, аның «Мохтарият кайтавазы» шигыре 1917 елның 16 декабрендә «Олуг Төркестан» газетасында басылып чыга [Турдиев, 1997, с. 179]. Төркестан автономиясе Вакытлы хөкүмәте премьер-министры Ислам Шаһиәхмәтов Төркестан Мөселманнар Советы Үзәк аппараты рәисе дә була [Аъзамхўжаев, 2000, б. 130; Ўзбекистон совет.., б. 53–54]. Шул ук вакытта Абдулла Гайнуллин Төркестан автономиясенең хәрби ведомствосында эшли [Ражабов, Ҳайдаров, 2002, б. 21].

Төркестан автономиясенең эшчәнлеге чыннан да игътибарга лаек. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында Россия империясе хакимияте астында булган төрки-мөселман халыклары арасындагы сәүдә, иҗтимагый-сәяси, мәдәни һәм мәгариф өлкәсенә караган багланышларның үзара аерым

бер якынлыгы күзгә ташлана. Чөнки төрки-мөселман халыкларының тел берлеге, дини бердәмлек, мәдәни якынлыгы аларга бер-берсенә омтылырга һәм хезмәттәшлек урнаштырырга этәргеч була. Шулай ук шунысын да исәпкә алырга кирәк: әлеге төрки-мөселман халыкларының кайберләре йөз еллар буена патша Россиясе хакимияте астында яшәсә, башкалары берничә дистә еллар дәвамында гына сәяси ирекләрен югалткан була. Шул сәбәпле үзбәк, казакъ, татар, кыргыз, башкорт халыклары арасында төрки бердәмлек, бер-берсенә ярдәм итү теләге көчле була. Февраль революциясеннән (1917) соң барлыкка килгән демократик процесслар нәтиҗәсендә бу төрки бердәмлек хисе тагын да алгырак планга күчерелә.

Төркестан автономиясе идарәсе системасында мөһим роль уйнаган дәүләт эшлекләләре арасында татар халкы вәкиле – Шаһиислам Солтан Шаһиәхмәтов та бар. Ул Оренбургта туса да, «башкорт стипендиаты» буларак, Петербург университетының юридик факультетында укыган һәм аны 1910 елда тәмамлаган. Ул 1916 елдан Кокандта профессиональ юрист булып эшли һәм иҗтимагый эшчәнлек белән шөгыльләнә, «Гайрәт» мәгърифәтчелек җәмгыяте секретаре һәм Төркестандагы «Русские ведомости» газетасы корреспонденты буларак хезмәт куя. Ислам Солтан Шаһиәхмәтов төрки мөселманнарның иҗтимагый-сәяси тормышында, бигрәк тә төрки халыклар арасында милли-территориаль һәм дини-мәдәни автономияләр формалашкан чорда милли-мәдәни автономия тарафдары булган (сәяси карашлары буенча ул – федералист). Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, И.С. Шаһиәхмәтов 1917 елның язынннан Бөтенроссия сәяси тормышында да актив катнаша башлый. Аерым алганда, 1917 елның март урталарында, Санкт-Петербургта Бөтенроссия мөселман хәрәкәтендә булу белән бергә, апрель-июнь айларында Төркестан крае мөселманнары шурасы эшендә дә катнаша, Мөселманнарның беренче Бөтентөркестан корылтаенда президент итеп сайлана, ә корылтай карары нәтиҗәләре буенча, 1917 ел ахырында Төркестан крае мөселманнары шурасы рәисе була. Шулай ук 1917 елның июлендә мөселманнарның Казанда узган II Бөтенроссия корылтаена Төркестаннан вәкил итеп җибәрелә, ә июль-августта мөселманнарның Бөтенроссия Милли шурасы эшендә башта секретарь, аннары рәис вазифаларын үти [Акбаров, 2019, б. 235–254].

И.С. Шаһиәхмәтовның югарыда телгә алынган эшчәнлеге аның Россиянең төрки-мөселман халыклары тормышы белән яхшы таныш булуын, шул ук вакытта, юрист һәм мөселман хәрәкәте лидерларының берсе буларак, Төркестандагы социаль-сәяси һәм икътисади вазгыятьтән яхшы хәбәрдарлыгын күрсәтә. И.С. Шаһиәхмәтов яңадан Оештыру җыелышына сайлау кагыйдәләре буенча фикер алышуда актив катнашып, 1917 елның көзендә ул Фирганә өлкәсеннән делегат итеп сайлана. Нәкъ менә 1917 елның көзеннән ул Төркестан федераль автономия алу проектының актив тарафдарына әйләнә. 1917 елның 8–11 сентябрендә узган Төркмәнстан мөселманнарының II корыл-

таенда ул «Төркестан Федерациясе проекты» идеясен Гомумроссия Оештыру җыелышында тикшерү өчен тәкъдим итә. Бу проект Төркестан автономиясенең беренче «конституцион проекты» булып тора һәм 27 статьяны үз эченә ала. Төркестан мөселманнарының II корылтаенда И.С. Шаһиәхмәтов президиум әгъзасы итеп сайлана. Ул шулай ук, сәяси аңны арттыру өчен, Төркестан мөселманнары тормышында массакүләм мәгълүмат чараларын нәтиҗәле куллану максатка ярашлы булыр иде, дигән нәтиҗәгә килә. Чөнки XX гасыр башыннан Төркестанда җирле интеллигенция тормышында матбугат мөһим роль уйный башлый. Газеталарда басылып чыккан мәкаләләрдә теге яки бу дәрәҗәдә төрки-мөселман халыкларының тормышы, көнкүреше, тарихы, икътисади хәле яктыртыла. Мәсәлән, 1917 елның 18 ноябрендә, Төркестан автономиясе игълан ителүгә берничә көн кала, «Олуг Төркестан» газетасында аның «Төркестанның автономиясе һәм икътисади автономиясе» дигән мәкаләсе басыла, автор крайда автоном идарә итү өчен барлык шартларның да җитәрлек булуын нигезли. Ул мөселманнарның 1917 елда узган чираттан тыш IV Бөтентөркестан корылтаенда актив катнаша һәм 28 ноябрьдә оештырылган Төркестан автономиясе Хөкүмәтенең премьер-министры вазифасына билгеләнә. Шулай ук, 1917 елның декабреннән башлап ул Төркестан автономиясе Хөкүмәтенең финанс министры була һәм автономия хөкүмәте аның җитәкчелегендә 30 миллион сумлык заём облигацияләре чыгара һәм әлеге облигацияләрнең 10 миллион сумлык өлешен Коканд банклары каплый. Әйтергә кирәк, бу облигацияләр үз вакытында Төркестан автономиясенең финанс мәсьәләләрен хәл итүдә мөһим роль уйный [Акбаров, 2019, б. 254].

И.С. Шаһиәхмәтов тарафыннан Төркестан мөселманнарының II корылтае өчен әзерләнгән 27 статьядан торган «Төркестан Федерациясе проекты»н автономиягә бару юлында кыю адымнарның берсе дип карарга мөмкин [Мингнаров, 2002, б. 44]. Бу проектта Төркестан крае Җирле һәм милли автономия нигезендә Россия республикасы составына кертелергә, барлык халыклар, ир һәм хатын закон каршында тигез булырга, һәр гражданинга вөҗдан иреге хокукы бирелергә тиеш, дип белдерелә [Акбаров, 2003, б. 96].

Төркестан автономиясен игълан иткәннән соң, крайның барлык җирле халкы белән беррәттән, татар милләтенең прогрессив карашлы зыялылары да зур энтузиазм белән эшкә тотынган. Әндиҗан шәһәрендә яшәгән татарлар 1917 елның 3–4 декабрендә Төркестан автономиясе бәйрәмен билгеләп үтәләр, шул рәвешле төрки-мөселман халыкларының автономияне үз итүен белдерәләр. Шул ук вакытта, 4 декабрьдә, өлкән буын татарлар гына түгел, ә мәктәп яшендәге балалар да «Иттифак» җәмгыяте бинасында бәйрәм оештыралар. Шулай ук 4 декабрьдә «Иттифак» җәмгыяте әгъзалары, мәктәп укучылары һәм мөселман сугышчылар, бергәләп, иске шәһәргә киләләр, автономия игълан ителү уңаеннан, музыка авазлары астында Әндиҗан татарлары исеменнән җирле халыкны сәламлиләр. Бу вакыйгалар илдә

яшәүче һәм армиядә хезмәт итүче, иҗтимагый-сәяси тормышта актив катнашучы татарларның Төркестанда автономия игълан ителүне бик теләп сәламләве турында сөйли. 1917 елның 25 декабрендә Төркестан мөселманнары шурасы инициативасы белән мөселман солдатлар һәм эшчеләрнең чираттан тыш корылтае үткәрелә. Анда татарлардан Төркестан автономиясе премьер-министры И.С. Шаһиәхмәтов, Үзәк мөселман хәрби шурасы исеменнән Исамәт Гобәйдуллин, мөселман солдатлары исеменнән солдат Акчурин актив катнаша. Үз чиратында, 1917 елның 26 декабрендә Петроградка Төркестан хәрби шурасы рәисе Гариф Клевлеев исеменнән автономияне яклап җибәрелгән телеграммада болай диелгән: «Төркестан халкы бертавыштан Төркестан автономиясе турында игълан итте һәм Төркестанның Оештыру җыелышына ил белән идарә итү ысулын эшләргә тәкъдим кертте. Хәер, руслар һәм европалылар ил халкының нибары 2 процентын гына тәшкил итсәләр дә, Шурага сайланучыларның 33 проценты шушы халык булды. Әмма Россия комиссарлары Төркестан автономиясен юкка чыгару өчен чаралар күрә башлады. Мөселман эшче һәм солдатларның 1 нче корылтае карарлары белән танышканнан соң, идарәне Ташкенттагы Комиссарлар шурасыннан алып Төркестан автономиясе хөкүмәтенә тапшыру турында боерык бирүегезне сорыйм, чөнки Сез Россия Демократик Республикасының иң югары идарә органы булып торасыз. Фикер каршылыклары башланганчы, Төркестан да таркалмаячак» [Мингнаров, 2013, б. 105–111; Андижонда Мухторият...].

Автономия игълан ителү уңаеннан 6 декабрьдә Җәләл-Абад волостеның Хәнабад авылында узган митингта Абдулла Эшон һәм Хөсәен Вәлиди чыгыш ясый һәм халыкка автономиянең оешуын һәм максатларын аңлата [Агзамходжаев, 2006, с. 197]. Төркестан автономиясе хөкүмәте әгъзасы И.С. Шаһиәхмәтов һәм Төркестан татарлары Үзәк аппараты рәисе Кәбир Бәкер өлкәдә яшәүчеләрне автономия игълан ителү уңаеннан сәламлиләр. Алар Төркестан халкын автономиягә матди һәм рухи ярдәм күрсәтергә өндиләр [Ражабов, Ҳайдаров, 2002, б. 23].

Төркестан автономиясе игълан ителеп ике атна узганнан соң, «Олуг Төркестан» газетасында татар шагыйре Сәгыйть Сүнчәләйнең «Мохтарият кайтавазы» шигыре басылып чыга [Мухторият садоси].

1917 елның 10 декабрендә Ташкентта «Иттифак» татар җәмгыятенең гомуми җыелышы була, анда 26–28 ноябрь көннәрендә мөселманнарның Кокандта узган гадәттән тыш IV край корылтаенда тәүге мәртәбә катнашкан Кәбир Бәкер доклады тыңлана. Аннары җәмгыять әгъзалары чыгыш ясый һәм барысы да Төркестан автономиясен шатланып каршылавын белдерә. «Иттифак» җәмгыяте әгъзалары, автономия хөкүмәтен котлап, кулдан килгәнчә матди һәм рухи ярдәм күрсәтергә әзер булуларын җиткереп, 13 декабрьдә махсус милли байрак астында узачак автономия демонстрациясендә катнашырга карар кылалар. Мөселман солдатлар һәм мәктәп укучыларының да демонстра-

циягә җәлеп ителергә тиешлеге турында карар кабул ителә. Солдатларны демонстрациягә җәлеп итү бурычы Хәбибрахман Фәйзи һәм Галисәфәр Сутушовка йөкләнә. Аннары Коканд мөселманнарының чираттан тыш IV корылтаенда Төркестандагы татар җәмгыятьләре вәкилләренең карарлары тикшерелә. Анда татарларның Үзәк бюросы вәкиле Кәбир Бәкер дә катнаша [«Иттифоқ» жамиятининг...].

Автономиянең Вакытлы хөкүмәте 13 декабрьне «Төркестан автономиясенең милли фондына акча җыю көне» дип игълан итә [Аъзамхўжаев, 2000, б. 143]. Автономияне саклап калырга һәм ныгытырга тырышучылар арасында татарлар да күп була.

Коканд татар җәмгыяте әгъзалары да автономиягә яхшы мөнәсәбәттә булуларын беренчеләрдән булып белдерәләр. Акча җыюда Коканд татарларыннан бертуган Гозиннар – 500 әр сум, Садыйк Тазиев, Мөхәммәд Гәрәй Юздинаков, Шәриф Кашаев һәм Нигъмәтулла Мифтаксиддиновлар – 300 әр сум, Латыйф һәм Мөхәммәд Борнашлар – 200 әр сум, Хәмзә Кашаев һәм Гали Рахманкулов – 100 әр сум, Абдулла Мөхәммәдов, Садыйк Хәлилов, Хәсән Крымов, Хафиз Мөхәммәди һәм Кәрим Әбүбәкеров – 25 әр сум, Үзәк татар шурасына барлыгы 2425 сум күләмендә акча җибәрелгән [Ҳўқанд тоторларининг...]. Башка төбәкләрдә дә акча җыю белән татар җәмгыятьләре шөгыльләнгән, бөтен сумма автономия файдасына җибәрелгән.

1917 елның декабрь ае башында Ташкентта Татар җәмгыятьләре шурасы утырышы була. Анда Коканд, Каттакурган, Сәмәрканд, Бохара, Әндиҗан һәм Нәмәнган татар җәмгыятьләре вәкилләре һәм хәрбиләре катнаша. Кәбир Бәкер җитәкчелегендәге шура утырышында Төркестан мөселманнарының чираттан тыш IV корылтаенда (Коканд, 26–28 ноябрь) каралган мәсьәләләр тикшерелә. Башта Кәбир Бәкер Үзәк татар Советы алып барган эш һәм гомуми сәяси хәл турында мәгълүмат бирә. Вазгыятьнең җитдилеген истә тотып, Төркестандагы татар җәмгыятьләренә янә җаваплылык йөкләнәчәге таныла.

1917 елның 30 декабрендә Коканд татарларының «Җәмгыяте исламия» оешмасы әгъзалары утырышы була, анда түбәндәге карарлар кабул ителә:

1. Ирләр мәктәпләрен мәчет һәм мәдрәсәләрдән «Җәмгыяте исламия» карамагына күчерергә.

2. Мәктәп өчен смета төзергә һәм шәһәр Думасыннан акча сорарга.

3. Азык-төлек комитетына – В. Вахитовны, ата-аналар комитетына – И. Төхвәтуллинны, укытучылар берлегенә А. Исамиддиновны вәкилләр итеп сайларга.

4. Мәктәп китапханәсенә китаплар һәм газеталар алу өчен, җәмгыять хисабына 100 сум акча бүлеп бирергә.

5. «Җәмгыяте исламия» президиумы утырышларын атнага бер тапкыр җомга көнне үткәрергә.

1918 елның 17–18 февралендә Автономиянең вакытлы хөкүмәте структурасында үзгәрешләр була. М. Чокаев үз вәкаләтләрен туктату

турындагы карарга килгәннән соң, аның урынына Мәһди Чанышев билгеләнә [Мингнаров, 2000, б. 45].

Әмма акрынлап большевикларга да уңыш елмая башлый. Бу вакытта Ташкенттан Төркестан хәрби комиссары Е.Л. Перфильев җитәкчелегендә кавалерия һәм артиллерия частьләреннән торган 11 эшелон килә. 19 февральдә Төркестан автономиясе бәреп төшерелә һәм канга батырыла, ә Коканд шәһәрендә өч көн буена суеш, талау һәм янгыннар туктамый. Чыганакларга караганда, бу көннәрдә Кокандта 10 000 кеше һәлак булган [Аъзамхўжаев, 2000, б. 148–149].

Шул ук елның февраль-март айларында «Олуг Төркестан» газетасы саннарында «Коканд трагедияләре» дигән исем астында басылган мәкаләләр серияләрендә Кызыл Армия частьләре һәм әрмән дашнаклары тарафыннан Төркестан автономиясенең юк ителүе, шәһәрдәге коточкыч погромнар һәм талаулар объектив рәвештә һәм ачыктан-ачык яктыртыла. Төркестан автономиясенең бәреп төшерелүе түбәндәгечә сурәтләнә: «11 көн үз тормышларын һәм җаннарын кызганмыйча дәвам иткән сугышлардан соң, Төркестан автономиясе солдатлары шәһәрдән чыгып китәргә мәҗбүр булдылар. Рус шәһәре, мөселман шәһәре (Коканд шәһәренең яңа һәм иске өлешләре күздә тотыла. – *Авт.*) атыштан нык зыян күрде. Большевистик хөкүмәт тарафыннан оештырылган көчле артиллерия һөҗүменнән соң, мөселман шәһәре бушап калды. Мөселманнар, нәтиҗәдә, газават игълан итте. Бу хәлләрнең авыр нәтиҗәләргә китерүен аңлап, большевик солдатлар башлыгы Перфильев гаскәрләрне Кокандтан чыгару турында карар кабул итте...» [Туркистон Мухториятининг...].

«Сәгадәт» китап кибете хуҗасы Абдулла Гайнуллинның «Олуг Төркестан» газетасы редакциясенә язган хаты да игътибарга лаек. Аерым алганда, анда: «Коканд тулысынча яндырылган һәм «Гайрәт», «Сәгадәт», «Берлек» һәм «Мәгърифәт» китап кибетләренең исемнәре генә калды. Биналар үзләре юк. Шул сәбәпле безгә адресланган газеталарны бүтән җибәрмәгез. Биредә бу газеталарны укучылар да, аларны сатучылар һәм сатып алучылар да калмады» [Ҳўқанддан мактуб]. Бу чыганактан күренгәнчә, Коканд шәһәренә һәм аның халкына нинди авырлыклар кичерергә туры килә.

Төркестан автономиясе бетерелгәч, большевиклар хөкүмәте Автономия хөкүмәте әгъзаларыннан аяусыз үч ала башлый. Автономия хәрби шурасы рәисе Мәһди Чанышевның язмышы да бик аяныч тәмамлана. Ул Скобелев шәһәрендә большевиклар тарафыннан кулга алына һәм җәзалап үтерелә [Маҳди Чанишев]. Бу вакытта Автономиянең Кокандта булган премьер-министры И.С. Шаһиәхмәтов кызылармиячеләргә әсирлеккә эләгә. Коканд фаҗигалары вакытында танылган сәүдәгәр Абдулла Газинны да большевиклар кулга ала [Абдулла Ғозин].

1918 елның 28 апрелендә Мәскәүдән килгән мөселман комиссары катнашында уздырылган киңәшмә Ташкент татарларының «Иттифак» җәмгыяте Совет хакимияте мәнфәгатьләренә җавап бирми, дигән нәтиҗәгә килә һәм аның урынына «Татар социалистик эшчеләр коми-

теты» оештырыла [Мухтарам тотор...]. Бу очрашу вакытында кемдер Ташкент шәһәре башлыгы янына барып, «Иттифак» җәмгыяте әгъзаларының Төркестанда игълан ителергә тиешле Пролетар автономиягә каршы яшерен җыелыш үткәрүе турында ялган мәгълүмат җиткерә. Шуннан соң егерме казак җыелышка бәреп керә, 15 кеше кулга алына һәм Тупроккургандагы төрмәгә утыртыла. Бу яңалык «Азатлык йорты»нда узган большевиклар җыелышында катнашучы мөселман комиссарларына бик тиз барып ирешә. Шуннан соң комиссар Гариф Клевлеев җаваплылыкны үз өстенә алып, тоткыннарны төрмәдән чыгарта [«Иттифоқ» аъзоларина...].

Большевиклар, Төркестан автономиясен юкка чыгаруда катнашып, үзләренең чын йөзен күрсәтә. Юлбашчылары Ленин һәм Сталин 1917 елның 20 ноябрендә «Россия һәм Шәрыкның барлык мөселман хезмәт ияләренә» мөрәҗәгатендә Төркестан, Идел буе, Кырым, Себер, Кавказ мөселманнарына адресланган мондый юллар бар: «Хәзер сезнең динегез һәм гореф-гадәтләрегез, милли һәм мәдәни учреждениеләрегез ирекле һәм кагылгысыз дип игълан ителәчәк. Иректә һәм ләззәтләнеп үз милли тормышыгызны төзегез. Сез моңа хокуклы» [Ленин, б. 493]. Әмма чынбарлыкта «юлбашчылар» җитәкчелегендәге совет хөкүмәте халыкларның һәртөрле хөр фикерлелегенә, үз язмышларын үзләре билгеләргә омтылуына каршы чыга. 1918 елның 1 июнендә Зәки Вәлиди большевиклар юк иткән Төркестан автономиясенең фаҗигалы язмышына үз карашын белдереп, болай дип яза: «Алар автономиячеләрне кулга алып, аларның күбесен үтерделәр. Бик күп йортларны яндырдылар һәм меңләгән кешене салкын Себергә сөрделәр... Большевиклар үз эшчәнлекләрендә бернинди пычрактан да чирканып тормады». Зәки Вәлиди шулай ук Коканд, Маргилан, Кува һәм башка шәһәрләрдәге ут төртү һәм суешларны ассызыклап үтә, мөселманнарның бу хәлләрдән «сакалларын кырып һәм муеннарына тәре асып кына котыла алуын искәртә» [Ахмет Заки Валиди Тоган, с. 108–109].

Татарларның Төркестан автономиясе өчен көрәштә катнашуы, аларның бу милли хөкүмәткә күрсәткән ярдәме төрки-мөселман халыкларының үзара хезмәттәшлеге һәм ярдәм итешүе турында сөйли. Бәйсезлек һәм ирек өчен көрәштә крайдагы төрки-мөселман халыкларының теләсә кайсы вазгыятьтә иңне-иңгә куярга сәләтле булуын күрсәтә. Башлангыч чорда бу хезмәттәшлек мәдәни-агарту алгарышы юнәлешендә алып барылса, 1917 елның Февраль революциясеннән соң ул сәяси характер ала. Шул ук вакытта татар зыялыларының авыр тормыш шартларында бердәм бәйсез дәүләтчелек өчен төрки кардәшләре белән бергәләп эш итүе төрки халыкларның Төркестан азатлыгы өчен көрәштә берләшүләрен күрсәтә. Бу урында шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: соңрак большевиклар, хәйлә һәм мәкерне эшкә җигеп, Төркестанда совет хакимиятен ныгытуга хезмәт итәргә татар зыялыларының (Ю. Ибраһимов, Г. Клевлеев, С. Габдесаттаров, Ю. Алиев һ. б.) зур төркемен туплауга ирешәләр.

**Әдәбият**

Абдулла Ғозин // Улуғ Туркистон. 1918. 21 март.

*Абдурашидханов М.* Танланган асарлар. Ташкент: Маънавият, 2003.

*Агзамходжаев С.* История Туркестанской автономии (Туркистон Мухторияти). Ташкент: Тошкент ислом университети, 2006.

*Акбаров Р.* Туркистон миллий ташкилотларининг дастурларида миллий масаланинг акс этиши // Ўзбекистонда миллатлараро муносабатлар: тарих ва ҳозирги замон. Ташкент, 2003. Б. 96.

*Акбаров Р.Х.* Ислом Султон Шоаҳмедов сиёсий фаолиятига доир айрим мулоҳазалар // «Фарғона водийси тарихи янги тадқиқотларда» мавзусидаги халқаро илмий конференция материаллари. Фарғона, 2019. Б. 253–254.

Андижонда Мухторият намойиши // Улуғ Туркистон. 1917. 16 дек.

*Ахмет Заки Валиди Тоган.* Не сочтите за пророчество (на башкирском и русском языках). Уфа: Китап: 1998.

*Аъзамхўжаев С.* Туркистон Мухторияти. Ташкент: Маънавият, 2000.

«Иттифоқ» аъзоларина тақуф // Улуғ Туркистон. 1918. 30 апр.

Иттифоқ жамияти // Улуғ Туркистон. 1917. 25 апр.

«Иттифоқ» жамиятининг умумий живилиши // Улуғ Туркистон. 1917. 13 дек.

*Ленин В.И.* Ўрта Осиё ва Қозоғистон тўғрисида. Ташкент: Ўзбекистон, 1984.

Маҳди Чанишев // Улуғ Туркистон. 1918. 21 март.

*Мингнаров А.* Туркистонда 1917–1918 йиллардаги миллий сиёсий ташкилотлар (Миллий матбуот материаллари асосида). Ташкент: Маънавият, 2002.

*Мингнаров А.* Туркистондаги ижтимоий-сиёсий жараёнларнинг миллий матбуотда ёритилиши (1917–1918 йиллар). Ташкент: Истиқлол нури, 2013.

*Мингнаров А.Т.* Туркистонда миллий озодлик масалалари давр миллий матбуотида (1917 йил февраль – 1918 йил ўрталари): тарих фан. номз. дисс. Ташкент, 2000.

Мухторият садоси // Улуғ Туркистон. 1917. 16 дек.

Муҳтарам тотор қардошлар // Улуғ Туркистон. 1918. 30 апр.

*Ражабов Қ., Ҳайдаров М.* Туркистон тарихи (1917–1924 йиллар). Ташкент: Университет, 2002.

*Турдиев Ш.* Среднеазиатские татары: роль и значение в культурной и политической жизни Туркестана первой четверти XX в. // Ислам в татарском мире: история и современность. Казань, 1997. С. 179.

Туркестан в начале XX века: к истории истоков национальной независимости. Ташкент: Шарқ, 2000.

Туркистон Мухториятининг фожеаси // Улуғ Туркистон. 1918. 26 февр.

Ўзбекистон совет мустамлакачилиги даврида... Ўзбекистонннинг янги тарихи. Иккинчи китоб. Ташкент: Шарқ, 2000. Б. 53–54.

*Усманова Д.* Февраль 17-го в телеграммах от мусульманского населения // Гасырлар авазы = Эхо веков. 1997. № 1/2. С. 168–169.

Ҳўқанд тоторларининг ҳимматлари // Улуғ Туркистон. 1917. 24 дек.

Ҳўқанддан мактуб // Улуғ Туркистон. 1918. 6 март.

***Рәсүлов Абдулла Нуретдин улы,***
*тарих фәннәре докторы, Нәмәнган дәүләт университеты профессоры (Үзбәкстан)*

***Рәсүлова Рислигой Абдулла кызы,***
*Үзбәкстан милли университеты докторанты (Үзбәкстан)*

УДК 392.1/398.831

***Э.К. Хәбибуллина,***
***Л.Х. Дәүләтшина***

# ТӨРКИ ХАЛЫКЛАРДА БАЛА ТУУГА БӘЙЛЕ ЙОЛАЛАР

В статье рассматриваются обряды родильно-нарекательного цикла и связанные с ними фольклорные жанры в традиционной культуре тюркских народов. Авторы выделяют этапы родильной обрядности, анализирует фольклорные жанры, составляющие ее основу, обращает внимание на местные особенности обрядовой культуры. Отдельно внимание уделено жанру колыбельных песен, их терминологии и семантическим особенностям.

**Ключевые слова:** традиционная культура, обряд, ритуал, жанр, родильно-нарекательные обряды.

The article deals with the rites of the birth and birth cycle and the folklore genres associated with them in the traditional culture of the Turkic peoples. The authors identifies the stages of the birthing ritual, analyzes the folklore genres that make up its basis, draws attention to the local peculiarities of the ritual culture. Special attention is paid to the genre of lullabies, their terminology and semantic features.

**Keywords:** traditional culture, rite, ritual, genre, birth-and-reproach rites.

Төрки халыкларның традицион яшәеше турында сүз алып барганда, барыннан да элек, территориаль яктан бер-берсеннән шактый ерак җирләрдә яшәгән халыкларның рухи мәдәниятендәге күп кенә күренешләрнең уртак булуын билгеләп үтәргә кирәк. Мондый мәдәни һәм рухи якынлык борынгы бабаларыбызның бердәм тарихы белән тыгыз бәйләнгән, шуңа күрә, төрки халыкларның йола фольклорын өйрәнгәндә, иң элек уртак төрки нигезгә барып тоташкан күренешләргә игътибар итү зарури.

Башлангычы белән борынгы төрки чорга нисбәтле күренешләрнең берсе – гаилә-көнкүреш йолаларының бала туу белән бәйле өлеше. Башка халыклардагы шикелле үк, төркиләрдә дә бәби тууга бәйле йола һәм гадәтләр зур урын алып тора. Гомумән, баланың дөньяга яралуы элек-электән зур бер сер буларак күзаллана. Кешелекнең бик борынгы заманнарында, бу сергә әле аңлатма табылмаганда, шуңа бәйләп бик күп ырымнар, йола-гадәтләр барлыкка килгән, һәм аларның шактые гаилә көнкүрешендә бүгенгәчә сакланып калган. Әлеге йолаларның нигезендә ана һәм баланың саулыгына, баланың киләчәк тормышына, аның уңышларына, гаилә коруына тәэсир итеп була, дигән ышану ята.

Бала тууга бәйле йолалар турында сөйләгәндә, сүзне нарасыйның дөньяга пәйда булуына булышлык күрсәтүче кендек әбиләрдән башларга кирәк. Төрки халыкларның күбесендә кендек әби атамасының төрле вариантлары кулланылышта йөри: мәсәлән, карачай-

балкарларда – «*киндик анна*» [Боташев, 2001, б. 14–15], уйгурларда – «*киндик-ана*» [Чвырь, 2006, б. 55], алтайларда *«киндик-эне, кин-эне*» [Шатинова, 1981, б. 74], татарларда – *кендек әби, кендек инә,* төрекләрдә исә – *ebe* (әбә) һ.б. Кендек әби – бала табарга җыенган хатын-кыз янында бердәнбер булышчы, аның янәшәдә булуы мәҗбүри бер шарт. Бала дөньяга килүгә, кендек әби һәр гамәлен буыннан буынга сакланып килгән гореф-гадәтләргә таянып кыла. Электән килгән инанулар буенча, баланың кубып төшкән кендеге һәм җаны турыдан-туры бәйләнгән. Шул сәбәпле, татарларда баланың кипкән кендеген саклап тоту – мөһим бер гамәл санала. Аның тарту көче бар дип ышаналар: ул хуҗасын үз яныннан ерак җибәрми, һәрвакыт туган нигезенә тартып тора. Буй җиткән һәр баланың кендек әбисен олылап искә алып, аның хәлен белеп, ярдәм итеп торуы да – төрки халыклар өчен традицион күренеш.

Татарларда гына түгел, башка төрки халыкларда да кендеккә электән аерым бер мөнәсәбәт булуы күзәтелә. Мәсәлән, тувалылар аны кечкенә янчыкка тегеп куйганнар, ул баланың гомер символы буларак кабул ителгән. Алтайлар аны бишек бавына эленгән тире кисәгенә төргәннәр, кайчагында баланың әнисе шундый тире кисәген бәйрәм күлмәге өстеннән путага да беркетеп куйган. Моңа охшаш күренешне казан татарларында да күзәтергә була: кайбер гаиләләрдә баланың кендеген дә, беренче чәч бөртекләрен, тырнакларын да, тукыма кисәгенә тегеп, бишеккә бәйләү гадәте саклана. Әлеге төенчек нарасыйны яман көчләрдән саклый дип ышаналар [Брусько, 2013, с. 26–27].

Төрекләрдә баланың кендеге белән башкарыла торган гамәлләр аның җенесенә карап та билгеләнә. Киселгән кендек малайныкы булса, аны иманга китерү, киләчәктә имам итеп күрү максатыннан, кендек Корьән янында саклана яисә мәчет нигезенә күмелә; укымышлы булсын өчен, мәктәп янында күмелә; чиста булсын өчен, суга яисә диңгезгә атыла. Кызларның кендеге исә кыз бала өй җанлы булсын дип, өй астына күмелә, шулай итсәң, бала өйгә бәйләнгән була, дигән ышану яшәп килә [Yılmaz, 2014, б. 88].

Бәби тууга аны *беренче тапкыр коендыру йоласы* да гади юындыруга гына кайтып калмый, бу очракның да матур йола-гадәтләре бар. Бала, әйтерсең лә, бөтенләй башка дөньядан аерылып, без яши торган шушы дөньяга килеп кушыла да тәүге тапкыр коендырганда рухи бер чисталыкка ирешә, алай гына да түгел, аннан соң аны тәмам үз итеп, «үзебезнеке» дип кабул итәләр... Бәбине, гадәттә, беренче көннәрендә үк теләкләр тели-тели әнисе яки әбисе коендыра.

*Тигез канатлы булсын,*
*Озын гомерле булсын,*
*Бәхетле, тәүфыйклы булсын,*
*Игелекле, шәфкатьле булсын!*
[Брусько, 2013, с. 39]

Туганнан соң бәбине юындыру белән бәйле йола-гадәтләр дә төрки халыклар мәдәниятендә зур урын алып тора. Төрек һәм төрекмән халыкларында юындыру белән бергә балага тоз тидерү яисә тозлы су белән коендыру гадәте дә яшәп килә. Төрек фольклорын беренчеләрдән булып системалы рәвештә өйрәнгән П.-Н. Боратав да баланы тозлы су белән коендыру гадәте хакында язып, тозның баланы кара көчләрдән саклый торган магик көченә игътибар итә [Boratav, 1999, б. 90]. Бу йола бүгенге көндә дә сакланган, һәм ул яңа гына дөньяга килгән балага тозлы су тидерү аның тәнен пешегүдән саклый, дигән ышану белән дә бәйле. Шул ук вакытта төрекләр ир бала бай булсын дип, аны юындырганда суга акча салалар, кыз баланы юындырганда исә, матур булсын дип, суга канәфер, роза чәчәкләре салына, иреннәренә чия суы сөртелә, тәмле телле булсын дип, кызның иреннәренә бал тидерелә [Yılmaz, 2014, б. 90].

Бала туугa бәйле йолаларның мөһим компоненты – *баланы бишеккә салу йоласы.* Төрки халыкларда өй түренә эленгән бишек элек-электән төрле йола-гадәтләрнең үзәгендә булган, ул йолалар баланың бишектәге чоры белән бәйләнгән, баланы яман күзләрдән, яман көчләрдән, төрле авырулардан, үлемнән саклауны күздә тоткан. Баланы саклар өчен, бишеккә кайчы яки пычак кебек тимер әйбер, сарымсак, артыш я миләш ботагы, Коръән китабы куялар. Мәсәлән, төрекләрдә 40 көне тулмаган бәбигә бишектә *Alkarısı* (Алкарысы) дип исемләнгән (ямьсез, олы тешле, чәчләре тузгыган итеп сурәтләнә) мәхлук зарар китерер дигән ышану саклана. Алкарысыннан саклап калу өчен, баланы беренче тапкыр бишеккә салыр алдыннан Коръәннән сүрәләр укыйлар, соңыннан баланың баш очына кечкенә Коръән китаплары куя торган булганнар.

Безнең көннәрдә бишек берара яшь гаиләләр тормышыннан югалып торса да, бүген бик күпләр, традицияләрне саклап һәм дәвам итеп, өй түренә бишек элүне гадәткә кертеп баралар. Элек-электән килгән йолаларга нигезләнеп, бүген дә баланы тәүге тапкыр бишеккә салуны иң беренче чиратта әбисенә, кайчагында әнисенә тапшыралар. Элек күп кенә халыкларда бәбине бишеккә салу вазифасын күп балалы, сау-сәламәт, һәркем тарафыннан хөрмәткә лаек хатын-кызга йөкләгәннәр. Андый хатын-кыз үзе үк саулык, уңыш символы буларак кабул ителгән, үзендәге шушы асыл сыйфатларны яңа туган бәбигә дә күчерергә тиеш дип саналган.

Бала туу йоласына бәйле фольклор текстлары арасында бишек җырлары аеруча әһәмиятле урын алып тора. Бишек җырлары – фольклорның бик борынгы жанры, һәм алар бүгенгәчә, буыннан буынга тапшырылып, сакланып киләләр. Бишек җырлары – гади такмаклар гына түгел, аларның һәр сүзенә, һәр юлына тирә-як турындагы мәгълүмат, әхлак кануннары, әни кешенең сабыена ирештерер тормыш тәҗрибәсе сыйган шикелле. Төрки халыкларда әлеге жанр төрлечә атала (татар телендә – *бишек җыры*, азәрбайҗан телендә – *layla*, чагатай телендә – *elle*, чуваш телендә – *nenne,* төрек телендә – *ninni* һ.б.)

[Yardımcı, 1998, б. 2]. Гаҗәеп бер ихласлык, җылылык һәм наз белән бишек җыры көйләгән ананың йөрәгендә дә, телендә дә үз сабыеның язмышын күзаллавы, аның киләчәге өчен борчылуы, бәхет юравы, баласын дөньяда акыллы, гыйлемле, бәхетле кеше итеп күрү теләге чагылыш таба. Кайсы гына халыкларның җырларын мисал итеп алсак та, аларның тирән лиризм белән сугарылганлыгын, балага кечкенәдән үк үгет-нәсыйхәт биреп, аның киләчәген фаразлаудан гыйбарәт икәнлеген күрәбез.

**Татарларда:**

*Әлли-бәлли итәр бу,*
*Мәктәпләргә китәр бу.*
*Тырышып сабак укыгач,*
*Галим булып җитәр бу.*

**Казакларда:**

*Eldiy, eldiy, nemerem,*
*Men özngmen kögerem.*
*Calıkpaymın kün boyı,*
*Kızıgıngna kenelem.*
*Eldiy, böpem, eldiy-ay,*
*Men salamın en-küydi-ay*
[Yardımcı, 1998, б. 4]

**Татарчага тәрҗемәсе**

Әлли-бәлли, оныгым,
Синең белән яшәрмен,
Арып талмам көне буе.
Сөенечеңнән шатланырмын,
Әлли-бәлли, балакаем, әлли-бәлли
Мин җырлармын бишек җыры.

**Үзбәкләрдә:**

*Osib ungil, kuvnağım,*
*Bolgil mevalı, bağım.*
*Alla-ya alla,*
*Sevimli bol hamişa,*
*Hazırgidek dil peşa*
*Alla-ya alla*
[Yardımcı, 1998, б. 7].

**Татарчага тәрҗемәсе**

Үсеп җитеш, көләч йөзем,
Җимешле бул, балам,
Әлли-бәлли бәлли-бәү.
Сөйкемле бул һәрвакыт,
Хәзерге кебек хозурлы
Әлли-бәлли бәлли-бәү.

**Төрекләрдә:**

*Nar ağacı narlanır,*
*Bal ağacı ballanır.*
*Küçük yavrum büyürse,*
*Okuyup memur olur.*
*Ee yavruma eee.*
[Yardımcı, 1998, б. 7]

**Татарчага тәрҗемәсе**

Нар агачы нар бирер,
Бал агачы балланыр.
Бәләкәчем үсеп җиткәч,
Укып зур кеше булыр .
Әәә, балам, әәә.

Төрки халыкларда иҗат ителгән бишек җырларының нигезендә ананың баласын иксез-чиксез яратуы, аның киләчәктә уңышларга ирешүен, озын гомерле егет, каһарман булуын теләп кылган догалары, бала атасын, анасын, өлкәннәрне хөрмәтләсен дип бирелгән нәсыйхәтләре, укытучы, табиб, төзүче кебек ихтирамлы һөнәр иясе булуы белән бәйле теләкләр ята.

Баланың туганнан соңгы тормышына бәйле йола-гадәтләр бик күп. Дөньяга килүнең беренче кырык көнен, беренче атнасын барлык халыклар да үзенчә бер гадәт белән билгеләп үтә. Чөнки әлеге аралык бәбинең үзе өчен дә, аның әнкәсе өчен дә аеруча әһәмиятле чор санала. Нәкъ шушы көннәрдә баланы карау мәшәкатьле дә, мавыктыргыч та бер төс ала, аны яман күзләрдән-көчләрдән саклау өчен, бөтен йолалар да җиренә җиткерелеп башкарыла.

Төрки халыклар мәдәниятендә баланың беренче кырык көн гомеренә аерым бер әһәмият бирелә. Кырык көн тулу – җанның кешегә иңүе һәм кешедән китүе белән тәңгәлләштерелә. Кешенең вафатыннан соң да кырыгын билгеләп үтү гадәткә кергән. Татарларда баланың тууына кырык көн булгач, садака бирү тиешле санала. Бала хөрмәтенә дип, гадәттә, өлкән хатын-кызларга, әбиләргә садака бирелә. Себер татарлары телендә «*арыслан сәтәкәсе*» дип аталган бу йоланың асылында балага саулык, бәхетле киләчәк юрау ята. *«Умбиш тин көмөшне арыслан сәтәқәсе тип, башыннан әйләндереп бер әбигә бирә. Шул умбиш тин көмеш бирелсә, арыслан да һөҗүм қыла алмыйты, кеше тә тийә алмыйты. Үтерәм тип килгән пыцак та төшеп китәр ти»* [Баязитова, 2011, б. 31]. Төрки халыкларның кайберләрендә баланың кырык көне тулуга бәйле бу гадәт *«кырклама», «кыркланмак»* дип атала. Төрекләрдә баланың кырыгы тулган көнне кырык чүмеч су белән коену гадәте гамәлгә кергән. Мунчада яисә өйдә башкарыла торган бу гамәл баланы һәм ананы кырык чүмеч су белән бисмилла әйтеп башларыннан коендырудан гыйбарәт. Төркиянең кайбер өлкәләрендә кырык көне тулмаган баланы коендырганда егерменче һәм кырыгынчы көннәрендә суга 40 кашык су яисә 40 бөртек арпа салып коендыралар [Yılmaz, 2014, б. 106], ә кырыгы тулмаган бала булган йортта исә сөннәт туйлары яисә җеназа үткәндә, ана белән баланы өйдән ераграк тоту тиеш санала.

Төрекләрдә *kırk çıkarma* («кырыгын чыгару») йоласы дә билгеле. Бу йолага мәхәлләдәге өлкән хатын-кызлар, туган-тумача, күршеләр чакырыла, кечкенә генә бер бәйрәм ясала. Мәҗлес башлангачы, Корьәннән сүрәләр укыла, баланың тугач та кидерелгән киемнәре салдырыла, беренче чәче киселә. Алдан хәзерләп куелган *кырк суына* кырык кашык су һәм тоз салына. Мәҗлестәге кунаклар тарафыннан дога кылына, бала бай һәм бәхетле булсын дип теләкләр теләнә (*Yaşın uzun, ömrün uzun olsun – Яшең озын, гомерең озын булсын); Kırkın mırkın çıksın – Кырыгың чыксын*). Баланы теләкләр тели-тели *кырк суы* белән коендыру, аның алга таба нык бәдәнле булып үсүен тәэмин итү максатыннан чыгып эшләнә. Кырклама мәҗлесенең ахырында *kırk tokuç* дип аталган икмәк пешерелә. Бу икмәк мәхәлләдәге балаларга таратыла. Болай эшләү кырык көн чиген узган баланың башка балалар кебек үк сау-сәламәт булып үсүен теләү максатыннан эшләнә [Yılmaz, 2014, б. 109].

Теге яки бу гаиләдә бәби туса, яшь ананың хәлен белергә, аны котларга килү, саулыгын кайгырту якын кешеләре өчен язылмаган

бер бурыч булып тора. Күчтәнәчкә камыр һәм сөт ризыклары алып килү – борынгыдан калган гадәт. Бәби тапкан яшь әни күчтәнәчкә килгән бу ризыкларның һәммәсен дә авыз итеп карарга тиеш. Йоланың төп максаты – баланың кардәш-ыру тарафыннан кабул ителүе, үз кеше булып китүе. Якутларда яңа гына баладан котылган хатынның тәне көчсез дип исәпләнә, шуңа күрә аңа 40 көн дәвамында өйдән чыгып китү, чит йортларга керү рөхсәт ителми. Бу күренеш баланы саклау белән аңлатыла, әлеге тыюны үтәмәгән хатын-кызның баласы да авыру, көчсез була дип уйланыла [Yılmaz, 2014, б. 97].

Бәби туганнан соң аның тормышында зур урын биләгән йолалар арасында *исем кушу* аерым бер игътибарга лаек. Исем үзе дә сакраль мәгънәгә ия. Ул үзенең «хуҗасын» саклый, аның җанына калкан булып тора кебек. Шуңа күрә татарларда яңа туган баланы озаклап исемсез тоту куркыныч санала, балага беренче көннәрдә үк, кырыгы тулганчы, исем кушарга омтылалар. Исеме булмагач, бала яклаучысыз, саклаучысыз калгандай кабул ителә. Шуңа күрә аны кеше күзе тию ихтималыннан да, явыз көчләр тәэсиреннән дә ныграк сакларга тырышалар. Бары тик колагына Азан әйтеп исем кушкач кына, Аллаһы Тәгалә аны саклый, яклый дигән ышану яшәп килә. Исем кушылмаган баланың җаны, үзенең исемен тапканчы, аны эзләп, адашып йөрер, ди. Бүген татарларда исем кушу йоласы ислам динен тотучы башка төрки халыклардагы шикелле үк, бер үк кануннарга нигезләнеп башкарыла.

Исем кушу уңаеннан яисә бала хөрмәтенә махсус билгеләнгән вакытта туган-тумачаны, күрше-күләнне чакырып, махсус мәҗлес уздырыла. Кеше тормышындагы иң тәүге туй бу, җитдирәк итеп әйткәндә, баланың җәмгыять тарафыннан рәсми рәвештә кабул ителүе дип атасак та була. Чөнки сабый хөрмәтенә зурлап мәҗлес үткәрелә, аңа төрле бүләкләр китерелә, бала турында, аның да җәмгыятьнең бер әгъзасы булуы хакында кешеләргә ирештерелә. Мәҗлес вакытында балага әйтелгән теләкләр дә төрле була. Алтай төркиләренең халык иҗатында сакланып калган махсус алкышлар балага исем кушкан вакытта әйтелә:

| | |
|---|---|
| *Caksı cürüm sürzin* | **Татарчага тәрҗемәсе** |
| *Carıngıda caktarbas,* | Озын гомер яшәсен, |
| *Bökö bolzın.* | Көчлегә дә җиңелмәс |
| *Caaktuga ayttırbas,* | Үгездәй нык булсын. |
| *Çeçen bolsun.* | Яман сүзләр сөйләтмәс |
| *Cüs caş caşa,* | Чичән булсын. |
| *Cügürük ata min.* | Йөз ел яшәсен, |
| [Dilek, 1996, б. 4] | Иясе бөек булсын. |

Бала туу йолалары арасында ир баланы сабый чакта ук *сөннәткә утырту* йоласы да әһәмияткә ия. *Сунна* – гарәп сүзе, традиция, гадәт дигәнне аңлата. Ә менә баланы *сөннәтләү*, *сөннәткә утырту*

беркадәр таррак мәгънәгә ия, ул малайларны мөселман гадәте буенча физик пакьләндерү. *Сөннәтләү* – һәр ир баланың тормышында шактый зур урын алып торган, аны шартлы рәвештә булса да чын ир-егетләр исемлегенә керткән мөһим бер вакыйга ул. Элек-электән халык арасында даны чыккан сөннәтче бабайлар булган. Кендек әби шикелле үк, ул да ихтирамга лаек затлардан саналган, аңа бүләк-күчтәнәчләр китергәннәр, илтифат күрсәткәннәр. Чөнки аның бик җаваплы һәм саваплы, шул ук вакытта бик катлаулы эш башкарганын яхшы аңлаганнар. Сөннәтче бабай кулында – баланың сәламәтлеге, киләчәктә нәселне дәвам итүе. Әстерхан һәм Себер якларында, Урта Азия халыкларындагы кебек, бу йоланы күп итеп кунаклар чакырып, төрле уеннар, көрәш, ат чабышлары үткәреп, зурлап бәйрәм итәләр. Бу сөйләшләрдә аны *сөннәт туй, сөннәт хатеме* дип атыйлар [Баязитова, 1992, б. 230].

Әйтик, төрек, азәрбайҗан халыкларында бүгенге көндә дә сөннәт мәҗлесе туй мәҗлесеннән бер дә ким түгел. Сөннәт йоласы ир балага 11–12 яшь тулганчы үтәлә. Сөннәт эшләнәчәк һәм бала ятачак бүлмә махсус хәзерләнә: ятакка, гадәттә, ана кешенең кул эше саналган җәймә җәелә, диварларга бизәкләр, шарлар эленә. Кунакларга махсус чакырулар җибәрелә. Кунаклар җыелгач, пәйгамбәрне олылау максаты белән аятьләр укыла, салават әйтелә. Сөннәт алдыннан ир бала авылларда ат өстенә, шәһәрләрдә купшы машинага утыртып йөртелә, шул рәвешле урам әйләнү гадәте гамәлгә ашырыла. Соңгы елларда сөннәт махсус шифаханәләрдә башкарылуга карамастан, бала янына ир туганы кертелә. Баланың авыртуы кимесен өчен, аңа лукум каптыралар. Элек заманнарда кулына чи йомырка тоттыру гадәте дә булган. Сөннәттән чыгуга, баланың өенә кунаклар килә, зурлап мәҗлес үткәрелә.

Адыяман җирлегендә Корбан итенең чалган өлеше иң хөрмәтле кешегә – кирвәгә (төрек халкында *кирвә* дип «сөннәт ителгән баланың кулын яки аягын тотып торган һәм бала өстендә ата хакы булган кеше»не атыйлар) бирелә. Туйларда давыл, зурна кебек музыка уен коралларында уйныйлар, җирле биюләрне башкаралар. Озын гомерле булсын дип, баланың кулына кына ягу ритуалы үткәрелә, үзенә алтын тәңкә тагыла [Яруллина-Йылдырым, 2014, б. 546].

Бала тууга бәйле йола-гадәтләрне барлап чыккач, еллар, гасырлар дәвамында аларның күбесе онытылган, югалган, үзгәреш кичереп, башка төсмер алган булса да, асылы шул ук калганлыгын күрә алабыз. Әмма шуңа карамастан, кайбер төрки халыкларда бу йолаларның сакланып һәм үтәлеп баруы да күзәтелә. Моны без югарыда үрнәкләр белән дә дәлилләп үтек. Һәр йола сабый баланың кешелек дөньясында «яңадан туууына», җәмгыять тарафыннан кабул ителеп үз урынын алуына, аның сәламәтлеген кайгыртуга, анда әдәп-әхлак кагыйдәләре тәрбияләүгә хезмәт итә. Бала туу белән бәйле гореф-гадәтләрне барлау-өйрәнү безгә шулай ук буыннан буынга тапшырылып килгән, кабатланган кайбер гамәлләрнең тарихын һәм асыл мәгънәсен-функциясен аңлау-ачыклау өчен дә бик кирәк.

**Әдәбият**

*Баязитова Ф.С.* Халык традицияләре лексикасы: бишек туе (йола һәм фольклор текстлары яссылыгында). Казан, 2011. 815 б.

*Боташев М.Д.* Искусственное родство у карачаевцев (XIX–XX вв.): автореф. дис. … канд. истор. наук; Ин-т этнологии и антропологии им. Н.М. Миклухо-Маклая. М., 2001. 27 с.

*Бруසько З.М., Завгарова Ф.Х.* В круге жизни. Казань: Ихлас, 2013. 224 б.

*Чвырь Л.А.* Обряды и верования уйгуров XIX–XX вв.: очерки народного ислама в Туркестане. М.: Восточная литература, 2006. 287 с.

*Шатинова Н.И.* Семья у алтайцев. Горно-Алтайск: Алтайское кн. изд-во, 1981. 184 с.

*Яруллина-Йылдырым Р.А*. Төрки халыкларда сөннәт йоласы: традицияләр һәм бүгенге торышы (татар һәм төрек халыклары мисалында) // Традиционная культура тюркских народов в изменяющемся мире: материалы I Международной научной конференции (12–15 апреля 2017 г.). Казань: Ак бүре, 2017. С. 545–548.

*Boratav P.-N.* 100 Soruda Türk Folkloru. İstanbul, Gerçek Yayınevi, 1999. 256 s.

*Dilek İbrahim.* Altay Türklerinde çocuğun doğması ve doğum günü kutlamalarına dair bazı inanışlar // Bilig Dergisi. 1996. S. 1. S. 51–54.

*Yardımcı Mehmet.* Kıbrıs ve diğer Türk ülkelerinde ortak ninni ve tekerlemeleri // II. Uluslararası Kıbrıs Araştırmaları Kongresi, 24–27 Kasım 1998 Doğu Akdeniz Üniversitesi, Gazimağusa, Kuzey Kıbrıs Türk Cumhuriyeti. S. 1–11.

*Yılmaz Yeşil.* Türk Dünyasında Geçiş Dönemi Ritüelleri. Ankara, 2014. 280 s.

*Работа выполнена в рамках мероприятия 3.5.4*
*Государственной программы «Сохранение, изучение и развитие*
*государственных языков Республики Татарстан*
*и других языков в Республике Татарстан на 2014–2022 год»*

*Мәкалә «2014–2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен*
*һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау,*
*өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4 номерлы чарасын*
*тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Хәбибуллина Эльмира Камил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, Казан федераль университеты*
*Халыкара мөнәсәбәтләр институты Халыкара мөнәсәбәтләр*
*һәм Көнчыгышны өйрәнү югары мәктәбе деканы*

***Дәүләтшина Ләйлә Хәсән кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел,*
*әдәбият һәм сәнгать институты гыйльми секретаре*

УДК 82-131

***Г.Р. Хөсәенова***

# ДАСТАННАРДА ЖАНР АТАМАСЫНДАГЫ ТӨРЛЕЛЕК МӘСЬӘЛӘСЕ ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ФОЛЬКЛОР ЯССЫЛЫГЫНДА

Статья посвящается проблеме разнородности жанровых названий в татарском романическом наследии. Объектом исследования статьи выступают рукописные и печатные тексты татарских дастанов на любовную тематику, как фоновые тексты привлекается также эпос героического характера. Автор проводит обзор всех зафиксированных в текстах книжно-письменных эпос-дастанов терминов, употреблявшихся в качестве названия жанра дастан; обращает внимание на активное фигурирование до начала XX века таких названий, как «китап», «кыйсса», «алькыйсса», «хикаят», «хикая». Подобный синкретизм жанровых названий по отношению к романическим дастанам автор оценивает как явление, характерное для определенного периода татарского фольклора и литературы. Как первоисточник автор в первую очередь обращается к дастанным текстам, хранящимся в Центре письменного и музыкального наследия ИЯЛИ имени Г. Ибрагимова АН РТ.

**Ключевые слова:** романический дастан, взаимовлияние, фольклорный и литературный процесс, книжно-письменный эпос, текст.

The article is devoted to the problem of the heterogeneity of genre names in the Tatar romance heritage. The object of the study of the article is the handwritten and printed texts of Tatar dastans on love topics, as background texts, the epic of a heroic nature is also involved. The author reviews all the terms recorded in the texts of the book-written epic dastans that were used as the name of the dastan genre; draws attention to the active figure of such names as «kitap», «kyissa», «alkyissa», «hikayat», «hikaya» until the beginning of the 20th century. The author assesses such a syncretism of genre names in relation to romance dastans as a phenomenon characteristic of a certain period of Tatar folklore and literature. As a primary source, the author first of all refers to the dastan texts stored in the Center for Written and Musical Heritage of the G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art of the Tatarstan Academy of Sciences.

**Keywords**: romance dastan, mutual influence, folklore and literary process, book-written epic, text.

Эпос жанры тарихында төрки эпос һәм Борынгы Көнчыгыш әдәбияты традицияләрен туплаган татар дастаннары үзенә бер әһәмиятле урын биләве белән характерлана. Бүген фәндә татар халкының мондый әсәрләренә карата «эпос» һәм «дастан» терминнары параллель кулланылса да, фарсы әдәбиятының тирән йогынтысын кичергән төрки халыкларның күпчелегендәге кебек, татарларда да «дастан» атамасының популярлыгы зуррак. Дастан дип гадәттә катлаулы сюжетка, вакыйгалылыкка корылган, тормыш һәм чынбарлыкны күпкырлы һәм киң эпик сурәтли торган, стиле белән күбрәк

чәчмә я катнаш, шулай ук шигъри типтагы бик зур күләмле әсәрне атап йөртәләр. Тематикасы да киң – каһарманлыктан башлап мәхәббәт маҗараларын тасвирлауга кадәр. Дастан чичән-импровизаторлар тарафыннан халык алдында башкарыла торган булган.

Идел буе татарлары иҗатындагы дастан әлеге төшенчәнең гомум кабул ителгән мәгънәсеннән дә, әдәби жанрны аңлата торган мәгънәсеннән дә аерыла. Чынлыкта казан татарлары эпос-дастаннары – чичән-импровизатор башкаруыннан ераклашкан, шул ук вакытта, күпләгән вариантта таралган булулары сәбәпле, аерым авторның оригиналь дастан-поэмасы дип тә билгеләп булмый торган язма төр иҗат. Татарларга хас мондый әсәрләрне китаби дастаннар дип атап, аларны әдәбият һәм фольклор чигендәге әсәрләр буларак тикшерү кабул ителгән. Бу мәсьәләгә татар галимнәренең мәгълүм карашлары, махсус хезмәтләре бар, мәсәлән, филология фәннәре докторы Л.Х. Мөхәммәтҗанованың шушы өлкәгә багышланган махсус монографиясе дөнья күрде [Мухаметзянова, 2014].

Китаби дастаннар арасында иң зур күпчелекне романик характердагы иҗат үрнәкләре алып тора. Хәлбуки бу әсәрләр татар әдәбияты белемендә дә, фольклористикада да дастан дип аталып йөриләр, соңгырак чорда аларга карата тагын да төгәлрәк *китаби романик эпос-дастаннар* дигән термин куллану активлашты. Урта гасырлар кулъязмаларыннан алып XX гасыр башынача китап булып басыла килгән мондый әсәрләр эчтәлеге һәм жанр билгеләре белән романик китаби дастаннар дип аталырга хаклы. Әмма язмада теркәлеп безнең көннәргә килеп җиткән, ике гашыйкның үзара мәхәббәте темасына багышланган әлеге истәлекләрнең чыганактагы үзатамасы күп очракта дастан дип түгел, ә бөтенләй башкача яңгырый. Язучы-күчерүче тарафыннан аларның үз чорында бүгенге термин белән аталмаган булуы табигый. Кулъязмаларда һәм басма китапларда теркәлгән мондый әсәрләр «дастан» дип, күбрәк «кыйсса», «хикәя», «хикәят», «намә» дигән исемнәр белән дә билгеләнгәннәр, ягъни «дастан» сүзенә синоним булырдай терминнар белән аталганнар. Хәтта бер үк сюжетка корылган әсәрләрне төрле чыганакта төрле жанр исеме белән атау очрый, татар дастаннары теркәлгән язма чыганаклар өчен бу закончалыклы һәм үтә гадәти күренешкә әйләнгән була.

Дастаннарның, шул исәптән романик дип билгеләнә торганнарының чыганакта ничек аталган булуларын барлап, аларга күзәтү ясап, әдәби процесста бу атамаларның динамикасын ачыклау һәм әлеге терминнарның кулланылыш сферасын билгеләү бик мөһим. Төрле чыганакта очрап торган мондый төрлелекне бер проблема астында тикшерү әлеге төшенчәләрнең тәңгәллек кимәлен ачыкларга ярдәм итәчәк.

Билгеле бер чор татар әдәбиятының шигъри жанрларында «кыйсса», «дастан», «намә», «рисалә», «хикәят», «китап» һ.б. атамалар төрлелегенә игътибар итеп, Ә.М. Шәрипов болай ди: «XIII–XIV гасырларда төрки-татар әдәбиятында лиро-эпик характердагы шигъ-

ри әсәрләрнең жанр исемнәрен билгеләүдә төрлелек хакимлек итә, Урта гасырлар авторлары һәм күчереп язучылары жанр чикләрен бик җиңел атлап чыгалар» [Шарипов, 2001, с. 255]. Чыннан да, татар әдәбиятында һәм шулай ук фольклорда да жанрлар бүленешендә төгәл кагыйдәләргә ихтыяҗ әле XX гасыр башларына кадәр булмаган.

Хәзерге татар фольклористикасында халык эпосын дастан дип атау кабул ителгән булса да, халык биргән исеменә, ягъни үзатамасына мөнәсәбәттә караганда, казан татарлары үзләре мондый әсәрләрен чагыштырмача сирәк «дастан» дип йөрткәннәр. Бу сүзнең кулланылыш сферасы безнең көннәргә күбрәк кульязмаларда килеп җиткән ядкярләргә кагыла, ягъни Идел буе татарларында «дастан» термины, жанрның үзе кебек үк, сөйләмә телдә актив яшәмәгән, ә бәлки китаби төшенчә булып килеп кергән. Мәсәлән, «Гайсә улы Амәт дастаны», «Чыңгыз хан нәселе турындагы дастан», «Аксак Тимер нәселе турындагы дастан», «Каһарман дастаны» – болар бар да язма истәлекләр, чыганакта ук аларның жанры «дастан» дип билгеләнгән. XVII йөз башыннан басмага теркәлгән романик характердагы эпик әсәрләрнең исә «дастан» дип күрсәтелгәннәре «кыйсса», «хикәят», «китап» сүзләре аша яисә гомумән әсәр исемен генә күрсәтеп тәкъдим ителгәннәренә караганда бик аз күзгә чалына [Каримуллин, 1993]. Мәсәлән, XIX гасыр ахырында «Дастан Хәтәм тай» исеме белән басылган әсәр [Дастан..., 1892] һәм XX гасырның 40 нчы елларыннан дөньяга чыгарылган җыйнама «Идегәй»гә карата (Н. Исәнбәт варианты) шулай ук «дастан» атамасы кулланылуны исәпкә алмаганда, бу термин актив түгел. Бүген романик дастан исеме белән өйрәнелә торган мәхәббәт сюжетлы әсәрләр чыганакларда гомумән «дастан» дип билгеләнмәгән дип тә әйтә алабыз.

Фольклористика тарихына күз салсак, «дастан» сүзе беренче мәртәбә Галимҗан Ибраһимовның «Пролетариат әдәбияты турында» дигән хезмәтендә очрый [Мухаметзянова, 2014, б. 104]. Әлеге мәкаләсенең искәрмәсендә ул терминны Көнчыгыш әдәбиятына нисбәтән кулланып: «Безнең Шәрык әдәбиятларында буны (эпопеяны. – *Г.Х.*) дастан дип атыйк. Буңарчы «поэма» сүзен «дастан» диюебез хата иде», – дип әйтеп уза [Ибраһимов, 1978, б. 466]. Әмма биредә әле «дастан» бүгенге фольклористика һәм әдәбият белемендә кулланыла торган мәгънәдән шактый ерак. «Дастан» атамасының эчтәлеге татарларда даими үзгәрә барган. Бүгенге татар телендә дә бу сүз шактый киң мәгънәне сыйдыра. Әмма хәзерге татар фольклор фәнендә терминның тәгаен ачыкланган мәгънәсе – эпос-дастаннар төркеменә карый торган жанр атамасы буларак – соңгырак чорда кабул ителгән.

Шушындый ук төрдәге әсәрнең бераз җыйнаграгы чыганакларда «хикәят», ә кайвакыт «хикәя» дип күрсәтелгән. Болар халык тормышын, дастан дип билгеләнгән әсәрләрдәге кебек үк, эпик планда яктырталар. «Хикәят» үзатамасы белән күбрәк героик характердагы эпос-дастаннар аталган. Хикәят бер батырның туганнан алып үлгән-

чегә кадәрге тормышын сурәтли, шулай ук бер я берничә вакыйганы артык җәелдерми генә сөйләп бирә. Мәсәлән, «Нарык һәм Чураның хикәяте», «Хикәяте Күр углы солтан», «Баһадир шаһ хикәяте» һ.б. Терминның мәгънәсе гомумән бик киң һәм бу халык иҗаты әсәрләренә мөнәсәбәттә дә чагылыш тапмый калмаган. Бездә ХХ гасыр башында да әле әкиятне, мәзәкне хикәят дип атаган очраклар да юк түгел [Каримуллин, 1993, б. 15].

«Хикәят» үзе – гарәп сүзе, хикәяләү дигән мәгънәне белдерә, борынгы һәм Урта гасырлар Көнчыгыш әдәбияты термины. Энциклопедиядә аңа мондый аңлатма бирелә: «Якын һәм Урта Көнчыгыш, Көньяк-Көнчыгыш Азия, Идел-Урал буе халыклары әдәбиятындагы жанр. Эчтәлеге белән хикәягә, новеллага, мәсәлгә якын. Хикәят – татар әдәбиятында иң популяр жанрларның берсе» [Татар энциклопедия..., 2002, б. 787]. Ә «Зур энциклопедик сүзлек»тә (һәм «Россиянең зур энциклопедик сүзлег»ендә) әлеге әдәби терминның теләсә нинди, еш кына шигъри һәм прозаик әсәрне аңлатуы, тар мәгънәсендә аноним китаби прозаик эпос жанры булуы күрсәтелгән [Большой..., 2005, с. 1716]. Әмма биредә татар язма әдәбиятында «хикәят» дип басылган һәрбер әсәрнең дастан жанрына туры килмәвен искәртеп үтү дә зарур. Татар әдәбияты тарихында маҗаралы яки дини эчтәлекле, күбесенчә аноним, әмма әдәби характердагы язма хикәятләр дә булган [Мәҗмугыл..., 1994].

Эпос-дастанга (яки хикәят дип бирелгән әсәр сюжетына) әле моңа кадәр телгә алынмаган батыр турындагы яңа сюжет килеп кергән очракта да бездә әсәрнең аңа бәйле өлешен шул батыр исеме белән «хикәят» дип аерымлау гадәте булган. Мәсәлән, шул ук «Чура батыр»да «Хикәят Колынчак батыр», «Түләк китабы»нда «Хикәяте Бачман хан берлә Җаждар хан» дип аерымланган юллар, «Каһарман Катил»дә әсәрнең бер өлешен шул рәвешчә ассызыклау игътибарны җәлеп итә. «Таһир-Зөһрә» сюжетлы дастанының Сайади вариантында «Таһир хикәяте», «Хикәят. Ахырда Таһирның Маһымга бәкләрдән сәлам әйткәне» дип бирелгән өлешләр, мәсәлән, әсәрнең башка урыннарыннан үзенең стиле белән дә аерылып тора. Биредә андый өлешләр мәснәви формалы рифма белән язылган.

Әсәр эчендә төп сюжеттан үзенең гыйбрәтлелеге белән аерылып торган, чигенеш ясап алу тибындагы мөстәкыйль сюжетлы текстлар да күпвакыт «хикәят» сүзе астында китерелгәннәр, шуннан соң әсәр гадәттәге сюжет сызыгы белән дәвам иткән. Кайвакыт зуррак әсәрдән кечерәк сюжет аерылып чыгып, хикәят исеме астында аның әллә ничә кульязмасы мөстәкыйль әсәр сыйфатында популярлашкан булуы да билгеле. Әйтик, XVIII гасырның соңгы чирегендә Идел буе татарларында киң таралган «Хикәяте сычкан» исемле шигъри текст (бу текстның XVIII гасырның 80 нче елларында күчерелгән берничә кульязмасы билгеле. XIX гасыр уртасыннан төрле җыентыкларда дөнья күргән) «Мәче белән сычкан сугышы» дип аталган әсәрнең бер өлешен тәшкил итә.

Төрки эпоста күләмле әсәрнең чагыштырмача мөстәкыйль әллә ничә сюжеттан оешканлыгы мәгълүм. Казан татарлары дастаннарында билгеле бер өлешне хикәят дип аерып кую – шушы алымның чагылышы, Урта Азия төрки дастаннары традициясенең татар халык дастани мирасында әле югалып бетмәгән, әмма соңгырак чорга якынлашкан саен актуальлеген җуйган элементы. Гомумән дастан жанрына мөнәсәбәттә караганда «хикәят (хикәя)» сүзе безнең халык аңында күләмле дастанның бер өлеше, дастаннан кечерәк эпик әсәр дигән мәгънәдә ныгып урнашкан булган.

Күп кенә эпос-дастаннарыбыз «кыйсса» үзатамасы белән билгеле. Бу да, дастан, хикәят кебек, Көнчыгыш әдәби термины. «Татар энциклопедия сүзлеге»ндә аңа билгеләмә түбәндәгечә: «Кыйсса – гарәп сүзе, хикәя, тарихи вакыйга, риваять дигәнне аңлата. Шәрык әдәбияты һәм фольклорында эпик, кайвакытта лиро-эпик жанр. Кыйсса формасы һәм тематикасы белән дастанга якын, китаби һәм фольклор чыганакларына нигезләнә, героик, фантастик, әкияти һәм тарихи эчтәлектәге вакыйгаларны үз эченә ала...» [Татар энциклопедия.., 2002, б. 380]. «Кыйсса» сүзенең гарәп, фарсы һәм төрки телләрдә белдергән мәгънәләре шактый киң – бу телләрдә ул «еш кына хикәят, әкият, повесть, поэма, легенда, риваять, дастан, мәсәл һ.б. мәгънәләрдә кулланыла» [Әдәбият.., 2007, б. 92].

«Кыйсса» сүзе – казан татарлары эпос-дастаннарына карата халыкның аеруча яратып, бик актив кулланган үзатамасы. Бу сүз Идел буе татарларында Болгар шагыйре Кол Галинең атаклы «Кыйссаи Йосыф» поэмасы тәэсирендә популярлашкан булырга мөмкин, ягъни казан татарлары дастани иҗаты термины буларак халык теленә бу төшенчәнең XIII гасырдан да соңрак керә алмавы бәхәссез. XIX гасырдан татар әдәбиятында һәм фольклорында кыйссаларга ихтыяҗ бик нык артып, бу процесс XX йөз башынача дәвам итә. «Кыйссаи авык», «Кыйссаи Сәйфелмөлек», «Кыйссаи Бүз егет», «Таһир илә Зөһрә кыйссасы», «Кыйссаи Сәедбаттал», «Кисекбаш кыйссасы», «Кыйссаи Сәкам», «Кыйссаи Козы Көрпеш» – болар күпсанлы эпос-дастаннарның халыкта күбрәк «кыйсса» сүзе белән аталып йөргәннәре. Безнең халыкның кыйсса дип билгеләнгән дастаннары – күбрәк тезмә, шулай ук чәчмә һәм катнаш характердагы, романик сюжетлы әсәрләр. Хикәят-дастаннар белән чагыштырганда боларда индивидуаль иҗат билгеләре күбрәк чагыла, алар лирик шагыйрь йогынтысын күбрәк кичергәннәр. Һәрвакыт булмаса да, кыйсса-дастаннарыбызның сюжеты еш кына билгеле бер мәшһүр автор исеме белән мәгълүм поэмаларга барып тоташа. Бу – романик китаби дастаннарыбызның Борынгы Көнчыгыш әдәбияты белән тыгыз бәйлелегеннән килә.

Романик характердагы дастаннарда текстның шигъри өлешләре ахырында тезмә белән бирелгән юлларны «әлкыйсса» сүзе белән башлап китү традициясе бик еш очрый. Безнең карашыбызча, бу сүз лиро-эпик әсәр стилендә үзенә бер функция үтәү чарасы булган. Мәхәббәт сюжетына корылган «Таһир белән Зөһрә», «Ләйлә-

Мәҗнүн» вариантларында һ.б. әсәрләрдә бу алым бик еш кулланылганын ассызыклыйк.

Шул ук вакытта «кыйсса» исеме белән татар матбугаты әдәби әсәрләрне, дини эчтәлектәге текстларны, тәрҗемә әсәрләрен һәм хәтта риваять, легенда, мәзәк хәлләрне дә бастырган булуны искәртү мөһим. Шуңа күрә, чыганаклар белән эш иткәндә бүгенге караштан халык эпосы дип бәяләнергә хаклыларын сайлап алу аеруча сак эш итүне сорый.

«Дастан», «кыйсса», «хикәят», «хикәя», үзатамаларыннан тыш Идел буе татарлары үзләренең бүгенге көндә язма-китаби дастан буларак карала торган әсәрләрен еш кына «китап» сүзе белән дә атап йөрткәннәр. Әйтик, «Түләк китабы», «Йосыф китабы» («Китабы Йосыф»), «Кисекбаш китабы». Әлеге атама казан татарларында нәкъ менә китаби чыгышлы, ягъни шул ук сюжетка әдәби версиясе дә гаять популярлашкан романик дастаннарга карата ныгыган. Мондый эпик әсәрләрнең халыкның үзе тарафыннан китапка нисбәт ителеп, аның язма нигезле ядкяр булуын турыдан-туры искәртеп, «китап» дип аталуы – төрки-угыз язма эпосы «Китабы дәдәм Коркыт»тан килә торган һәм, әлбәттә, ислам йогынтысы тәэсирендә формалашкан традициянең күркәм чагылышы.

Дастаннарның исеме аеруча билгеле саналып, аеруча киң таралганнары хакында сүз барганда, безнең халыкта жанр атамасын бөтенләй төшереп калдырып, әсәр исеме белән генә атау яки әсәр исеме белән генә бастырып чыгару гадәте дә яшәгән. Мәсәлән, «Таһир-Зөһрә», Бүз егет», «Сәйфелмөлек», «Түләк» һ.б. текстлар шулай бирелгән.

Әмма, XX гасыр башы татар матбугатында нәшер ителгән дастаннар үрнәгендә фикер йөрткәндә генә дә, бу чорга инде кайсы әсәрне нинди үзатама белән атау мәсьәләсендә принципиаль кагыйдәләрнең булмавы ачыклана. Дастани ядкярнең китаби формада халыкта таралу процессында фольклорда мондый әдәби нечкәлекләргә игътибарның кайчандыр булу ихтималы гомумән бик аз. Бер үк текстның һичбер үзгәртүсез кат-кат басылып, басылганы берендә әле кыйсса, әле хикәят, хикәя, дастан яисә китап дип бирелүе дә шушы фикерне куәтли. Мәсәлән, «Каһарман Катил» дастаны «Каһарман хикәяте», «Кыйссаи Каһарман», «Каһарман китабы» дигән исемнәр белән мәгълүм булган, халыкта аны «Каһарман дастаны» дип тә йөрткәннәр. Шул ук текст әсәр исеме белән генә дә, ягъни «Каһарман Катил» дип кенә дә басылган.

«Кыйсса», «хикәят», «хикәя» исемнәре белән басылган (яисә күчерелгән) текстлар арасында принципиаль аермалар юк, бу әсәрләр барысы да эпос-дастан жанрына тулысынча сыеша. Фольклористика һәм әдәбият белеме тарихында бу терминнарның үзләренә генә хас билгеләрен дә үзгәрмәс һәм ныклы дип күрсәтеп булмый. Болар татар теленә иран, төрки-иран, гарәп-фарсы әдәбияты-мәдәнияте аша кереп урнашканнар, чыганак телдә белдергән мәгънәләрен күпмедер

дәрәҗәдә саклап калсалар да, татар эпик иҗатында аларның кулланылышына катгый таләпләр дә булмаган. Бу әлеге төшенчәләр белдергән мәгънәнең гасырлар дәвамында чыганагыннан ераклашып, татар җирлегенә генә хас традицияләргә хезмәт итә башлавыннан килә, дип билгели алабыз. Татар дастаннарына нисбәттә аларның үзләренә генә хас билгеләре бөтенләй югалып беткән дияргә дә мөмкин.

Татарларда сакланып калган иң күләмле, иң камил эпос-дастаннарның язма мәдәният белән дә тирән керешкән, фольклор кануннарына да буйсынган үзенчәлекле ядкярләр булуы мәгълүм. Алар төрле фәнни үзәк архивларында, аерым алганда, Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фондларында кульязмалар һәм гарәп язулы басма китаплар рәвешендә саклананалар. Язуга дастан, кыйсса, хикәят, хикәя, китап исемнәре белән теркәлгән күпсанлы татар романик эпосы бүгенге көндә, бер жанр атамасына тупланып, «дастан» дип атала. Халык иҗаты билгеләренә ия булулары аларны эпос төшенчәсенә дә якынайта, шуңа да мондый төр иҗат китаби эпос-дастан категориясенә туры килә дә. Югарыда телгә алынган терминнарның, асылда, бер үк жанрны белдерүгә кайтып калуын ачыклау бу чор язма истәлекләрен романик китаби дастаннар буларак тикшергәндә килеп туган күп кенә мәсьәләләрне ачыкларга булыша. Бу терминнар бүгенге көндә татар теленең архаик лексикасын тәшкил итәләр, ягъни хәзер инде алар элекке мәгънәсендә жанр исеме булып яшәмиләр, шулай ук бу исемнәрнең халык әсәрләренең үзатамасы буларак та очравы билгеле түгел.

Казан татарларының төрле үзатама белән йөргән романик китаби дастан текстларын чагыштырулар түбәндәге нәтиҗәгә китерә: кульязмаларга теркәлгән яисә китап булып басылып чыккан романик характерлы әсәрләр чыганакта «дастан» дип билгеләнмәгән, әмма алар эчтәлеге һәм формаль билгеләре белән бер үк жанрга карый. Әдәбият һәм язма фольклор чигендә торган мондый эпик әсәрләр, ничек аталган булсалар да, киң мәгънәсендә эпос-дастан төшенчәсенә туры киләләр. Алар Кол Галинең «Кыйссаи Йосыфы», Харәзминең «Мәхәббәтнамә»се, Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан»ы, Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен»е, Мөхәммәдьярның «Төхфәи Мәрдан»ы кебек әдәби дастаннарга тартым, әмма алар янәшәсендә үзләренең күп кенә билгеләре белән аерылып торалар. Шул ук вакытта мондый төр әсәрләрнең сөйләмә характерда булмавы һәм тагын башка билгеләре аларны төрки традициясеннән килә торган «тере» эпостан да үзгә итә.

**Әдәбият**

Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. 231 б.

Большой Российский энциклопедический словарь. М.: Большая Российская энциклопедия, 2005. 1887 с.

Дастан Хатәм тай. Казан: Ун-т тип., Ш. Хөсәен нәшере, 1892. 83 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр. Сигез томда. Т. 5. Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910 – 1933). Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 616 б.

*Каримуллин А.А.* Татарский фольклор. Аннотированный указатель литературы (1612–1981). В двух частях. Ч. I. Казань, 1993. 135 с.

Мәҗмугыл хикәят. Борынгы татар прозасы. Нәҗип Исмәгыйль күчермәсе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 446 б.

*Мухаметзянова Л.Х.* Татарский эпос: книжные дастаны. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2014. 380 с.

Татар энциклопедия сүзлеге. Казан: Татар энциклопедия институты, 2002. 830 б.

*Шарипов А.М.* Зарождение системы стихотворных жанров. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2001. 364 с.

***Хөсәенова Гөлнирә Рәзиф кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге аспиранты*

УДК 37

*М.М. Хәбетдинова*

# НӘКЫЙ ИСӘНБӘТНЕҢ ПЕДАГОГИК ЭШЧӘНЛЕГЕ ҺӘМ КАРАШЛАРЫ

**(галимнең фәнни биографиясен төзү юлында)**

В статье реконструируется педагогическая биография Наки Исанбета (1899–1992). Материалом исследования послужили архивные документы, воспоминания ученого-энциклопедиста, его современников, научные труды. В работе предпринята попытка дать целостную характеристику педагогической деятельности Н. Исанбета. Новизна исследования определяется отсутствием работ, осмысляющих педагогическую деятельность «народного академика». Основными методами исследования являются системно-целостный подход к объекту изучения и конкретно-исторический метод, позволяющие исследовать педагогическое наследие Н. Исанбета в единстве с историей развития отечественной науки в конкретную эпоху.

**Ключевые слова**: татарская культура, джадидизм, Наки Исанбет, национальная система образования, история педагогики.

The article reconstructs the pedagogical biography of Naki Isanbet (1899–1992). We used archive documents, memoirs of the scientist-encyclopedist and his contemporaries, scientific works as the research material. In this paper, an attempt is made to give a holistic description of the pedagogical activity of N. Isanbet. The novelty of the research is determined by the lack of works that interpret the pedagogical activity of the «people's academic». The main research methods are the systematic and holistic approach to the object of study and the concrete historical method that allows us to study the pedagogical heritage of N. Isanbet in unity with the history of the development of Soviet science in a specific era.

**Keywords:** Tatar culture, Jadidism, Naki Isanbet, national education system, history of pedagogy.

Аһ, юк мин ни өчен гыйлем алдым,
Шул халкыма файдам тимәгәч?
Кояш булып кояш кемгә хаҗәт,
Башкаларга нурын бирмәгәч?
Юк, юк! Алар бәхте – минем бәхтем,
Телим – халкым күзе ачылсын,
Гыйлем белән алар көчле булсын,
Сөю, хаклык җирдә шаһ булсын,
Артык кеше кешегә кол булмас,
Бер халыкны берсе табындырмас,
Сәҗдә булмас, һичкем хур булмас.

*Н. Исәнбәт. «Әбүгалисина» (1958)*

Татар әдәбияты тарихында Нәкый Исәнбәт (1899–1992) шәхесеннән дә серлерәк язмышлы әдип юктыр ул. Бер яклап, ул – фольклорчы, тел һәм әдәбият белгече булып, әдәби тәнкыйтьченең фәнни

хезмәтләре тюркологиядә аның какшамас урынын тәэмин итсә (М. Галиев, Ф. Ганиев, М. Госманов, Ә. Еники, М. Мәһдиев, Х. Мәхмүтов, Г. Рәхим, С. Сафуанов, Б. Урманче, С. Хәким һ.б.), икенче яклап, татар әдәбияты тарихын классик язучының драматургиясе, шигърияте һәм тәрҗемәләреннән башка күз алдына китерү мөмкин түгел (А. Әхмәдуллин, Г. Арсланов, Т. Галиуллин, Р. Рахмани, Ф. Миңнуллина, Н. Ханзафаров, Г. Шамуков һ.б.). Н. Исәнбәт гомеренең егерме елын педагогик эшчәнлеккә багышлаган: мөгаллим, методист булган, БАССР һәм ТАССР мәктәпләрендә укыткан, дәреслекләр язган.

Кызганычка каршы, татар мәдәнияте тарихында Нәкый Исәнбәтнең фәнни биографиясе әлегә кадәр язылмаган.

«Фәнни биография» төшенчәсе төрлечә шәрехләнә, әмма аның эчтәлеген билгеләгәндә, нигездә, Россия тарихчысы, Россия Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, тарих методологиясе, историография һәм интеллектуаль тарих өлкәсендә эйдәп баручы белгеч Л. П. Репина биргән билгеләмәгә таяналар. Асылда, ул Д. Уокер типологиясенә туры килә: фәнни биография – ул «шәхси, һөнәри, вазгыятькә ярашлы һәм библиографик характердагы фактлар җыелмасы» [Репина, 2009, с. 452–454].

Фәнни биографияне реконструкцияләгәндә, аның методологиясе биографик, тарихи һәм текстлар анализын күздә тота. Беренче чиратта, ул – биографиянең фактик ягы белән эш итү, моңа кадәр билгеле булмаган фактларны ачыклап, аларны фәнни әйләнештә булганнары белән чагыштыру һәм төгәллекләр кертү. Әмма шуңа карамастан, фактлар – биографиянең өлгесе генә, төп эчтәлек аларны ни рәвешле кабул итүдән, ягъни фактларга элек һәм вакытлар узгач нинди мәгънә салынудан гыйбарәт.

Татар әдәбият гыйлемендә Н. Исәнбәткә кагылышлы хезмәтләрдә (Г. Шамуков [Шамуков, 1959], Н. Ханзафаров [Ханзафаров, 1982], А. Әхмәдуллин [Әхмәдуллин], Р. Рахмани, Ф. Миңнуллина [Рахмани, Миңнуллина, 2017]) без галимнең педагогик эшчәнлеген өйрәнүгә игътибарның җитәрлек дәрәҗәдә булмавына яки тулаем битарафлык күрсәтү фактларына юлыктык. Бу исә энциклопедист галимнең тормышы һәм эшчәнлегенең егерме елы өйрәнү даирәсеннән төшереп калдырылган дигән сүз. Бу проблеманы өйрәнүгә без берничә фәнни хезмәт багышладык [Хәбетдинова, 2020; Хабутдинова, 2020]. Яңа фәнни хезмәтебез өчен материал итеп Нәкый аганың архив һәм биографик документлары, үзенең һәм шәкертләренең хатирәләре, шулай ук аның педагогик эшчәнлеге турында фикер йөртү мөмкинлеге бирә торган фәнни эшләре һәм мәкаләләре алынды.

Н. Исәнбәтнең педагог буларак формалашуына аның гаиләсе зур йогынты ясый. Галимнең әнисе Таибә абыстай – остазбикә, әтисе Сираҗетдин мулла була. «Бәби чак» дигән автобиографик повестенда Н. Исәнбәт үзенең яшьтән үк педагогик процесска җәлеп ителүе турында яза, чөнки өйдә әнисе кызларга сабак бирә.

«Нәсибашның Әхмәтша мәзиннең үзе дә, карчыгы Хәдичә дә, өендәге барлык балалары да – барысы да элеккечә укымышлы кешеләр булганнар. Аларның икенче баласы Таибә исемле булган. Минем әти Сираҗетдин, Троицкиның мәшһүр Зәйнулла ишан Рәсүли мәдрәсәсендә озак еллар укып, Малаязга кайткач, анда указлы мулла – имам-хатыйп – мөдәррис булган һәм шул Нәсибаш Әхмәтша мәзин кызы Таибәгә өйләнгән. Шул Сираҗетдин белән Таибәдән мин дөньяга килгәнмен. Ягъни Нәсибашның Әхмәтша мәзин – анам ягыннан, минем карт атай, аның карчыгы Хәдичә минем картинәй булалар. Малаяз исә – татар авылы, Нәсибашныкылар – мишәрләр, ә Хәдичә картинәй Лаклы авылыннан, алар исә – татарлар. Шулай итеп, нәселем ягыннан татар-мишәр миндә нык катышкан. Әнкәй Малаязда, мин үземне белә башлаганнан бирле, укымышлы остабикә булып, үзебезнең өйдә авыл кызларына сабак укыта иде» [Исәнбәт, 1999, б. 98].

Н. Исәнбәт «Бәрәзә песие Мыраубай маҗаралары» китабында билгеләп үткәнчә, Башкортстан Республикасының төньяк-көнчыгышында урнашкан Лаклы авылыннан «зур галимнәр, шагыйрьләр дә чыкканнар» [Исәнбәт, 1972, б. 64]. Н. Исәнбәтнең әнисе ягыннан бабалары нигез салган Лаклы мәдрәсәсе җирле халык арасында аеруча популяр булган (*Кара*: [Зинуров, 2004; 2010; 2015; 2021]). Г. Зиннуров билгеләвенчә, Н. Исәнбәтнең бабасы – Әхмәтсафа хәзрәт Баһаветдин 1884 елда мәдрәсә белән идарә итүне үз кулларына ала – Зәйнулла Рәсүлев Троицк шәһәрендә 5 нче мәхәллә каршындагы «Рәсүлия» мәдрәсәсенә дә шушы ук елны җитәкчелек итә башлый. Зәйнулла ишанның Лаклы мәдрәсәсенә күп тапкырлар килүе билгеле. Мәгърифәтче муллалар мәдрәсәдәге уку-укыту программаларын үзара киңәшеп төзегәннәр.

Таибә абыстайның әтисе – Әхмәтсафа ибне Баһаветдин ибне Шәмсавир ибне Гайсә ибне Сөләйман... ибне Сөендек... – татар дөньясына киң билгеле дин әһеле һәм җәмәгать эшлелесе, Уфа губернасы Златоуст өязе мөселманнары лидеры була. Ул Лаклыда ирләр (1894) һәм хатын-кызлар (1905) өчен рус-татар мәктәпләре ачу эшендә актив катнаша. Әхмәтсафа хәзрәт рус-татар мәктәбендә туган тел һәм дин сабакларын укыта. «Аның белем бирүне яңарту мәсьәләләрендә прогрессив карашлы булуы аркасында, Лаклы XIX–XX гасырлар чигендә Уфа губернасының төньяк-көнчыгышында тәрәккый белем бирү үзәгенә әверелә, һәм Оренбург мөселманнары Диния нәзарәте аңа Златоуст өязендәге бөтен мәктәп һәм мәдрәсәләрдә тикшерү белән йөреп чыгу бурычын йөкли. Шул сәфәрләренең берсендә Әхмәтсафа Баһаветдин Сираҗетдин муллаларга кереп, аның улы Әхмәтнәкыйга исем кушу йоласын үтәп чыга» [Зинуров, 2021, с. 138].

Нәкый Исәнбәт әнисен зур ихтирам һәм олы сөю хисе белән искә ала: «Минем анам (татар хатыны) минем җисемемне дөньяга китереп кенә калмаган, мин тугач та, иң элек минем рухи байлыгымны кайгырткан: телем кешегә татлы, ягымлы булсын дип, мине бал-май белән авызландырган. Туганда сөйләр телем юк, ул миңа үз телен

биргән. Рәхмәт аңа, ул миңа тел аңы – уй-мәгънә бирүе белән мине аталы-аналы, туган халыклы һәм шуның белән тарихлы, үз мәдәниятле иткән, бәхетле иткән. Аннан соң ул мине үз телемдә хәреф танырга, укырга өйрәтте. Чөнки ул сабак абыстае – остазбикә иде. Мине үз өебездә, үз сәкебездә, авыл кызчыклары белән бергә, көйләтеп, "Бәдәвам"нар әйттерде, ягъни хәреф тану белән, минем кулыма борынгы Болгар, Казан әдәбиятын тоттырды, "Йосыф китабы"-на төшерде. Күрәсең, без үзебез патша вакытында чабатага калган булсак та, бабаларыбыз итек кигән, асылда без, чынлап та, борынгы зур культуралы халык балалары икәнбез, чөнки үз сәкебездә утырып, шул чабаталы авыл кызыйлары белән бергә, үзебезнең шул мең еллык классик әдәбиятыбызны кулларыбызга тотып, нәкъ борынгы үз язма төрки телендә үк көйләп укырлык хәлдә булганбыз... Безнең үз сәкебез һәм кыз балалар өчен сабак йорты катнаш мәктәп урынын тоткан» [Исәнбәт, Мин ничек шагыйрь булдым, б. 1].

Н. Исәнбәт аның дөньяны танып белү ягыннан зәвыгын формалаштыруда әнисе хәлиткеч роль уйнаган һәм киләчәктә һөнәри кызыксыну даирәсен билгеләгән дип саный: «Рәхмәт әнкәемә: ул мине уку-язудан кызык һәм мәгънә табарга, үз әдәбиятыбыздан ямь-тәм һәм рухи азык алырга өйрәтте, киләчәктә үзем дә язучы булуыма нигез салды, юл ачты. Рәхмәт аңа, югыйсә бит, кем белә, бәлки, кайбер бушбугазлар кебек, туган телсез, ягъни ил эчендә илсез, туган халыксыз, нәсел-нәсәпсез, үз җиремдә килмешәк я бер йорт тотмасмы-кем булып калган яки дә, Алла сакласын, каядыр "киртә сикергән" берәр бәндә булып калган булыр идем...» [Исәнбәт, Мин ничек шагыйрь булдым, б. 1].

Н. Исәнбәт «Бәби чак» дигән автобиографик повестенда остазбикә әнисе көндәлек сабакларында кулланган уку-укыту һәм методик әдәбиятны анализлап, аларның, мәсәлән, «Бакырган», «Мәрьям ана китабы», «Ярым алма» кебек китапларның, дидактик һәм онтологик куәсен билгели. Галим бик тә кыйммәтле күзәтүләре белән уртаклаша: «Бигрәк тә гаҗәбе: менә мин бәләкәй чакта безнең өйдә сабак абыстае булган әнкәйнең моннан 800 ел элек язылган китаплар белән Малаяз кызларына сабак укытуы иде. Хәер, моның шулай икәнен әнкәй үзе дә белми, бик күп сабак абыстайлары – бар да шул китаплар белән сабак укыйлар, һәм берсе дә шул китапларның 800 ел элекке әсәрләр булуын белми иде, күрәсең, белергә кирәкми дә иде. Үзебезчә ич» [Исәнбәт, 2000, б. 94].

Н. Исәнбәт үзенең хатирәләрендә остазбикә әнкәсендә гыйлем өйрәнүнең индивидуаль характерын аерып күрсәтә: «Кызларның берсе килә, берсе кайтып китә, сәгать юк, һәркемгә үзенчә иде. Һәркайсының укуы китапның төрле җиреннән иде. Һәр кыз сабагын көйләп укый, хәтта хәреф көйләп әйтелә иде. Шулай бер ел көйләп йөргәч, әллә ничек кенә укырга да өйрәнеп чыгалар иде. Вак кызлар олы кызлар алдында идәндә тезләнеп йә чүгәләп йөреп, йә алар артына сәкегә тезләнеп утырып көйлиләр. Шул ук вакыт алларындагы утырган

зур кызларның чәч толымнарын да рәтләштереп алалар иде. Буйчанрак кызлар көйле китапларны кычкырып, көйләп укыйлар. Аларның китаплары төрле булган кебек, һәркайсының укый торган урыны да, бите да аерым-аерым үзенә бер җирдән иде» [Исәнбәт, 2000, б. 92].

Әтисенең мәдрәсәсендә уку башка характерга ия була: «Әни мәктәбеннән чыгып, әти мәктәбенә укырга күчтем. Монда эш бүтән. Чөнки монда үлем түгел, яшәү һәм шул замандагы татар тормышы, Казан каласы, Кама каласы, Уфа каласы, утын чанасы, тас, шулай шәһәрләр. Дөнья. Монда хәзрәти Мәрьям, Бакырганнар түгел, кулында Тукай, Гафури шигырь китаплары» [Исәнбәт, 2000, б. 94]. «Бу ярым җәдитче мәдрәсә. Монда татар әлифбасы белән укытыла, гарәпчә түгел. Казанда басылган әлифба китаплары килә. Бала ана телен таныгач кына, төрки өйрәнә, әдәбият …, хисап, география, кыйраәте төрки (төрки телендә уку) өйрәнә. Тарих фәне үтелә (“Тарихы әнбия”, ягъни “Пәйгамбәрләр тарихы”), татар тарихы юк иде. Югарырак классларда гарәпчә укырга өйрәтәләр (Коръән, догалар һ.б.)» [Ханзафаров, 1982, б. 11–12].

Башлангычны тәмамлагач, 1910 елда Н. Исәнбәт Зәки абзые белән Уфага, Сабир хәзрәт мәдрәсәсенә укырга китә. «Мин укыган ул мәдрәсә, дини дип йөртелсә дә, ул дини түгел, фәнни мәдрәсә. Анда тарих, җәгъръәфия, математика, һәндәсә (геометрияләр) укытыла, ул тик патша хөкүмәте татарга бары дини мәктәп тотарга рөхсәт иткән өчен тыштан гына шулай «дини» дип атала. Әмма 5 нче ел революциясе һәм аннан соң мәдрәсә, гомумән, үзе, эчтән шәкерт күтәрелешләре белән программасын алыштырып, эчтәлеген дә алыштырып, дөньявига әйләнеп беткән, дин сабагы исә рус мәктәп һәм университетларындагыча «Закон божий» сәгатьләре булып кына калган, бу реформадан хәтта мәгълүм реакционер Сабир Хәсәни мәдрәсәсе – бу без яткан мәдрәсә дә читтә калмаган иде», – дип яза әлеге уку йорты турында Н. Исәнбәт үзенең хатирәләрендә [Исәнбәт, Биографиям, б. 1].

Абыйсы аркасында Н. Исәнбәт бер ел Рус Малаязы авылында рус казна мәктәбендә укырга мәҗбүр була. Ике төрле укыту системасын чагыштырып карау мөмкинлеге милли мәгариф системасы файдасына хәл итеlә: «11 нче елда Рус Малаязы дигән күрше авылда икенче класска кереп, русча бер ел укуымны әйткән идем. <...> Ул миңа хәтта бик көлке, казенный булып тоелды. Чөнки анда стенада зур итеп буяулап ясалган патша белән патша хатыны рәсеме һәм почмакта тәре икона тора, һәр көн иртән поп кереп, балаларны икона алдына бастырып чукындыра һәм үзенең сасы чиркәү кадилы белән безгә, татар малайлары өстенә юри төтен бөркетә, ул безгә христиан рухы, рус коллыгы рухы сеңдерергә – “чукындырырга” тырыша иде. Стеналарда ничек “татар игосы” белән сугышып, илләрен, җирләрен басып алуны күрсәткән һәм татарны колонизацияләүне данлаган рәсемнәр эленгән иде. Дини святойлар турындагы рәсеме язылган, төшерелгән китаплар бирелде. Мин славян хәрефләренең матурлыгына кызыгып, аларны укый, әмма инде эчтәлегеннән көлеп һәм җирәнеп утырырлык аңым да бар иде...» [Исәнбәт, Биографиям, б. 3].

«Прогрессив аңны – мәдрәсә һәм яңа татар әдәбияты биргән иде. Хәлбуки, ул рус школасында укыганда, миңа бары 12 яшь иде. Рус мәктәбенең бу дәрәҗәдә түбән, дини, схоластика оясы булуын күргәч, минем исем китте. Әле бит бу дөньяви, тәртипле һәм гыйльми аталган рус казна школасы иде», – дигән нәтиҗә ясый галим [Исәнбәт, Биографиям, б. 4].

1912 ел көзендә Н. Исәнбәт абыйсы белән тагын Уфага, әлеге «Хәсәния»гә өченче рөшдигә укырга китә. Әлеге уку йортының халыкчан булуы белән горурланып яза: «Ул татарның милли мәктәбе иде». Ул шулай ук әлеге мәдрәсә аның үзбилгеләнүе формалашуга зур йогынты ясады дип ышана: «Мин үзем мәдрәсәдә татар телен һәм әдәбиятын, башлап, Тукай язган дәреслекләрдән укыдым. Кульязма революцион җырларны да шул мәдрәсәдә җилем матбагадә басылган “сада”ләрне, “Марсельеза”лар җырлап үстем. Шулар аша үземнең кем булуымны танып белергә, үз хакым өчен үзем тора белергә, берләшеп көрәшергә шунда өйрәндем» [Исәнбәт, Биографиям, б. 1]. Уфада Н. Исәнбәткә төрки кавемнәр тарихын Хәсәнгата Мөхәммәт улы Габәши (1863–1936) – композитор Солтан Габәшинең атасы укыткан.

Күренекле татар галиме, тарихчы, мөгаллим, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, җәдитчелек хәрәкәтенең мәшһүр вәкиле Сираҗетдин муллага улы Нәкый тарихтан яхшы укыганга, Казанга белем эстәргә җибәреп, аннан мулла түгел, ә Мәрҗани кебек галим, «мөчтеһәт» тәрбияләргә кирәк, дип киңәш биргән [Исәнбәт, 2000, б. 101].

1914 елда Казанга килеп, Н. Исәнбәт «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә беренче сыйныфка укырга керә. «Нәкый белән очрашкан вакытта без рөшдия бүлегендә укый идек. Бу бүлектә иң әһәмият бирелгән фәннәр – риязият (математика) фәннәре, татар теле һәм әдәбият, тарих, җәгърәфия иде. Гарәп һәм рус телләре аерым тел дәресләре булып укытылалар иде», – дип яза үзенең истәлекләрендә Бакый Урманче. Н. Исәнбәт каләменең көче, кодрәте шул вакыт сынала башлый. Чордашы турында уйланганда, бөек рәссам энциклопедист галимгә шундый бәя бирә: «Алдынгы татар мәдрәсәләренең дәресханәләрендә (аудитория) аякка баскан һәм гомер буе гыйлем һәм сәнгать өлкәләрендә ясаган кул хезмәтләрен мәдрәсәдә корылган фундамент өстенә нигезләгән абыз агаларыбызның берсе» [Урманче, б. 131].

Үзенең автобиографиясендә Н. Исәнбәт мәдрәсә тәмамлаганнан соңгы тормышын болай тасвирлый: «1916 елның көзендә мин Казаннан кайтып киттем. Укырга карар бирдем. Әнинең туган авылы Нәсибашка килеп, башлангыч рус мәктәбенең 4 нче сыйныфына кереп, тәмамлап чыктым. Февраль революциясен мин анда каршыладым».

«1917 елның җәендә якындагы Үрге Кыйгы авылында кыска мөддәтле педагогия курслары ачылды. Мин шунда укырга кердем. Көзен Атаудагы алты еллык татар мәктәбенә тел-әдәбият дәресләре укытучысы булып киттем» (01.10.1917–31.12.1918) [Исәнбәт, Тәрҗемәи хәлем, б. 7].

Атауны Н. Исәнбәт шунда яшәгән татар зыялысы Һади Сәгъди аркасында сайлаган: «Һади, ул профессор Габдрахман Сәгъдинең агасы, башта Атау мулласы булып торган, гыйлем белән, зирәклек һәм ораторлык белән дан казанган кеше иде. Ул 1905 елдан соң муллалыгын ташлап, русча укырга керешкән, дөнья классик әдәбиятын нечкә төшенүче, шуның өстенә мәдәният, фәлсәфә тарихларын шактый моталәгә иткән кеше иде. Язган әсәрләрен "Сабир" псевдонимы белән чыгарган, берничә хикәясе дә бар. Аны "дәһри, Коръән таптаган" дип, күп эзәрлекләп тә йөргәннәр, мин күргәндә, шактый изелгән кеше иде. Анда комсызлыкның әсәре дә юк, Толстойча үзе кара эштә эшли иде. Менә мин шул яхшы кешегә фатирга кердем. Мин килгәндә, ул "Бакунинның тормышы һәм тәгълиматы" дигән әсәрен тәрҗемә итеп ята иде. Тәрҗемәне беркем өчен дә түгел, үзе өчен эшли, Һади Сәгъди кулакларны бер дә яратмый, Ленинга мәхәббәте зур иде. Шул яклардан без аның белән фикердә килешеп киттек. Октябрь революциясен мин Атауда каршы алдым. Һади Сәгъди Мулланур Вахитов чыгарган «Чулпан» газетасына яза, мин дә шигырьләрне анда җибәрә идем» [Исәнбәт, Тәрҗемәи хәлем, б. 9].

1918 елның май аенда Һади Сәгъди белән Ари авылына ялга барганда, юлда Мияшәгер авылында сәнәкчеләр Н. Исәнбәтне кулга алалар: «Икебезне дә, "болар динсезләр, большевик газетасына язучылар" дип, бик җәфалап йөрттеләр... Озакламый Һади абзыйны үз волостеннан килеп, бәйләп алып киттеләр. Мин бу камерада ике атналап яттым. Безне Минсөяр һәм Кытау заводыннан килгән кызыл частьләр килеп коткардылар. Алай да бу сәнәк явы мине бик нык имгәтте» [Исәнбәт, Тәрҗемәи хәлем, б. 11]. Нәсибаштагы әнисе ягыннан туганнары корбан була, Хәдичә әбинең кызлары һәм кияүләре генә торып калалар.

Н. Исәнбәтнең педагогик эшчәнлеге башланган вакыт шул төбәктә гражданнар сугышы барган чорга туры килә: «Бу вакыт Уфа губернасын тимер юл сызыгы буенча Самарага хәтле Чехословакия интервенциясе басып алган иде. Кышын Колчак монархиясе каплап китте. Златоуст земствосында мәгариф бүлегендә эшләүче Рәхмәтулла абзый Еникеев мине, татар, башкорт контрреволюционерлары үтерүдән саклап калу өчен, өязнең иң ерак почмагы булган Тастүбә дигән рус авылына укытучы итеп җибәрде. Анда мәктәптә унлаган татар баласы укый, мин аларга татар теле, әдәбияты укытырга тиеш булдым. Билгеле, авылда да акларның командалары тора, миннән шикләнсәләр дә, яхшылап белүче булмаганга, артык борчучы да булмады. Алгы җәйне кызыл гаскәр килеп җитеп, безнең өязне тагын азат итте» [Исәнбәт, Тәрҗемәи хәлем, б. 12]. Тастүбәдә Н. Исәнбәт 1918 елның 31 гыйнварыннан 1919 елның 31 июленә кадәр эшли. Мөгаллим булгач, армиядән аңа отсрочка бирәләр (31.07.1919–19.11.1919). Шул вакытта Златоуст өязендә вакытлыча мәктәп инструкторы вазифасын үти башлый. 1919–1920 елларда Н. Исәнбәт Кыйгыда (10.08.1920–25.08.1920) һәм Мәсәгутьтә (19.11.1919–10.08.1920) укыта. Шул елны Уфага Халык мәгарифе институтына укырга керә (25.08.1920–17.05.1921). Җәен

мөгаллим Дуван-Кушчы мәгариф бүлеге оештырган курсларда укытучылар өчен лекцияләр укый (17.05.1921–28.07.1921) [Исанбет, Трудовой список, Второй раздел].

1921 елгы ачлык башлангач, Н. Исәнбәт Харьков университетына укырга китә. Харьковта Украина партиясе Үзәк Комитеты секретариатында татар секциясенең тәрҗемәчесе булып эшли башлый (21.08.1921–15.11.1921), Мәгариф буенча халык комиссариаты татар шахтёрлары өчен оештырган 6 айлык педагогик курсларда лектор вазифасын үти (15.11.1921–05.02.1922) [Исанбет, Трудовой список, Второй раздел]. Уку йортының статусы үзгәргәч, югары уку йортында төп фәннәрне украин телендә укыта башлыйлар, шуның өчен Н. Исәнбәт иптәшләре белән Мәскәүгә китә. Ул Шәрык халыклары хезмәт ияләре Коммунистик университетында марксизм әдәбиятын татарчага тәрҗемә итү секциясенә «студент» сыйфатында языла (09.02.1922–01.10.1922). Н. Исәнбәт бу хыялының тормышка ашмавын хатирәләрендә түбәндәгечә аңлата: «22 нче елның көзендә миңа бу университетта студент булып калу мөмкин иде. Ләкин партия әгъзасы булмаган хәлемдә Ком. университетта укырга хакым юк иде». [Исәнбәт, Тәрҗемәи хәлем]. Н. Исәнбәт Мәскәүдән янә туган якларына кайта. 1923 елның апреленнән июльгә кадәр мөгаллим Мәсәгутьтә техник хезмәткәрләр өчен оештырылган курсларда арифметика укыта. Педагогик курсларда математика, табигать белеме, политграмота фәннәре буенча белем бирә (10.06.1923–05.08.1923.) [Исанбет, Трудовой список, Второй раздел].

Көз көне Уфаның 4 нче мәктәбенә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшкә урнаша (01.10.1923–09.09.1929) [Исанбет, Трудовой список, Второй раздел]. 1924 елның ахырында Н. Исәнбәт Гөлсем ханымга өйләнә. «Уфаның 4 нче татар мәктәбендә һәм партшколада Нәкый дәресләр алып бара, мәктәптә әдәби түгәрәкләр, әдәби кичәләр үткәрә, стенгазеталар, кулъязма әдәби журналлар чыгару аның өстендә. Ул аларны зур дәрт, канәгатьләнү белән эшли, укучыларның әдәби зәвыгын тәрбияләп, әдәбият мәйданына тарта. Шундагы укучылар арасыннан Эмма Шамил, Газизов, Рәхим Саттаров, Хәсән Гобәйдуллин һ.б. үзләренең каләмнәре, язу сәләтләре барлыкны күрсәттеләр. Һәм шулай ук күп кенә талантлы яшьләрдән байтагы бүгенге көндә дә күренекле эшләр алып баралар», – дип яза үзенең истәлекләрендә Гөлсем Исәнбәт. 4 нче мәктәптә Н. Исәнбәт Закир Шакиров кул астында эшли. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыганда, Закир абый аның сыйныф җитәкчесе булган.

1928 елда Н. Исәнбәт Ленинград галимнәре белән бергә Башкортстан буйлап оештырылган фольклор экспедициясенә чыга. СССР Фәннәр академиясенең Башкорт комплекслы экспедициясен күренекле тюрколог Н.К. Дмитриев җитәкли. Фәнни төркемнәрнең маршруты түбәндәге юнәлешләр буенча үтә: 1) Белорет – Тукан – Усмангали; 2) Белорет – Тирлян – Миәс; 3) Белорет – Сәрмән – Инзәр. Әлеге экспедициядән белгечләр бай фольклор материаллары туплап,

курайчыларның уйнаганнарын фонографка яздырып алып кайталар. З. Шакиров төркеме Аргаяш, Коншак, Ялан-Катай якларын өйрәнгән. Йолдыз Исәнбәт архивында Н. Исәнбәтнең 1928 елда информантлардан язып алган «Идегәй» эпосын тапшыруы турындагы расписка кәгазе саклана. Шушы материал нигезендә галим «Idukəj həm Moradum» эпосының җыелма текстын төзеп, 1940 елда Уфада бастырып чыгара [«Idukəj həm Moradum», 1940].

Г. Исәнбәтнең хатирәләре безгә бик кызыклы тоелды: «Җәйләрен капчык асып, авылларга чыгып, фольклор җыю – Нәкыйнең яраткан эше иде. Шул җыйган материаллары буенча бер кышны утырып, «Башкорт халык әдәбияты теориясе һәм хрестоматиясе» дигән 40 табаклы, зур эчтәлекле китап язып, Башгизга тапшырды. Бастыру өчен килешү төзелсә дә, “Җидегән” вакыйгасы килеп чыккач, аны басмадылар. Без Казанга күчеп килгәннән соң берничә ел үткәч, үзебезгә кире кайтарып бирделәр. Бүген дә үзебездә әле» [Син сазыңны уйнадың, 2000, б. 14].

Н. Исәнбәт параллель рәвештә Башкорт совет партия мәктәбендә татар теле укыта (1925 елның августыннан 1926 елның 1 сентябренә кадәр). 1927 елда Алласызлар союзының Өлкә оештыру бюросы әгъзасы була.

1929 елның 16 апреленнән 1930 елның 15 февраленә кадәр Нәкый Исәнбәт Уфада Башкорт сәнгать техникумында башкорт теле һәм әдәбияты укыта [Исанбет, Трудовой список, Второй раздел].

Уфада Н. Исәнбәт уку-укыту әсбап-дәреслекләрен төзү белән шөгыльләнә. Шул рәвешле 1922 елда ул С. Коганның «Башкортстанда табыла торган дару үләннәрен җыю өчен кыскача кулланма»сын тәрҗемә итә [Коган, 1922, б. 14]. 1926 елда «Исламның дөньяга карашлары» [Исәнбәт, Исламның дөньяга..., 1926] китабын бастырып чыгара. Һ. Сәгъди белән бергәләп башкорт һәм татар мәктәпләре өчен әлифбалар төзи: «Яшь буын» [Яшь буын, 1926], «Яңа мәктәп» [Яңа мәктәп, 1927].

1930 елның башында Н. Исәнбәтнең «Портфель» пьесасы куелу сәбәпле, аны тәнкыйть утына тоталар, шул ук вакытта Уфаның фәнни даирәсендә «советка каршы элементлар»дан чистарту эшләре башлану белән бәйле, аны да кулга алу куркынычы яный. 1929 елның сентябрендә фәнни экспедицияләр эшендә борылыш була: «иске белгечләрдән» арына башлыйлар. 1929–1930 елларда кулга алу очраклары күбәя. 1929 елда җитәкчелек кулга алына, аннан соң СССР Фәннәр академиясенең гади хезмәткәрләренә чират җитә. Е.Н. Алдашева язуынча, галимнәр эше кысаларында 1500 белгеч кулга алына [Алдашева, 2011, с. 92–96].

Н. Исәнбәт гаиләсе белән Уфадан Казанга күчеп килә. 1930 елның 23 февраленнән 3 сентябренә кадәр Н. Исәнбәт Казанның сәнгать техникумында татар теле һәм әдәбияты укыта. Әмма «Җидегән» эше буенча эштән китәргә мәҗбүр була [Исанбет, Трудовой список, Второй раздел].

Мөгаллимлек эшчәнлегенә ул ике ел узгач кына әйләнеп кайта. 1932 елның 1 октябреннән 1933 елның 1 сентябренә кадәр Н. Исәнбәт Татарстанның Казан кооператив комбинатында дингә каршы дәресләр бирә. Эшеннән китү сәбәбе – «уку программасыннан предмет циклының төшеп калуы». 1932 елның 31 октябрендә Казан уку-җитештерү комбинатында математика укыта башлый. 1933 елның 16 сентябреннән 1934 елның 1 сентябренә кадәр Энергетика техникумында татар теле укыта. 1934 елда уку йортының башка шәһәргә күчеп китүе сәбәпле, эшеннән китә. 1933 елның 14 апрелендә Н. Исәнбәт Кооператив техникумына татар теле укытучысы булып килә. 1935 елның 11 августында КХТИ рабфагына татар теле укытучысы итеп кабул ителә [Исанбет, Трудовой список, Второй раздел]. Язучының архивында Н. Исәнбәтнең ударник булуы турында җирле комитеттан белешмә саклана. СССР Язучылар берлеге әгъзасының шәхси битендә язучы үзенең әлеге курсларда 1932 елның декабреннән 1936 елның мартына кадәр укытуын күрсәтә [Исанбет, Личный листок члена СП СССР].

Репрессия елларында Н. Исәнбәт Казан артына укытырга китә. 1938 елның 20 маенда язучы һәм галим Әтнә районы халык мәгарифе бүлегенең методик кабинет мөдире вазифасына билгеләнә. 1938 елның 1 сентябреннән Әтнә урта мәктәбендә әдәбият укыта башлый. Хезмәт таныклыгындагы язмаларга караганда, 1938 елда Н. Исәнбәт Әтнә районында методик кабинет хезмәткәре була. ТАССР Халык мәгарифе комиссариатының 1938 елның 2 июленнән 599 нчы санлы фәрманы (Казан, Кремль) белән Әтнә районара кабинеты директоры Исәнбәтов Н. Арча училищесына читтән торып укучыларның сессиясе вакытына укытучы итеп билгеләнә. Язучының архивында бу чор турында кызык хатирәләр саклана: «Әтнә. 1938–1939. Миңа монда педкабинет оештыру эше тапшырылган. Кичә генә монда педология булса, бүген педагогия. Әбиләр әйтмешли, Алланың кодрәте, бәндәнең хикмәте. Көне белән бар, көне белән юк. Бар да бер кул селтәү белән берсе бар ителә, икенчесе юк ителә. Нигә, ни өчен дип сорама. Шулай кушылган, кирәк. Бер без түгел, ил белән. Билгеле, мин 1917 елдан ук педагог булганга, үзем дә – педкабинет якчысы. Тезәбез икән тезәбез, стенага плакатлар, каяндыр югарыдан өзлексез агылып килгән фотолар эләбез. Матурлыйбыз. Билгеле, болар бар да эшнең инструкцияләр кушуы буенча эшләнгән рәсми һәм кәҗүнни яклары... Иң элек бу педкабинет үзе Әтнә һәм Кызыл юл районнары өчен ике районга бер. Мин исә – кабинетым өстенә Әтнә урта мәктәбендә югары классларда тел-әдәбият укытучысы да. Аңардан бушаган көннәремдә мин районга чыгып, андагы мәктәпләр, уку-укыту, тәрбия эшләрен карап йөри алам. Минем өчен эшнең җанлы һәм кызыклы җире дә шул ноктада. Чөнки мин бу чагында мәктәпләр белән турыдан-туры бәйләнешкә кереп кенә калмыйча, калган вакытымда Казан арты авыллары белән дә аз да булса таныша, тел-фольклор материалларын җыя алам» [Исәнбәт, 1958, б. 15–16].

1938 елның 6–28 июлендә Н. Исәнбәт Арча педагогика училищесы каршындагы читтән торып уку секторында татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасыннан дәресләр бирә. 1938 елның 15–19 августында Әтнә методик кабинеты каршындагы укытучылар киңәшмәсендә укытучы була. 1938 елның 15 ноябрендә Әтнә районара методик кабинет директоры вазифасын үти башлый. 1939 елда Казанга эшкә күчерелә. 1939 елның 8 февраленнән – Өлкә методик кабинетында мөдир. Биредә 1939 елның 11 апреленә кадәр эшли [Исанбет, Трудовой список, Второй раздел]. 1939 елның 7 маеннан – НКЛда өлкәннәрне укыту кабинеты методисты. 1940 елда исә Н. Исәнбәт үзенең педагогик эшчәнлегенә нокта куя [Исанбет, Личный листок члена СП СССР].

1940 елдан Н. Исәнбәт бөтен көчен куеп фольклор материалларын системага салу белән шөгыльләнә. Шуның бер нәтиҗәсе – балалар өчен чыгарылган җыентыклар: «Татар халкының балалар фольклоры» [Татар халкының балалар фольклоры, 1941], «Татар табышмаклары» [Татар табышмаклары, 1941]; «Ни өчен ни булган, яки утыз ялган» [Исәнбәт, 1956], «Уеннар турында. Нәниләр шатлана» [Нәниләр шатлана, 1967], «Татар халык табышмаклары» (1970), «Балалар дөньясы» [Балалар дөньясы, 1970], «Отканда мәкаль, тапканда табышмак» [Отканда мәкаль... 1973], «Балалар фольклоры» [Балалар фольклоры, 1984].

Галимнең педагогик карашлары югарыда саналган җыентыкларда урын алган фәнни мәкаләләрдә чагылыш тапкан. Аларда, кагыйдә буларак, теге яки бу жанр формаларының поэтик үзенчәлекләре ягыннан гомумиләштерүләрдән тыш, практик педагог фольклор әсәрләренең балалар тәрбияләүдәге, баланың интеллектуаль, коммуникатив, физик һәм иҗади сәләтләрен үстерүдәге роленә кагылышлы күзәтүләре белән дә уртаклаша. Галимнең «Балалар фольклорының тәрбияви роле һәм әһәмияте» дигән мәкаләсе әле дә актуальлеген югалтмаган [Балалар фольклоры, 1984, б. 444–446]. Халык мәкальләренең функциональ яктан потенциалы турындагы кыйммәтле фикерләрен Н. Исәнбәт «Мәкальләр турында» дигән мәкаләсендә әйтә [Балалар фольклоры, б. 448–454]. Галим татар табышмакларының барлыкка килү һәм халык арасында таралу тарихын өйрәнеп, «Яңа табышмаклар чыгару» мәкаләсендә заманча табышмаклар иҗат итү буенча укучыларга үз киңәшләрен бирә [Балалар фольклоры, б. 463–464]. Н. Исәнбәтнең халык уеннарының әхлакый һәм тәрбияви потенциалы хакындагы «Уеннар турында» мәкаләсе бүген дә педагоглар тарафыннан кулланма буларак файдаланыла ала [Балалар фольклоры, б. 464–480].

СССР Язучылар берлеге әгъзасының 1952 елның 15 декабрендә тутырылган Шәхси битендә күрсәтелгәнчә, Н. Исәнбәт Татарстан Язучылар берлегенә 1939 елның 3 ноябрендә кабул ителгән. Һөнәри язучылык эшчәнлегенә хокукка ул 1942 елның 23 маенда гына ия булган [Исанбет, Личный листок члена СП СССР]. Н. Исәнбәт – ши-

гырьләр, хикәяләр, повестьлар, балалар өчен язылган драма әсәрләре авторы. Эше тыгыз булуга карамастан, ул мәктәп укучылары һәм югары уку йортлары студентлары өчен оештырылган конференцияләрдә теләп катнашкан. Галим милли мәдәниятне актив пропагандалаган, студентлары Ш. Абдуллин [Абдуллин, 1999, б. 5], Л. Бадыйкшан [Бадыйкшан, 1999, б. 5], Р. Батулла [Батулла, 1997, б. 189–197; 2007, б. 246–263], М. Госманов [Госманов, 2010], хезмәттәш мөгаллимнәре [Зингаров, 1996] һәм үз хатирәләре дә шуны раслый. Бу очракта педагогның укыту-методик лабораториясе турында күзаллау тудырырга мөмкинлек бирә торган истәлекләр аеруча кыйммәтле. Мәсәлән, 1938 елда аның укучысы булган М. Заһидуллина Н. Исәнбәтнең әдәбият дәресләрендә укучыларның белем дәрәҗәләрен киңәйтүдән тыш, сәнгатьле уку күнекмәләрен арттыруга да зур игътибар бирүен ассызыклап искә ала: «Бу дәрестә Нәкый ага безгә Габдулла Тукай иҗаты турында сөйләде һәм бик матур итеп “Теләнче” шигырен яттан укыды. Без, авыл балалары, әле авыл мәктәпләрендә андый оста сәнгатьле итеп сөйләүчене очратканыбыз булмаганга, үз укытучыбызның шундый оста итеп укуына шатланып туя алмадык». Н. Исәнбәт дәрестән тыш эшләр вакытында да укучыларында фольклорга һәм әдәбиятка кызыксыну тәрбияли: «Исәнбәт абый (без аны шулай дип атый идек) дәрестән тыш вакытларда да безнең белән булырга вакыт таба. Кайбер кичләрдә безнең гомуми торакка керә иде, безнең белән озак-озак утыра, сорауларыбызга тулы җаваплар бирә, әкиятләр сөйли, табышмаклар әйтә, ә без җавапларын таба идек. Без дә үзебез белгән әкиятләрне сөйли, мәкаль-табышмакларны әйтә, бергәләп уйный торган төрле уеннарны уйнап күрсәтә идек. Исәнбәт абый аларның кайберләрең язып та ала» [Заһидуллина].

Н. Исәнбәт Казан арты авылларында сакланган иске кульязмаларны җыя, чөнки сәясәт аркасында аларның юкка чыкканын күрә. Үзенең хатирәләрендә бу фаҗиганы шулай итеп тасвирлый: «...иске кәгазь кульязмаларына ныграк илтифат итә башладым. Бу мин йөргән елларда татарда латин хәрефенчә эш йөртелә, 30 елга кадәр булган элекке гарәп язмалары һәм китапларын нindидер надан һәм усал ниятле кешеләр барысын да контрлык дип атап, хәтта алар Маркс-Ленин әсәрләре булса да, юкка чыгарырга тырышалар, алар тиз арада югалачак гарәп, латин хәрефендә булганы өчен генә барын да өеп яндыралар, шунлыктан тарихи һәм бүгенге көн өчен әһәмиятле документлар тиз арада юкка чыгачак» [Исәнбәт, 1958, б. 85].

Әтнә мәктәбенең математика укытучысы В. Зингаров 1938 елда Н. Исәнбәт белән бергә эшләвен искә төшереп, укучыларның татар әдәбияты дәресләрен түземсезлек белән көтеп алуларын әйтә. Әтнә районында Н. Исәнбәткә нисбәтле халык театры барлыкка килә [Зингаров, 1996].

«Ватан сездән эш көтә!» [Ватан сездән эш көтә, 1979, б. 3], «Минем язучы булуым һәм халык иҗатын өйрәнүем» [Исәнбәт, 1960] дип аталган һәм башка интервьюларында галим балаларны фольклор ма-

териаллары җыярга өндәве турында әйтә һәм аларның әдәби иҗатка сәләтләрен үстерү буенча киңәшләр бирә: «Мин егерме ел буена укытучы булдым, татар теле һәм әдәбияты укыттым. Мин балаларга һәрвакыт җырлар, мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар җыеп килергә кушам. Бу – балалар өчен ифрат кызык эш. Гаҗәеп рәвештә ярата бит алар фольклорны! Туган телең әнә шуннан башлана бит. Халкыңның авыз иҗатын яратсаң, аны өйрәнсәң генә, бишектән үк килгән моңыңны, күңел байлыгыңны саклап калырга мөмкин» [Ватан сездән эш көтә, 1979, б. 3].

Н. Исәнбәт үзенең педагогик практикасында балаларның иҗади потенциалын үстерүгә зур игътибар бирә: «Шигъри тәрбия хакында йәнә шуны әйтәсем килә: үзең яраткан шигырьләрдән альбом төзүне мәктәпләрдә кагыйдә итеп кертәсе иде. Укучылар шигырь сайларга, яхшыны яманнан аерырга өйрәнәчәк, аларның зәвыклары үсәчәк. Без укып йөргән чакларда һәркемнең бәләкәй генә матур бер сандыгы һем ул сандыктагы китап-дәфтәрләр янында бер шигырь альбомы була иде...» [Ватан сездән эш көтә, 1979, б. 3].

Н. Исәнбәтнең: «Сез, балалар, культуралы, белемле, һәрнәрсә белән кызыксынучан булып үсәргә тиешсез. Ватан сездән эш көтә! Онытылмаслык эш, игелекле һәм фидакяр эш көтә», – дигән теләкләре энциклопедист галимнең һәркайсыбызга атап әйтелгән рухи васыяте кебек кабул ителә [Ватан сездән эш көтә, 1979, б. 3].

Н. Исәнбәт – мәгърифәтче, татар фольклоры, теле һәм әдәбияты фәнен популярлаштыруда тиңе булмаган олпат галим. Бүген югары уку йортларында лексикология, фразеология, грамматика, халык авыз иҗаты, татар әдәбияты тарихы буенча лекцияләр укыганда, без даими рәвештә Н. Исәнбәт мирасына мөрәҗәгать итәбез. Аның хезмәтләре һәрвакыт студентларда кызыксыну уята. Н. Исәнбәтнең этимологик анализлары һәм тарихи-мәдәни шәрехләмәләре мәктәп укучыларының һәм студентларның татар лексикасы һәм фразеологиясе өлкәсендә фәнни танып белү офыкларын киңәйтә. Сүз сәнгатенең бөтен нечкәлекләрен белгән Н. Исәнбәт татар телен өйрәтү текстка юнәлтелгән шартларда текстка лингвистик анализ ясау өчен җирлек әзерләп калдыра. Галим тарафыннан эшкәртелгән тел фактлары һәм аларның лингвистик интерпретацияләре укытучыны татар телен тирәнтен өйрәтү мөмкинлеге белән тәэмин итә, туган телгә сак караш һәм милли үзаң тәрбияләргә ярдәм итә.

Талантлы тел белгече Н. Исәнбәтнең үткен карашы шундый лексик-грамматик берәмлекләрне аерып билгели ки, аларның шәрехләмәләре аеруча кызыклы һәм бу исә татар теленең үсеше һәм кулланылышы, телдәге алдынгы процессларны мирас итеп алу традициясе, хәзерге заманда кулланылышта булган лексик берәмлекләрнең (барлыкка килгәннән алып) беренчел семантикасы белән концептуаль бәйләнеше турында сөйли.

Н. Исәнбәт үзенең интервьюларында туган тел язмышына карата һәрдаим борчылуын белдерә: «Телләр күп, иң элек, билгеле, үз

телебез – үз туган телебез, аннары урамнан ук без бергә очрашып үскән рус теле, аннан безгә болай да яртылаш аңлаешлы кардәш төрки телләр. Аннары төрлечә мөһим дөнья телләре китә. Бары да мөһим. Әмма безнең өчен иң мөһиме – үз туган телебез, аны укый да, яза да белүебез.

Әмма культуралылыкның иң-иң беренче шарты билгесе – үз туган телеңне белү, диләр. Бу инде бөтен халыкларда да гомуми бер кагыйдә. Бу – кайчандыр, бөтендөнья халыклары өчен дә бер гомуми тел булу, ясалу дигән теория туу өчен һич тә каршылык итми, киресенчә, нәкъ шуңа илтү юлы. Бару юлы. Үз туган телегезне белегез, бу телдә укый да, яза да белегез. Соңыннан балаларыгыздан үзегезгә чын ихтирам күрәсегез килсә, аларга да туган телебезне өйрәтегез. Укырга да, язарга да. Үкенмәссез, туган тел безгә бик борынгыдан килгән, безне тарихлардан бирле ил һәм дәүләт тоткан халык иткән, ата-бабаларыбызның иң борынгы заманнардан бирле безгә тапшырган иң зур культура мирасыбыз, ул – тел очында авызда төрлечә генә кыбыртаган һәм вакытлы хаҗәт үтәгән нәрсә генә түгел, чөнки тел кешенең, халкыбызның эчке рухи табигате, эчке байлыгы, аның эчке рухи, иҗади, психик байлыгы, психик ясалышы, табигате, аның уйлау аппараты һәм сыйфаты. Әйтик, аның уйлау аппараты җитез, йөгерек, үткен, зиһенле, зирәк яки, әйтик, аның математикага зур сәләтле булуы хакында сөйлибез икән, бу – аның үзебезгә хас бер уй-зиһен йөгереклеге, чапкынлыгы. Тагын да конкретрак әйтсәк, бу – минемчә, туры безнең туган телебезнең аналитик системасына, аның турыдан-туры параллельлек төсендә күренгән» [Н. Исәнбәткә – 85 яшь, 1984, б. 1].

Н. Исәнбәт гомеренең ике дистә елын педагогик эшчәнлеккә багышлаган. Мөгаллимлек сәләтен энциклопедист галим әти-әнисеннән алган. Таибә абыстай Башкортстанда киң билгеле мәгърифәтчеләр нәселеннән, ә әтисе Малаяз авылында җәдит мәктәп ачкан Сиражетдин мулла шәех Зәйнулла Рәсүлинең шәкерте булган. Галим татар мәдрәсәсендә белем алуы белән горурланган, Тукай дәверендә формалашкан милли мәгариф моделен иң нәтиҗәлесе дип санаган. Н. Исәнбәт мәгърифәтчелек идеалларына тугрылыгын гомер буена саклаган. Педагог буларак, укучылары арасында мәхәббәт һәм ихтирам казанган.

Н. Исәнбәтнең педагогик эшчәнлеге экспедицияләр, фольклор материаллары туплау белән бергә үрелеп барган. Хатирәләрдән күренгәнчә, ачык һәм киң күңелле, игътибарлы, шул ук вакытта таләпчән укытучы портреты күз алдына килеп баса, ул үзенең шәкертләренә белем генә биреп калмаган, ә галим һәм педагог кешегә хас булганча, югары әхлакый-этик принциплар да тәрбияләгән, үзе дә шул принциплардан тайпылмаган: даими рәвештә рухи һәм интеллектуаль үсеш кичергән; бәхәс-дискуссияләрдә катнашканда актив тыңлаучы булган, үз фикерен әйтеп һәм башка берәүнең карашларын ихтирам итеп, үзенекен әйләнә-тирәдәгеләргә мәҗбүри такмаган; дөреслекне ачыктан-ачык әйтергә курыкмаган һәм гаделлекне яклаган; кылган гамәлләрендә эзлекле һәм җаваплы булган.

Н. Исәнбәтнең педагогик теориясендә нигез ташы – халыкчанлык идеясе. Тәрбия эшен галим милли тарихны булдыру дип кабул иткән. Н. Исәнбәт үз милләтенә тугры һәм үзенең гражданлык бурычларын үтәргә әзер торган милләт хәдимәсен тәрбиянең максаты итеп күргән. Үзенең фәнни хезмәтләрендә олпат галим әхлак тәрбиясе мәсьәләләренә зур игътибар биргән. Галимнең фәнни һәм укыту-методик мирасы хәзерге заманда да тел һәм әдәбият укытудагы проблемаларга аваздаш.

**Әдәбият**

*Абдуллин Ш.* Язучы, педагог, галим // Ватаным Татарстан. 1999. 25 дек. 5 б.

*Алдашова Е.Н.* Роль Башкирской комплексной экспедиции АН СССР (1928 – 1932) в организации первых научно-исследовательских учреждений в Башкирской АССР // Вестник Самарского государственного университета. 2011. № 85. С. 92 – 96.

*Ахмадуллин А.Г.* Исанбет (Исәнбәт) Наки (Закиров Наки Сиразетдинович) // Татарская энциклопедия: в 5 т. Т. 2. Казань: Институт татарской энциклопедии АН РТ, 2005. С. 600–601.

*Бадыйкшан Л.* Укытучым // Ватаным Татарстан. 1999. 25 декабрь. Б. 5.

Балалар дөньясы: такмак–такмазалар, җыр, мәкаль, табышмаклар, алдавыч әкиятләр һәм башкалар: (балалар фольклоры): җыентык. Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. 216 б.

Балалар календаре: 1960 / Н. Исәнбәт каләме белән язылды; худож. П.Н. Григорьев. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. 24 б.

*Батулла Р.* Тузга язмаган хәлләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997.

*Батулла Р.* Урыннары оҗмахта булсын. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.

Ватан сездән эш көтә!: [Н. Исәнбәтнең «Яшь ленинчы» редакциясендә сөйләгәннәреннән // Яшь ленинчы. 1980. 26 гыйнв. (№ 7). Б. 3.

*Госманов М.* Аксакаллар мәҗлесеннән: [Нәкый Исәнбәт тур. истәлекләр] // Казан утлары. 2010. № 11. Б. 121–135.

*Зингаров В.* Яшьлектә очрашулар // Шәһри Чаллы. 1996. 12 апрель.

*Зинуров Г. Н.* Имамы села Лаклы. (Серия: Проповедники ислама. Книга 2). Уфа: Восточная печать, 2010. 110 с.

*Зинуров Г. Н.* История села Лаклы Салаватского района Республики Башкортостан. Уфа: РИО БашГУ, 2004. 436 с.

*Зинуров Г. Н.* Неизвестные страницы в биографии Наки Исанбета // Tatarica. 2021. № 1 (16). С. 127–141.

*Зинуров Г. Н.* Тропой судьбы: Документальная повесть. Уфа, 2015. 334 с.

Idukəj həm Moradum // Коммуна. 1940. №78 (1477). 28 апреля.

Idukəj həm Moradum // Коммуна. 1940. № 79 (1478). 29 апреля.

*Исәнбәт Н.* «Бәби чак» // Мирас. 1999. № 1. Б. 91–101.

*Исәнбәт Н.* «Бәби чак» // Мирас. 2000. № 1. Б. 95–104.

*Исәнбәт Н.* Берәзә песие Мыраубай батыр маҗаралары һәм башкалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 208 с.

*Исәнбәт Н.* Биографиям // Нәкый Исәнбәтнең шәхси архивы. Кульязма. Машинкада басылган. Датасы күрсәтелмәгән. 4 б.

*Исәнбәт Н.* Исламның дөньяга карашлары. Уфа: Башкнига, 1926. 190 б.

*Исәнбәт Н.* Минем язучы булуым һәм халык иҗатын өйрәнүем // Нәкый Исәнбәтнең шәхси архивы. Кульязма. Машинкада басылган. 1960. 5 б.

*Исәнбәт Н.* Ни өчен ни булган яки Утыз ялган: [әкиятләр] / К. Гобәйдуллин рәс. Казан: Таткнигоиздат, 1956. 104 б.

*Исәнбәт Н.* Оры аккан // Нәкый Исәнбәтнең шәхси архивы. Кулъязма. Машинкада басылган. 1958. Б. 91.

*Коган С.* Башкортстанда табыла торган дару үләннәрен җыю өчен кыскача кулланма / Исәнбәтов тәрҗ. Стәрлетамак, 1922. 14 б.

Личная карточка члена СП СССР Исанбета Наки Сиразиевич. 1952. // Краеведческий музей в д. Татарский Малаяз. Фонд Наки Исанбета. 5 л.

Н. Исәнбәткә – 85 яшь. // Нәкый Исәнбәтнең шәхси архивы. Интервью. Кулъязма. Машинкада басылган. 9 б.

Нәниләр шатлана: [балалар уеннары, санамышлар, такмак-такмазалар]. Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. 169 б.

Отканга мәкаль, тапкырга табышмак: балалар фольклоры / Н. Исәнбәт Казан: Татар. кит. нәшр., 1973. 125 б.

*Рахмани Р., Миңнуллина Ф.* Нәкый Исәнбәт // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 5 т. Казан: Татар. кит. нәшр, 2017 Б. 374–392.

*Репина Л. П.* Историческая биография и интеллектуальная история // Ейдос: альманах теорії та історії історичної науки. Київ, 2009. Вып. 4. С. 452–454.

Син сазыңны уйнадың... (Г. Исәнбәт истәлекләре) // Азат хатын. 2000. № 1. Б. 14–15.

Син сазыңны уйнадың... (Г. Исәнбәт истәлекләре) // Азат хатын. 1999. № 12. Б. 10–11.

Табышмаклар: [1468 табышмак һәм аларның җаваплары] / җыючысы һәм төзүчесе Н. Исәнбәт. Казан: Татгосиздат, 1941. 196 б.

Татар халкының балалар фольклоры / җыючысы һәм төзүчесе Н. Исәнбәт. – Казан: Татгосиздат, 1941. 188 б.

Татар халык табышмаклары: кереш мәкалә һәм аңлатмалар белән / җыючысы һәм төзүчесе Н. Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. 568 б.

Трудовой список Исанбета Наки Сиразеевича. // Архив Юлдуз Исанбет. 10 с.

*Урманче Б.* Исәнбәтнең урыны // Казан утлары. 1969. № 12. Б. 131–133.

*Хабутдинова М.М.* Вклад Наки Исанбета в изучение истории образованности татар // Просветительское движение у тюркских народов и творчество Абая: материалы Международной научной конференции, посвященной 175-летию со дня рождения казахского поэта, просветителя, общественного деятеля Абая Кунанбаева. Казань, 14 декабря 2020 г. / сост.: Ф.Г. Файзуллина, Г.А. Хуснутдинова. Казань: ИЯЛИ, 2020. С. 260–263.

*Ханзафаров Н. Г.* Нәкый Исәнбәт драматургиясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 190 с.

*Хәбетдинова М.М.* Нәкый Исәнбәт истәлекләрендә ХХ гасыр мәдрәсә шәкертләренең көндәлек тормышы // Tatarica. 2020. № 1. С. 78–102.

*Шамуков Г.* Нәкый Исәнбәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. 76 б.

Яңа мәктәп: татарча әлифба / Һ. Сәгъди, Н. Исәнбәт. Уфа: Башкнига, 1927. 72 б.

Яшь буын: бөтен һүззәр күзәтү методы белән төзелгән әлифба китабы / Һ. Сәгъди, Н. Исәнбәт. М.: Центр. изд. народов СССР, 1926. 64 б.

***Хәбетдинова Миләүшә Мөхәммәтҗан кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты доценты*

УДК 796.01

***А.Г. Ибәтуллин***

# ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН МИЛЛИ МӘГАРИФЕНДӘ РУХИЯТ ҺӘМ ТРАДИЦИЯЛӘР

Анализ практического опыта школ показывает, что гуманизация современного образовательного пространства, возврат к общечеловеческим ценностям обуславливает необходимость поиска новых решений по проблемам нравственного совершенствования молодого поколения. Учитывая тот факт, что имеется четкое представление о единстве физического и духовного развития в сфере физкультурной деятельности, в статье отмечается, что на сегодняшний день в большей степени превалирует ориентация на физическое развитие учащихся. Автор выдвигает мысль о том, что приобщение школьников к универсальным духовно-нравственным ценностям в школах Татарстана должно осуществляться через призму ценностей национальной культуры, через внедрение татарских народных традиций в учебно-воспитательный процесс.

**Ключевые слова**: педагогическая система, духовно-нравственные ценности, занятия физической культуры, внедрение татарских народных традиций.

Analysis of the practical experience of schools shows that the humanization of the modern educational space, the return to universal human values necessitates the search for new solutions to the problems of moral improvement of the young generation. Taking into account the fact that there is a clear idea of the unity of physical and spiritual development in the field of physical culture, the article notes that today the orientation towards the physical development of students is more prevalent. The author puts forward the idea that the introduction of schoolchildren to universal spiritual and moral values in the schools of Tatarstan should be carried out through the prism of the values of national culture, through the introduction of Tatar folk traditions into the educational process.

**Keywords:** pedagogical system, spiritual and moral values, physical education, introduction of Tatar folk traditions.

Бүген шәхес формалаштыруда укучыларның рухи-әхлакый кыйммәтләрен халыкның гореф-гадәтләре аша тәрбияләү аеруча актуаль. Хәзерге заман мәктәпләрендә милли кыйммәтләрне яңадан торгызуга зур ихтыяҗ тууга бәйле рәвештә әхлакый тәрбиянең эчтәлеге сизелерлек үзгәрешләр кичерә. Дәресләрдә (мәсәлән, физкультурада) халык мәдәнияте элементларын кулланганда, алар укучыларның шәхес турындагы фәлсәфи-теоретик күзаллаулары, аларның шәхес буларак формалашу шартлары белән бәйле булачак. Бу укучыларга өйрәнелә торган күренешләрнең һәм процессларның асылын тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирәчәк. Шул ук вакытта укучыларга белем бирү аларда әхлакый сыйфатларны максатка яраклы рәвештә барлыкка китерү өчен билгеләнгән педагогик система кысаларында гамәлгә ашырылачак [Проблема формирования нравственных ценностей

личности в современном социуме]. Татарстан мәктәпләрендә укучыларны рухи тәрбия белән таныштыру татар халык традицияләре кыйммәтләре призмасы, аларның милләтара һәм мәдәниятара баглынышларга сәләтләрен үстерү аша тормышка ашырылырга тиеш. Яшь буында әхлак төшенчәләре, бәяләр һәм фикерләр нигезендә әхлакый сыйфатлар формалаша, алар, ахыр чиктә, кешенең үз-үзен тотышын һәм гамәлләрен билгели.

Укучыларның тиешле милли тәрбия алуыннан башка уку-укыту процессы нәтиҗәле була алмый. Менә ни өчен уку-укыту процессы закончалыклы рәвештә белем бирү һәм тәрбия функцияләренең бердәмлеген күздә тота. Шунысын ассызыклап әйтергә кирәк: бу очракта аларның параллель, бер-берсенә бәйсез рәвештә гамәлгә ашырылуы турында түгел, ә нәкъ менә бердәмлеге турында сүз бара. Гомуми белем бирү учреждениеләре гражданин, үз Ватанының һәм туган халкының патриотларын тәрбияләргә, аларны югары технологияле, конкурентлы тормышка әзерләргә тиеш.

Безнең җәмгыятьтә, бигрәк тә яшьләр арасында, бүгенге көндә әхлак тирән рухи кризис кичерә дип әйтергә мөмкин. Моны ассызыклау мөһим, чөнки тоталитаризмнан демократиягә күчү шартларында кайбер кешеләр илебездә социаль кыйммәтләрне яңадан бәяләүне «барысы да рөхсәт ителә» дип аңлый, бу исә түрәләрнең рухи яктан бөлгенлеккә төшүенә һәм коррупциягә ныграк бирелүенә, җинаятьчелекнең үсүенә һәм башка тискәре күренешләргә китерә. Хәер, бу кризисның илдәге бөтен социаль вазгыятькә турыдан-туры йогынты ясавы барыбызга да билгеле. Без халкыбыз тормышында барган рухи-әхлакый үзгәрешләр тирәнлегенә үтеп кермәсәк, бүгенге Россиядәге социаль динамиканы вакытында аңлый алмаячакбыз.

Мәктәпләрдә һәм башка уку йортларында укучы яшьләр арасында укуда, спортта һ.б. башкаларга караганда яхшырак булу омтылышы көчәя. «Кем җиңми – шул оттыра» девизы хуплана. Видеоуеннарда да шундый максат куела. Галимнәр фикеренчә, алар балаларда каты күңеллелек, социаль бәла-казаларга һәм кешеләрнең фаҗигаларына битарафлык тәрбияли. Монда шунысын да әйтергә кирәк: россиялеләрнең холкында бу сыйфатлар шулкадәр киң таралган ки, бүген без, кызганыч, андый кешеләр сирәк очрый дип әйтә алмыйбыз инде.

Бүген Россиянең күп кенә төбәкләрендә фәнни җәмәгатьчелекне һәм зыялыларны җәмгыятьтәге рухи кыйммәтләрнең торышы тирән борчуга сала. Әхлакый кризис һәм хәзерге яшьләр арасындагы рәхимсезлек, кансызлык чагылышлары күбесенчә өлкән буыннар абруеның йогынтысын бәяләп бетермәүдән дә килә. Мәсәлән, зур тормыш тәҗрибәсенә, зирәк акылга ия өлкән буын вәкилләренә ихтирам Татарстан Республикасы халыклары милли-мәдәни менталитетының характерлы үзенчәлеген тәшкил итә. Бу – үткәндә, авыр тарихи шартларда халыкка үзенең милли үзенчәлекләрен, рухи-әхлакый кыйммәтләрен һәм яшьләргә традицион тәрбия бирү системасын саклап

калырга ярдәм итә. Әхлаклылык – рухи тормышның үзәге, рациональ белем хакыйкатькә һәм туры юлга илтә, дип өздереп әйтә алабыз.

Хәзерге этапта рухи менталитетны, гасырлар дәвамында барлыкка килгән иң югары рухи кыйммәтләрне чагылдыра алырдай әһәмиятле тәрбия программасы кирәк.

Шуның белән бергә, Россия Мәгариф министрлыгы мәгълүматлары буенча, инновацион эшчәнлек җәелдерелгән гомуми белем бирү мәктәпләренең 35% ы гына тәрбия өлкәсендәге эчтәлек, чара, форма һәм алымнарга яңача якын килү юлларын эзли.

Татар халкы тарихи һәм мәдәни мирасының әхлакый кыйммәтләр формалаштырудагы әһәмиятен дә билгеләп үтү мөһим. Татар халкы тәрбияви карашларының әһәмиятле чыганагы – халыкның тормышын һәм көнкүрешен, кайгы-хәсрәтен һәм бәхетен, патриотизмын, традиция һәм гореф-гадәтләрен чагылдырган халык иҗаты.

Әйткәнебезчә, милли мәгарифнең асылы аны дөнья мәдәнияте җәүһәрләре, гасырлардан килгән халык традицияләре белән тулыландыру-баетуда күренә. Мәгариф бу очракта төрле буыннарны һәм халыкларны тоташтыручы үзенчәлекле күпер ролен үти.

Укучыларны тәрбияләү процессында милли мәдәниятнең нигезен тәшкил иткән рухи-әхлакый сыйфатларны формалаштыруга булган ихтыяҗларны канәгатьләндерә торган түбәндәге нигезләмәләрне атарга мөмкин:

1. Россия мәгариф системасының киләчәге милли мәдәният нормалары һәм төбәк халык традицияләре, гомумкешелек рухи кыйммәтләренә каршы килми торган милли традицияләргә туры китереп төзелгән тәрбия системасы белән тыгыз бәйләнгән.

2. Тәрбия системасына сайлап алынган юнәлешләр тормышка сәләтле булсын өчен, аларның үсеп килүче буынның актуаль тормыш кыйммәтләренә туры килүе һәм тәрбия киңлегендә заманча дөньякүләм тенденцияләргә җавап бирүе зарур.

3. Укыту-тәрбия процессының эчтәлеге мәдәниятләр диалогы һәм толерантлык формасында гамәлгә ашырылырга тиеш.

Физик тәрбия процессында үзенчәлекле бурычлар белән берлектә шәхес формалаштыру, җәмгыять әгъзалары тәрбияләү, ягъни гомумпедагогик мәсьәләләр хәл ителә. Башкача әйткәндә, физик тәрбиянең иҗтимагый файдалы нәтиҗәсе дәресләрдә әхлакый тәрбиянең ни дәрәҗәдә тыгыз үрелеп баруы белән билгеләнә.

Физик культура дәресләрендә рухи-әхлакый тәртипнең гомуми нормалары тагын да үзгәрәк нормалар белән тулыландырыла (мәсәлән, ярыш кагыйдәләрен үтәү, көндәшеңне хөрмәт итү һ.б.). «Физик тәрбиянең милли чараларын кулланганда, гомуми тәрбиянең нәтиҗәсе бик югары» булуы расланган [Копылов, с. 24–36].

Шулай итеп, уку-укыту процессында укучыларның рухи-әхлакый кыйммәтләрен формалаштыруның әһәмияте бик зур. Рухият һәм традиционлыктан башка физик культура белән шөгыльләнү бары тик физик көчне арттыруга гына кайтып кала. Элек барлыкка килеп, милли

формада чагылыш тапкан кайбер традицияләр әле үзләренең прогрессив мөмкинлекләрен югалтмадылар һәм хәзерге мәктәптә уңышлы кулланыла алалар.

Татарстан Республикасы халкын сәламәтләндерүнең яңа технологияләрен куллану шартларында яшь буынны тәрбияләүдә электән килгән халык тәҗрибәсенә кире кайту күзәтелә. Уеннар халыкның үсеш тарихы, көнкүреше, гореф-гадәтләре, традицияләре белән тыгыз бәйләнгән. Алар милли мәдәниятнең аерылгысыз өлешен тәшкил итә һәм шәхескә физик, әхлак, хезмәт тәрбиясе бирү чарасы булып тора.

Татарстан Республикасында 170 тән артык милләт вәкиле яши. Монда да этносара мөнәсәбәтләр өлкәсендә иҗтимагый иминлекне һәм тотрыклылыкны саклау, шәхеснең толерантлыгын формалаштыру мәсьәләләре беренче планда тора. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, татар халкының күп кенә традицияләрен, йолаларын һәм бәйрәмнәрен үсеп килүче буынны тәрбияләүдә файдаланмау милли мәдәният үсешенә һәм халыкның рухи тормышына, шәхеснең формалашуына һәм үсешенә зур зыян сала, буыннар арасындагы бәйләнешнең җимерелүенә китерә.

Татарстанның күпмилләтле республика булуын исәпкә алып, без аерым халыкның традиция һәм уеннарына гына таянмыйбыз, ә республикада яшәүче барлык халыкларның традицияләрен колачлаган гомуми вариантны тәкъдим итәргә тырышабыз.

Укучыларда гуманлылык формалаштыру – актив педагогика ул, дигән билгеләмәгә таянып, без, тәрбия процессына татар халык традицияләре чараларын да кертеп, укучының тормышта үз-үзен табуына ирешергә омтылабыз, симпатия хисе уятып, аның күңеленә игелек орлыгы салабыз, үзебезнең уку-укыту бурычларын билгеле бер рухи кичереш-кичешләр аша хәл итәбез. Уку-укыту процессында татар халык традицияләрен (гореф-гадәт, бәйрәм, уеннарын) куллануны бердәм коллективта рухи һәм физик үсешкә ирешү юлы дип саныйбыз.

Формалашып килүче шәхеснең төп нигезләре салынганда, балалар һәм яшүсмерләрне тәрбияләүдә халык педагогикасы потенциалын эшкә җигү – бигрәк тә әһәмиятле һәм зарури эш. Чөнки, уйлавыбызча, Татарстан Республикасында милли мәдәниятне торгызу һәм аның рухи мирасын актуальләштерү проблемалары белән актив кызыксыну күзәтелә [Ибатуллин, с. 17]. Халыкның тәрбия чаралары этнография белән дә тыгыз бәйләнгән. Шуның белән бәйле рәвештә, традицион физик тәрбия – халык мәдәниятенең бер төре булып тора. Халык уеннары, милли спорт төрләре, ярышлар аның чараларын тәшкил итә.

Халык уеннарын [Мухаметзянов, Мухаметзянова, с. 152–154], гореф-гадәтләрне һәм бәйрәмнәрне файдалану бүгенге көндә дә балаларның тормыш позициясен формалаштыруга, актив эшчәнлек алып бару процессында иң яхшы кешелек сыйфатларын үстерүгә, шулай ук күмәк уеннарда катнашу процессында барлыкка килгән шәхси мөнәсәбәтләрне гуманлаштыру аша гражданлык хисе

формалаштыру, әхлаклы гамәлләргә һәм эшләргә ихтыяҗ тәрбияләүгә юнәлдерелгән.

Сәламәт яшәү рәвешенең өстенлекләрен популярлаштыру, укучыларның физик культура һәм спорт өлкәсендә кызыксынуларын киңәйтү дә халык традицияләре системасы аша хәл ителә торган иң мөһим бурычларга керә. Халык педагогикасын мәктәптә рухи-әхлакый тәрбия системасының үзәгенә алу яшьләргә тормыш мәгънәсен һәм идеалларын табарга ярдәм итәр, киләчәккә юнәлеш бирү системасының нигезе булыр иде.

Физик тәрбиянең эчтәлеге һәм ысуллары һәрвакыт тормышкөнкүреш, хезмәт шартлары белән бәйле һәм кешедә хезмәт күнекмәләре формалаштыру һәм үстерүгә буйсындырылган. Моннан чыгып, шундый нәтиҗә ясарга мөмкин: халык тәрбиясе традицияләре потенциалын җентекләп, детальләп билгеләгәндә һәм педагогик процесста кулланганда гына мәгарифне үстерергә мөмкин. Анда халык мәдәниятенең аерым катламын тәшкил иткән физик культура әһәмиятле урын алып тора.

**Әдәбият**

*Ибатуллин А.Г.* Формирование духовно-нравственных ценностей учащихся сельской школы (на занятиях физической культурой): автореф. дис... канд. пед. наук. Казань, 2005. 26 с.

*Копылов Ю.А.* Национально-региональный компонент учебного предмета // Физическая культура в школе. 2003. № 3. С. 24–36.

*Мухаметзянов А.Х., Мухаметзянова Л.Х.* Организация двигательной активности учащихся с использованием элементов детского игрового фольклора // Современные тенденции в науке и образовании: материалы Международной научно-практической конференции. М.: АР-КОНСАЛТ. С. 97–101.

Проблема формирования нравственных ценностей личности в современном социуме / URL: https://studwood.ru/1066804/pedagogika/problema_formirovaniya_nravstvennyh_tsennostey_lichnosti_sovremennom_sotsiume (дата обращения: 21.06.2021).

***Ибәтуллин Альберт Габделхәлим улы,***
*педагогика фәннәре кандидаты,*
*Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты доценты*

УДК 78.087.6

*Г.Ф. Юнысова*

# ТАТАР ВОКАЛЬ МУЗЫКАСЫНДА ШИГЫРЬ ТЕКСТЫН ТӘРҖЕМӘ ИТҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

В статье рассматривается вопрос о переводах вербального текста в татарской вокальной музыке. На примере песни «По ягоды» композитора Мансура Музафарова проанализированы проблемы переводов в связи с их соответствием оригиналу в плане названия произведений, содержания, количества куплетов. Внимание обращено на основной вид перевода в вокальной музыке – эквиритмический. Дана характеристика деятельности некоторых переводчиков в связи с результатами их работы. Намечены пути исправления обнаруженных недостатков в переводах песен и романсов композиторов Татарстана.

**Ключевые слова:** татарская вокальная музыка, композитор Музафаров, эквиритмический перевод, аллитерация, репертуар певцов, переводчики Бугаевский и Хисамов.

The article discusses the issue of translations of the verbal text in Tatar vocal music. On the example of the song «For Berries» by composer Mansur Muzafarov, the problems of translations are analyzed in connection with their correspondence to the original in terms of the title of works, content, and the number of verses. Attention is drawn to the main type of translation in vocal music - equirhythmic. The characteristics of the activities of some translators in connection with the results of their work are given. The ways of correcting the discovered shortcomings in the translations of songs and romances by the composers of Tatarstan are outlined.

**Keywords:** Tatar vocal music, composer Muzafarov, equirhythmic translation, alliteration, singers' repertoire, translators Bugaevsky and Khisamov.

Бүген дөньяда чит телләр өйрәнү киң таралган. Әмма ул берничә тел белән генә чикләнә һәм күбрәк инглиз телен өйрәнүгә кайтып кала. Шуңа күрә тәрҗемә әдәбият бүгенге көнгәчә төрле халыкларның әсәрләре белән танышу өчен төп чыганак булып кала. Бу төрле һәм күпсанлы милләтләр яшәгән Россиядә бигрәк тә актуаль. Илебездә төп дәүләт теле – рус теле (иң беренче чиратта, милләтара аралашу теле), ә безнең республикада татар теле дә дәүләт теле статусына ия булу сәбәпле, Татарстанда чәчмә һәм шигырь белән язылган әсәрләр тәрҗемәләренең зур күпчелеге шуларга карый. Алар шигырь текстлары һәм ноталар басмаларына кертелгән. Рус теленнән татар теленә тәрҗемәләр башка милләт шагыйрьләренең Татарстанда киң таралган әсәрләрендә, татар композиторлары иҗатында очрый. Беренче очракта әсәрләр җыр һәм театр-сәхнә жанрларында тәкъдим ителә. Җырлар арасында Ленинга, Коммунистлар партиясенә, Ватанга (СССРга) багышланган, шулай ук революцион һәм балалар өчен әсәрләр күп. Аларны «Революцион җырлар», «Партия һәм Ленин турында җырлар» кебек махсус әчтәлекле, яисә «Халык җырлый» кебек

аерым төркемнәргә тупланган җыентыкларда бастырып чыгарганнар. Иҗтимагый-сәяси һәм патриотик яңгырашлы мондый җырларда тәрҗемәгә аеруча зур әһәмият бирелгән, һәм бу рецензияләрдә дә чагылыш тапкан. Аларның берсендә, мәсәлән, В. Лебедев-Кумач («Москва майская»), Н. Голодный («Матрос Железняк») шигырьләренең Ә. Ерикәй тарафыннан эшләнгән татарчага тәрҗемәләре тәнкыйть утына тотыла. М. Садриның (М. Исаковский, «Ике лачын»), Ә. Исхакның (А. Сурков, «Сталин турында җыр») һәм шул ук Ә. Ерикәйнең (М. Светлов, «Каховка») тәрҗемәләре хуплана. Мондый җырларны совет чорында бастырганнар. Дөнья классикасы сәхнә әсәрләре либреттоларының (Моцарт, «Фигароның туе»; Бизе, «Кармен» һ.б.) татарчага тәрҗемәләренә ихтыяҗ әллә ни озак дәвам итми. Алар 1939 елда Казанда ачылган опера һәм балет театры репертуарын формалаштырганда гына кирәк була. Аларның тәрҗемәләре өстендә XX гасырның 30 нчы елларында Мәскәү консерваториясе каршында оештырылган Татар опера студиясенең М. Җәлил җитәкчелегендәге әдәби секторына йөрүчеләр эшли [Исанбет, 1977, с. 18]. Әмма Казанда татар теленә тәрҗемә ителгән дөнья классикасы әсәрләре кыска гомерле булып чыга: опера һәм балет театры сәхнәсе аларны «үз итеп бетерми».

Татарстанның үз композиторлары иҗатында рус теленнән татарчага тәрҗемә ителгән әсәрләр күп түгел. Аларга, гадәттә, танылган шагыйрьләрнең юбилейлары уңаеннан мөрәҗәгать ителә. Мәсәлән, А.С. Пушкинның вафатына 100 ел тулу уңаеннан Мәскәү консерваториясендә шагыйрь сүзләренә язылган вокаль әсәрләр конкурсы үткәрелә. Аларга студияче композиторлар М. Мозаффаров һәм Ф. Яруллин («Чегәннәр», «Җырлама син, иркәм», Ә. Ерикәй тәрҗемәсе), Н. Жиһанов («Козгын козгынга оча», «Мәхбүс», Ә. Фәйзи тәрҗемәсе) мөрәҗәгать итә [Тазиева, с. 26]. Әмма кайчагында музыканы турыдан-туры шигырьнең оригиналы телендә дә иҗат итәләр. Әйтик, 1941/1942 еллар өчен хисап докладында Татарстан Композиторлар берлеге рәисе Н. Җиһанов нәкъ менә сугыш елларында татар композиторларының беренче тапкыр рус телендәге текстларга җырлар яза башлавын ассызыклый, чөнки вазгыять шуны таләп итә. Шундый җырлар арасында Н. Җиһановның М. Мишнев сүзләренә язылган «Пощады врагам не дадим» (икенче исеме: «Смерть фашистам»), «Фашистов раздавим» (А. Бендецкий сүзләре) әсәрләре дә бар. Татар вокаль музыкасындагы әлеге күренешләрнең икесе дә – русча оригинал яки рус теленә тәрҗемә ителгән шигырьләргә җырлар язу – татар композиторларының иҗатында киләчәктә дә дәвам иттереләчәк. М. Мозаффаров, А. Пушкин һәм М. Лермонтов поэзиясенә мөрәҗәгать итеп, XX гасырның 40 нчы елларында яңа бормалы көйләр эзли. Татарстанның рус телле шагыйрьләре Б. Старчиков («Ожидание» – «Зарыгу») һәм М. Таҗетдинов («Живут на свете сказки» – «Җир йөзендә әкият бар») һ. б. сүзләренә Н. Җиһановның менә дигән камера вокаль музыкасы үрнәкләре кебек үк, Шекспирның рухландыргыч

ике сонеты да (С. Маршак тәрҗемәсе) Р. Яхин язган көйләр белән яңгырады.

Бу мәкаләдә Татарстан композиторларының музыкаль әсәрләрендә әдәби текстны татар теленнән рус теленә тәрҗемә итүнең кайбер үзенчәлекләре игътибар үзәгенә алына. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, әлеге мәсьәлә тарихында (якынча XX гасырның 50 нче елларыннан алып 80 нче елларына кадәр) мондый хезмәтнең сан һәм сыйфатына игътибар җитәрлек дәрәҗәдә бирелгән чор да булды. Бүген вазгыять бөтенләй башка. Нәтиҗәдә, татар композиторларының вокаль әсәрләре еш кына өлешчә тәрҗемә белән бастырыла яки тәрҗемә бөтенләй юк. Рус телендәге текстта куплетлар тулы булмаганда, аларның саны, гадәттә, төп чыганактагыдан бергә ким булып чыга. Мондый мисалларны «Кайда да йөрәктә» дип исемләнгән җырлар җыентыгында да [Кайда да йөрәктә, б. 16; 54] табып була: М. Җәлил сүзләренә З. Хәбибуллинның «Сагыну»ы (өч куплеттан икесенең генә тәрҗемәсе бирелгән), Ә. Ерикәй сүзләренә С. Сәйдәшевнең «Бибисара» җыры (2+1). М. Мозаффаровның «Йөрәк җыры» җыентыгы да, С. Сәйдәшевнең академик басма булырлык өч томлы сайланма әсәрләре кебек үк, рус телле текст белән тәэмин ителмәгән. Татар композиторларының вокаль музыкасы басмаларында рус телле текст булмауның бер сәбәбе – шигырь төзелешенә нисбәтле тәрҗемә проблемалары, кайбер әдәби алымнар (мәсәлән, аллитерация) белән бәйле. Юллар һәм иҗекләр саны тигез булган әсәрләрне тәрҗемә итү җиңелрәк. Татарча текстларда бу, гадәттә, 7–8 иҗекле дүртьюллыклар. Әмма мондый бирелешнең көйләргә тәэсире бар. Ул бертөрлегә әйләнә һәм аны фаразлап була. Төрлелек, бормалы көйләрнең сыгылмалылыгы күп очракта шигырь төзелешенең гадәти булмавыннан килә. Шигырь текстының мондый композициясе М. Мозаффаровның вокаль музыкасында аеруча ачык чагыла, аның әсәрләрен юкка гына җыр-романслар дип атамыйлар. Мәсәлән, М. Мозаффаровның «Йөрәк җыры» җыентыгыннан рус теленә тәрҗемәләре булмаган ике җырдан өзекләр (башлам өлеше һәм кушымта) китерик: [Мозаффаров, б. 57, 70]: «Кайда йөрәктә» (С. Хәким сүзләре) һәм «Саумы, кояш!», (Р. Әхмәтҗанов сүзләре). Аларда шигырь юлларында иҗекләр саны төрле:

**Кайда да йөрәктә**

Анда ул,
Анда ул таңнарның
Нәкъ Кырлай өстендә атканы...

**Саумы, кояш!**

– Саумы, кояш!
Саумы, иртә!
– Исәнме! – диләр...
Иркәли, иркәли җанны
Ягымлы көйләр.

Аллитерация алымын (шигырь юлында тартык авазның берничә мәртәбә кабатлануы) куллануның ачык мисалы – Н. Җиһановның С. Хәким сүзләренә язылган «Өзелгәнсең сиреньнән» җыры. Җырның

исемендә һәм куплетларда язгы сирень чәчәге атамасындагы [с] тартыгы белән берничә тапкыр очрашабыз:

Яши миндә
синең тавыш,
синең сагыш,
синең сүз.

Шул ук хәрефне (авазны) кабатлау юлы белән тәрҗемә кылу шактый авыр. Башка бер тартык авазны, мәсәлән, [т] авазы белән эш итү җиңелрәк: «оторвалась ты от ветки сирени». С. Хәким шигырендәге аллитерацияне, юлларда сүзләрнең аваз тезмәсен тәрҗемәдә бирү бик авыр, бу образ аерылышу һәм саубуллашу сагышы белән өретелгән. Сынган сирень ботагы «чәчәк аткан», сөю тулы дөнья тормышыннан китү (аерылу) символы буларак кабул ителә, аның артыннан сулу һәм үлем килә. Рус теленә тәрҗемәдә әлеге шигърилек һәм шигырьнең эчке мәгънәсе сакланмаган (В. Мостафин тәрҗемәсе) [Жиганов, с. 5].

Татар композиторларының вокаль әсәрләрен тәрҗемә итү зарурлыгы бүгенге уку-укыту процессында аеруча мөһим, чөнки аларның музыкасы белән танышу дәресләрендә еш кына республикага Россиянең башка (кайчагында бик ерак) төбәкләреннән һәм ерак чит илләрдән килгән төрле милләт вәкилләре катнаша. Татар композиторларының рус телендәге вокаль һәм опера музыкасы эчтәлегенә нәкъ менә шуларның тискәре мөнәсәбәте нәтиҗәсендә мәкалә авторы әлеге күренешкә игътибар итәргә мәҗбүр булды да. Әмма кайчандыр югары сыйфатлы тәрҗемәсе булган очракта гына, республикада да, аннан читтә дә Татарстан композиторларының романс һәм җырларын башка милләт җырчыларының репертуарына кертә торган булалар. Казандагы башкаручылар бу эшкә татарча радиотапшырулар тәкъдиме буенча тартыла. Мәсәлән, XX гасырда 60 нчы елларның икенче яртысында [Фәйзуллин, б. 4] кичке тапшыруларда татар композиторларының рус телле артистлар башкаруындагы җырлары тапшырыла башлый. Анда М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрының күренекле җырчылары катнаша. Бу театр күп очракта Россиянең башка театрлары белән дә бәйләнештә торып эш итә. Алар арасында О. Логинова, А. Талмазов, М. Пантюшин («Кара урман», С. Сәйдәшев), Н. Зайцева («Зоя турында баллада», Җ. Фәйзи; «Сагыну», З. Хәбибуллин) һәм В. Зорин («Табын җыры», Р. Яхин), шулай ук татар дәүләт филармониясеннән – А. Огородников («Таң йолдызы» исемле серенадасы, Ф. Әхмәтов) һ.б. бар. Шул ук вакытта татар композиторларының, барыннан да элек С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, Н. Җиһанов, Ә. Фәттах һәм Р. Яхинның вокаль музыкасы (М. Җәлил һәм Ә. Ерикәй сүзләренә) рус телендә Г. Отс, А. Ведерников, А. Огнивцев, В. Трошин, В. Канделаки, Л. Исаева, Н. Поставничева, Н. Рубан, В. Борисенко кебек танылган җырчылар башкаруында яңгырый. Кызганычка каршы, бу фактлар, шулай ук республикабыздан читтә яшәгән татар җырларын башкаручыларның күбесе

турындагы мәгълүмат әлегә кадәр музыка белгечләренең хезмәтләрендә яктыртылмаган.

Татар композиторларының вокаль әсәрләрен карап-тикшереп чыкканнан соң, шул ачыкланды: ноталы басмаларда шигырьләрнең тәрҗемә сыйфаты күп очракта канәгатьләнерлек түгел. Тәрҗемәнең төрле төрләре бар. Вокаль музыка әсәрләрендә шуларның иң катлаулысы – эквиритмик тәрҗемә кулланыла. Бу терминның нигезендә «экви» сүзе ята, ягъни «тигез» (ритмлы). Аның тасвирламасында төп басым **техник элементларга** – иҗек һәм сүз басымнарына, сүз аралары санына, шигырь үлчәменә, клаузулаларны (рифмовкалар) саклауга ясалган. Чыннан да, автор тарафыннан билгеләнгән авазлар санын һәм ритмик рәсемне саклап җырлау өчен, тәрҗемә ителгән шигырьне көе белән яраштыру мөһим. Гәрчә филологлар билгеләп үткәнчә, эквиритмиклык тулы яки өлешчә булырга мөмкин, әмма чынбарлыкта беренче төргә ирешеп булмый диярлек. Оригинал телен белмәгән белгечкә эквиритмик тәрҗемә ясарга кушыла һәм аңа ритмик ягы үрнәк нигезендә эшләнгән мәгънәсез сүзләр тоттырыла. Шуңа күрә, әсәрләрнең эчтәлеге еш кына канәгатьләнерлек булмый, бу исә татар композиторларының вокаль музыкасында шактый сизелә, гәрчә чыгарылмалар булса да. Аерым тәрҗемәчеләр оригинал эчтәлеген дөрес чагылдырырга гына түгел, ә «рус тыңлаучысына... шигырь юлларының шигъри сурәтлелеген һәм аны оригиналда тыңлаучының йөрәгендә җыр яки ария тудырган хисне» дә тапшырырга да омтылганнар [Рустем Яхин, 1996, с. 125]. Тәрҗемәләрдә төп проблемалар текст төзелеше, әсәр эчтәлеге һәм андагы образлар **поэтикасы** белән бәйле рәвештә барлыкка килә. Санап үтелгән сыйфатларны тәрҗемәдә хатага китерә торган объектив сәбәпләргә кертергә мөмкин. Әлеге проблемаларны тикшерүдә төп әсәр итеп М. Мозаффаровның М. Җәлил сүзләренә язылган (русчага В. Бугаевский тәрҗемәсе) «Җиләк җыйганда» җыры сайланды, ул беренче тапкыр Мәскәүдә «Искусство» нәшриятында 1938 елда басылып чыккан. Шулай ук башка әсәрләрдән дә мисаллар китерелә.

М. Мозаффаровның җырында оригиналга тәңгәл килмәгән тәрҗемә, кайбер башка әсәрләрдәге[1] кебек үк, иң элек тотрыклы, үрнәк була алмаган шигырь тексты аркасында туган. 1937 елда М. Җәлил М. Мозаффаровның «Җиләк җыйганда» җырының нигезенә яткан «Җир җиләге» шигыре өстендә эшен әле төгәлләмәгән булса кирәк, чөнки бу әсәрнең бер-берсеннән аерылып торган ике варианты бар. Алар икесе дә икешәр куплеттан тора, ә композиторның җыры әлеге вариантларның төрле өлешләрен сайлау нәтиҗәсендә өч куплеттан торган (шигырьнең беренче оригиналының башына тулысынча икенчесенеке кушылып киткән). Тәрҗемәче дә (В. Бугаевский) җыр эчендә өлешләрнең урыннарын алыштырган.

[1] Мәсәлән, Т. Гыйззәтнең «Бишбүләк» пьесасыннан «Өмә җыры»ның тексты, сүз һәм көйнең аһәңлелегенә ирешергә омтылган С. Сәйдәшев кушуы буенча, спектакльне сәхнәгә куйганда үзгәртелә.

Аның тәрҗемәсе оригинал әсәрнең шигъри юллары белән туры килми. Чынлыкта ул соңгы өлештәге сүзләрне ике тапкыр төрлечә тәрҗемәләп, икенче һәм өченче куплетлар сыйфатында биргән. Шулай ук җыр иҗат итүчеләр (шагыйрь һәм композитор) кушымтага төрлечә якын килгәннәр. М. Җәлил әсәреннән аермалы буларак, М. Мозаффаровта шигъри юллар (мисалда калын шрифт белән аерып бирелгән) һәркайда кабатлана (гадәттә кушымталарда). Кушымта сүзе-сүзгә шигырьнең беренче вариантының башлам куплетыннан алынган. Бу әсәргә кадәр М. Мозаффаров халык җырын эшкәрткән булса кирәк, композитор «һай» сүзен шуннан күчергән (М. Җәлилдә «ах») [Җәлил, б. 122]. Шигырь тәрҗемәсенең әле күптән түгел генә яңадан басылган нөсхәсендә ул, гомумән, раслауны белдергән «да» (әйе) сүзе белән алмаштырылган һәм шигырь юллары башкача урнаштырылган (оригиналдагы кебек биш түгел, ә җиде). Түбәндә китерелгән таблицада М. Җәлил шигыренең икенче вариантындагы сүзләр, аның М. Мозаффаров әсәренә кергән куплетларын (җыр тексты белән чагыштырып) күрсәтү өчен, аскарак күчерелгән.

| *Шигырьнең беренче варианты* | *Шигырьнең икенче варианты* | *Җыр тексты* | *Җыр текстының тәрҗемәсе* |
|---|---|---|---|
| Йөгерә-йөгерә җиләк җыйганда,<br>Карагайлы урман буенда,<br>Син булырсың минем уемда.<br><br>Ах... җир җиләгем, кура җиләгем,<br>Сагынып көтәм сине, чибәрем. | | Йөгерә-йөгерә җиләк җыйганда,<br>Карагайлы урман буенда,<br>Син булырсың минем уемда, һай!<br>Җир җиләгем, кура җиләгем,<br>Сагынып көтәм сине, чибәрем! | Ищу ли ягод ранней порой,<br>Брожу ли я тропою лесной,<br>Думы к тебе стремятся одной, хай!<br>Ты слаще ягод, ты ярче весны,<br>Думы тобою одной полны. |
| Җырлый-җырлый печән чапканда,<br>Колхоз туганда, болында,<br>Син булырсың тагын уемда.<br>Ах... шат яшим мин бәхтем таңында,<br>Син дә булсаң иде янымда. | Кайтып килсәң урман юлыннан,<br>Йөгерә-йөгерә каршы чыгармын,<br>Тәмле җиләк белән сыйлармын.<br>Ах... җир җиләгем, кура җиләгем,<br>Сагынып көтәм сине, сөйгәнем! | Кайтып килсәң урман юлыннан,<br>Йөгерә-йөгерә каршы чыгармын,<br>Тәмле җиләк белән сыйлармын, һай!<br>Җир җиләгем, кура җиләгем,<br>Сагынып көтәм сине, чибәрем! | Идет моя бригада на луг<br>И с песней косит сено вокруг –<br>Думы к тебе стремятся, мой друг, хай!<br>Ты слаще ягод, ты ярче весны,<br>Думы тобою одной полны. |
| | Кайтып килсәң печән өстенә,<br>Җырлый-җырлый каршы барырмын,<br>Уңыш белән каршы алырмын.<br>Ах... шат яшим мин бәхтем таңында,<br>Син дә булсаң иде янымда. | Кайтып килсәң печән өстенә,<br>Җырлый-җырлый каршы барырмын,<br>Уңыш белән каршы алырмын, һай!<br>Җир җиләгем, кура җиләгем,<br>Сагынып көтәм сине, чибәрем!<br>Җир җиләгем | Тебя увижу на молотьбе,<br>Цветком сверкнешь в девичьей гурьбе,<br>Песней стремиться буду к тебе, хай!<br>Ты слаще ягод, ты ярче весны,<br>Думы тобою одной полны. |

Әсәрнең шигъри һәм музыкаль өлеше XX гасырның 30 нчы елларында композитор, шагыйрь һәм аларның иптәшләре Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә эшләгән һәм укыган чорда иҗат ителә. Димәк, М. Җәлил М. Мозаффаровның җырында үзе язган шигырьнең үзгәртелүе турында белгән һәм моның белән килешкән. Бу җырның сүзләрен тәрҗемә итүдәге кыенлыклар аның куплетларында һәм кушымтасында башкаручының җенесен билгеләгәндә эчтәлекнең анык булмавы аркасында барлыкка килә. Җыр хатын-кыз тавышы белән башкарыла. Ул шактый популярлашып китә һәм Татарстанның әйдәп баручы җырчылары – С. Садыйкова, Н. Теркулова, Д. Баранникова һәм Ә. Галимова репертуарына керә. Алар башкаруында ул 1938, 1954, 1959 һәм 1968 елларда пластинкаларга яздырылган. Куплетларның яшь кыз исеменнән җырлануы бәхәссез. Нәкъ менә ул йөгерә-йөгерә җир җиләге җыя һәм үзенең сөеклесе турында уйлый.

Йөгерә-йөгерә җиләк җыйганда,
Карагайлы урман буенда,
Син булырсың минем уемда, һай!

Авыл җирендә җиләк җыю хатын-кыз эше булып саналган. Аннары җиләк-җимештән еш кына как ясаганнар. Күп кенә халык җырларында, әкиятләрдә һәм уеннарда да шул турыда әйтелә. Ә менә кушымтада, безнең карашка, егет исеменнән мөрәҗәгать ителә. Биредә без Шәрыктагы күп кенә халыкларның традицион алымы белән очрашабыз: сөйгән ярның гүзәллеге төрле табигать күренешләре белән чагыштырыла. Шигырьдә ул җиләк (җир җиләге һәм кура җиләге) белән бәйләп күзаллана. Кушымтадагы йомгаклау сүзе белән – «чибәрем» дип шулай ук һәрвакыт хатын-кызларга дәшәләр.

Җир җиләгем, кура җиләгем,
Сагынып көтәм сине, чибәрем!

Шул сәбәпле, күрәсең, бу шигырьне рус теленә күчергән В. Бугаевский тәрҗемәсендә җырның буеннан буена хикәяләү егет исеменнән алып барыла. Татар композиторларының кайбер башка вокаль әсәрләрендә тәрҗемәчеләр гомумкешелек әһәмиятенә ия булган юлларда, киресенчә, җенес сыйфатын (гәрчә ул аермачык күренеп торса да) аерып күрсәтәләр. Шуңа бәйле рәвештә Т. Гыйззәт пьесасы буенча куелган «Бишбүләк» спектакле (тәрҗемәче Р. Хисамов) өчен С. Сәйдәшев иҗат иткән «Өмә җыры»ннан берничә мисал китерик. Аның кушымтасы гади җөмләдән – «Ай-һай, дусларым, дусларым, дус-ишләрем», дип дусларына мөрәҗәгать итүдән башлана, анда «дусларым» сүзе генә кабатлана. Әмма ул «Нет хорошего сукна, плачет девушка одна» дип тәрҗемә ителгән [Сәйдәшев, б. 138]. Шунысын да әйтергә кирәк, «дус-ишләрем» гыйбарәсе татарларда күбрәк ирләргә туры килә. Әмма рус телендәге җыр, башкаручылар төркеменнән чыгып, «Кызлар җыры» дип исемләнгән, бу аның мәгънәсен

чагылдырмый. Җырның исеме күп нәрсәләрне сыйдыра, аны туры мәгънәдә («Өмә җыры» – «ярдәм җыры») һәм нибары ике сүз белән генә әйтеп бетереп булмый. Ул татар халкы көзге йолаларының берсе – авыл кызларының, кайсы да булса йортта җыелып, күмәк эш башкаруы белән бәйле. Алар монда үзара ярдәмләшеп тула басу белән шөгыльләнгәннәр (тула басу өмәсе). Кызлар һәм егетләр җыелган мондый утырмаларда эш һәм күңел ачулар бергә үрелеп барган. Бу җырда алдагы дүртьюллык татар телендәге куплетларда сүзгә-сүз кабатланса да, төрлечә тәрҗемә ителгән.

| | | |
|---|---|---|
| Аңламыйсыз йөрәгемнең<br>Нигә ярсып типкәнен;<br>Аңламыйсыз күңлем тәрәзәсен<br>Кемнең килеп чирткәнен. | Из сукна сошьем кафтан мы,<br>Чтоб носил его джигит.<br>Пусть он будет и отвагой<br>И кафтаном знаменит (1). | Если б знали, как однажды<br>Меня парень повстречал,<br>Как в окно души девичьей<br>Он тихонько постучал (2). |

Көнкүреш *детальләрен* (бигрәк тә беренче куплетта) кертү нәтиҗәсендә тәрҗемәдә эчтәлекнең мәхәббәт белән бәйле ягы фәлсәфи төсмерен югалткан. Тәрҗемәче, автор текстыннан аермалы буларак, соңгы юлларда кыз турында искә ала. Татарча шигырьдә әлеге юллар әллә кемнәрнең күңел кылларын тибрәндерә. Мәсәлән, виолончельдә уйнаучы беренче профессиональ татар музыканты Хәмит Әбүбәкеровның кызы кайбер спектакльләрдә С. Сәйдәшев иҗат иткән көйләрне әтисе башкаруында (уйнавын һәм җырлавын) ишеткән. Ул әлеге җырның нәкъ менә шушы юлларын исендә калдырган. Бу мәкаләнең авторы үз вакытында әлеге йомгаклау җөмләсенең рус теленә тәрҗемәсен тәкъдим иткән иде [Юнусова, с. 72]:

| | |
|---|---|
| Аңламыйсыз күңлем тәрәзәсен<br>Кемнең килеп чирткәнен. | Вам не понять: в окно души моей<br>Кто, подойдя, тихонько постучал. |

Татар композиторларының вокаль әсәрләрендә еш кына тәрҗемә оригиналның барлык өлешләрендә – җырның исемендә, башында һәм куплетында татарча шигырь белән ярашмый. Әсәр исемнәре кыска булуга карамастан, аларның дөрес тәрҗемәсе кирәкле җырның ноталарын эзләгәндә аеруча мөһим. Шул ук вакытта, әсәр исемнәре генә түгел, хәтта җыр җыентыкларының исемнәре дә туры килмәгән очраклар бар. Мәсәлән, бер җыентыкның тышына «Кайда да йөрәктә» дип язылган. Ул – М. Мозаффаров иҗат иткән танылган җырның исеме. Әмма аны рус теленә тәрҗемә итәсе урынга бөтенләй башка авторның – С. Сәйдәшевнең «Без кабызган утлар» әсәренең исеме куелган. Әсәр исемнәрен ялгыш тәрҗемә итү сәбәпләре төрле. Бигрәк тә автор кулъязмасын мөхәррир эшләгән вариант белән чагыштырганда, сәхнә әсәрләрендә дә номерлар атамасындагы үзгәрешләрне күрергә мөмкин. Еш кына татар композиторларының вокаль әсәрләрендә тәрҗемәгә аның мәгънә ягыннан оригиналга туры килүкилмәве ягыннан катгый таләпләр куелмаган. Хәтта үз шигырьләрен тәрҗемә иткән шагыйрьләр дә ирекле шәрехләүгә барганнар, бу исә кайбер вокаль әсәрләрнең исемнәрендә чагылыш тапкан. Мәсәлән,

Ә. Ерикәйнең «Кил, чибәрем» шигыре гүзәл романтика белән сугарылган. Рус теленә тәрҗемәдә Р. Яхин романсында ул бөтенләй башкача яңгырый: «Тебя желанней нет». Исегезгә төшерәбез, тәрҗемәдә исемнәре чыганактан аерылган әсәрләрне эзләү еш кына проблемалы булып чыга. Р. Яхин иҗаты мисалында әлеге мәсьәләне Й. Исәнбәт тарафыннан әзерләнгән биобиблиографик күрсәткеч [Рустем Яхин, 2001, с. 40] ярдәмендә хәл итәргә мөмкин. Әмма мондый белешмәлеге булмаган башка татар композиторларының әсәрләре белән нишләргә? Ә инде М. Мозаффаровның без тикшергән җырына килгәндә, М. Җәлилнең шигыре «Җир җиләге» дип исемләнгән. М. Мозаффаровның «Җиләк җыйганда» атамасы берничә тәрҗемәдә очрый, шуларның иң киң таралганы – «По ягоды», ләкин сирәк очрый торган «Собирая ягоды» дигәнен иң төгәле дип танырга кирәк. Җыр исеменең беренче вариантын әдәби һәм шигъри яңгырашы аркасында сайлап алган булганнар, күрәсең. Югарыда күрсәтелгән пластинкаларда җырның композитор куйган исеме ике язмада татарча («Җиләк җыйганда», Н. Теркулова җырлый) һәм русча («По ягоды», Д. Баранникова җырлый) бирелгән, башкаларында – М. Җәлил шигыренең үзенчәлекле исеме урын алган.

Татар шигырьләрен рус теленә тәрҗемә иткәндә иң начары – аның төп чыганак эчтәлегенә туры килмәве, бу еш кына аны артык гадиләштерүгә китерә. М. Мозаффаровның «Җиләк җыйганда» җырының татарча шигъри юлларын тәрҗемәсе белән чагыштырганда бу аеруча ачык күренә. Бу җәһәттән «когда моя бригада возвращается с косьбы» җөмләсе бигрәк тә аерылып тора. Ул күп кенә татар композиторларының (С. Сәйдәшев, Р. Яхин) иҗади омтылышларына туры килмәгән, чөнки алар поэтик образлар булмаган, көнкүрешне сурәтләгән шигырьләрдән качарга тырышканнар.

Вокаль музыкада татар шигырьләре тәрҗемәләренең сыйфаты канәгатьләнерлек булмауның субъектив сәбәпләре тәрҗемәчеләрнең тиешле белемгә ия булмавы һәм шәхси үзенчәлекләре белән бәйле. Аларның кайберләрен тасвирлап узыйк. М. Мозаффаровның «Җиләк җыйганда» җырында текстны рус теленә Владимир Александрович Бугаевский (1905–1964) тәрҗемә иткән. Ул үзе дә шигырьләр язуга карамастан, тәрҗемәче буларак та танылган. В. Бугаевский төрле шагыйрьләрнең мирасына мөрәҗәгать иткән. Гете әсәрләрең тәрҗемә итеп, аеруча зур уңыш казанган. Шул ук вакытта аның немец телен бик яхшы белүен һәм алман шагыйренең иҗаты белән мавыгуын да ассызыклыйлар. В. Бугаевскийның игътибарын музыкаль темалар җәлеп иткән. Аның үзенең, мәсәлән, «Бетховен» дигән шигыре дә бар. Ә чагыштырмача күптән түгел (моннан алты ел элек) немец композиторы Р. Вагнерның беренче өч операсы либреттоларының В. Бугаевский тарафыннан эшләнгән тәрҗемәләре басылып чыга. В. Бугаевскийның иҗади мирасында әледән-әле татар шигърияте әсәрләре дә күренә. Ләкин шуны да әйтергә кирәк: аның алар өстендә ничек эшләве моңарчы бөтенләй өйрәнелмәгән. Аларның басылып

чыкмаганнары турында белешмәләрне, аерым алганда, Россия дәүләт әдәбият һәм сәнгать архивында табарга мөмкин. Анда, мәсәлән, Ә. Ерикәй шигырьләренең ул ясаган тәрҗемәләре саклана. Аларны үз вакытында «Октябрь» журналы редакциясенә тәкъдим итеп караганнар, әмма барыбер бу тәрҗемәләр аның архивында калганнар. Татар композиторларының вокаль һәм опера музыкасында Казан тәрҗемәчеләреннән Р. Хисамовны аерым билгеләп үтәргә кирәк. Раушан Кыям улы Хисамов Казан дәүләт консерваториясенең вокаль факультетын тәмамлаганнан соң, башта филармониядә эшләгән, аннары М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрына күчкән. Кыска гомерле булуына карамастан (1927–1961), җырчы-солист (характерлы тенор), тәрҗемәче, либретточы, тәнкыйтьче, опера театрының репертуар-әдәби бүлеге мөдире буларак, үзен төрле яклап күрсәтә алган. Н. Җиһановның «Алтынчәч» (Урмай партиясе) һәм Җ. Фәйзинең «Тапшырылмаган хатлар» операларын (Искәндәр һәм Студент рольләре), Җ. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясен (Зыя Гафуров, Беренче шымчы) куйганда җырчы сыйфатында катнашкан [Исәнбәт, 2003, б. 128]. А. Ключаревның «Тау әкияте» балеты либреттосын язуда Р. Хисамов иҗатташ булган. Күрәсең, театрда әдәби бүлек мөдире вазифаларын башкару аңарда бу мәдәни-тамаша учреждениесе турында мәкаләләр, шулай ук анда куелган спектакльләргә рецензияләр язу теләге тудыра («Башмагым» комедиясе, «Кисекбаш», «Раушан» һәм «Тау әкияте» балетлары турында). Ул татарчадан русчага төрле жанрларга караган зур-зур әсәрләр тәрҗемә итә: Н. Җиһановның «Җәлил» операсы либреттосы (В. Фере белән берлектә), С. Сәйдәшев музыкаль драмаларыннан аерым шигырьләр («Зәңгәр шәл», «Наемщик», «Ил», «Бишбүләк» һ.б.), композиторның кайбер мөстәкыйль вокаль әсәрләре. Аның тәрҗемәләрендә дә кытыршылыклар бар һәм аларның барысын да уңай бәяләп тә булмый. С. Сәйдәшев белән Т. Гыйззәтнең «Өмә җыры»н да соңгылары исәбенә кертергә туры килә.

Текстны татар теленнән рус теленә күчерү турында сөйләшүгә йомгак ясап, шуны әйтәсе килә: тәрҗемә белән оригинал шигырь телен яхшы белгән һәм әсәр белән мавыгып эшләгән кеше генә шөгыльләнергә тиеш. Шуны да искәртик: СССР да хәтта чит ил язучыларының әсәрләрен дә беренчел чыганактан түгел, ә рус теленнән тәрҗемә иткәннәр. Тагын шунысы да бар: тәрҗемәче тиешле белемгә ия булырга тиеш (филологик белем күздә тотыла). Моннан тыш, шигырь текстларын үзе дә аз гына булса да шигырь язу сәләтенә ия кеше тәрҗемә итәргә тиеш, дигән фикер дә бар (мәсәлән, танылган полиглот һәм укытучы Д. Петров). Үз вакытында күренекле шагыйрь, Казан дәүләт университеты телчесе һәм укытучысы М. Ногман (1912–1976) әнә шул таләпләргә тулаем җавап биргән. Ул берничә көнчыгыш телен (үзбәк, таҗик, фарсы һәм төрек телләрен) яхшы белгән һәм шулардан турыдан-туры татарчага тәрҗемә иткән. М. Ногман бу эш белән яратып шөгыльләнгән. Аның татар теленә тәрҗемәләре арасында совет композиторларының берничә мәшһүр җыры да бар:

«Кайда сез, дусларым, полкташларым?» («Где же вы теперь, друзья-однополчане?» В. Соловьев-Седой көе, А. Фатьянов сүзләре), «Яз көнендә гөлләр матур була» («Хороши весной в саду цветочки», Б. Мокроусов көе, С. Алымов сүзләре) һ.б. [Юзиев, б. 9].

Татар композиторларының вокаль әсәрләре кергән басмаларда рус телле шигырьләр уңышсыз дип табылган очракларда, әлеге хәлне төзәтү өчен, аларның кайберләрен, тәрҗемәләрне (җыр исемнәрен дә кертеп) алмаштырып, әйтик, композитор һәм шагыйрьләрнең юбилейлары уңаеннан яңадан нәшер итүне планлаштырырга кирәк. Ноталарсыз, бары тик шигырьләрне генә бастырып чыгаруны да альтернатив вариант буларак күрсәтергә мөмкин. Оригиналны тәрҗемә белән чагыштыру өчен, бу очракта әсәрне берьюлы ике телдә бирү сорала.

**Әдәбият**

*Җәлил М.* Сайланма әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 429 б.

*Жиганов Н.* Лирическая тетрадь. Казань: Татар. кн. изд-во, 1977. 28 с.

*Исанбет Ю.* Муса Джалиль и татарская музыка. Казань: Татар. кн. изд-во, 1977. 160 с.

*Исанбет Ю. Н.* Словарь музыкально-сценических произведений татарских композиторов, поставленных на казанской сцене. Казань: Магариф, 2003. 158 с.

Кайда да йөрәктә. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 152 б.

*Мозаффаров М.* Йөрәк җыры: Җырлар, романслар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 80 б.

Рустем Яхин: Биобиблиографический указатель. Казань: Магариф, 2001. 118 с.

Рустем Яхин в воспоминаниях современников. Казань, 1996. 276 с.

*Сәйдәшев С.* Без кабызган утлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 310 б.

*Тазиева К.С.* Мансур Музафаров. Казань: Татар. кн. изд-во, 1994. 152 с.

*Файзуллин И.* Песня жить помогает // Советская Татария, 1968. 4 дек.

*Юзиев Н.* Мәхәббәтнең гомере чикләнмәгән // Ногман М. Акчарлаклар оча Иделдә: җырлар, шигырьләр, поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. Б. 8–10.

*Юнусова Г.Ф.* Жажда совершенства (судьба первого татарского профессионального виолончелиста) // Юнусова Г.Ф. О музыке и музыкантах Казани: сборник материалов. Казань: Отечество, 2009. 106 с.

***Юнысова Гүзәл Фәйзрахман кызы,***

*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 728.03

***И.И. Халикова***

# Ф. ХАЛИКОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ БОРЫНГЫ КАЗАННЫ СУРӘТЛӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Статья посвящена анализу произведений известного художника Республики Татарстан, академика Российской Академии художеств Фирината Халикова. По архивным документам, зарисовкам и устным преданиям он выстроил исторический облик древнего города в жанре реконструкций. В его картинах раскрывается величие и исторический масштаб ханской Казани.

**Ключевые слова:** творческая мастерская Российской Академии художеств в Казани, история, ханская Казань, интерпретация, реконструкция.

The article is devoted to the analysis of the works of the famous artist of the Republic of Tatarstan, academician of the Russian Academy of Arts Firint Khalikov. On the basis of archival documents, sketches and oral legends, he built the historical appearance of the ancient city in the genre of reconstructions. The greatness and historical scale of Khan's Kazan is revealed through works of art.

**Keywords:** creative workshop of the Russian Academy of Arts in Kazan, history, Khan Kazan, monumental architecture, art, artist, exhibition, exposition.

Казан – Идел елгасының сул ярында урнашкан шәһәр, Татарстан Республикасы башкаласы, Россиянең мөһим икътисади һәм мәдәни үзәге. Ул – күп гасырлык тарихы булган борынгы шәһәр генә түгел, ә Европа белән Азия, православие белән ислам мәдәниятләре кисешкән урын да. Моннан 1000 еллар элек Идел Болгарының төньяк өлешендә Киев Русеннан, Византия империясеннән һәм Якын Көнчыгыштан агылган сәүдә кәрваннарының очрашу урыны буларак ныгытма төзелә. Шәһәрнең яшен Казан Кремле территориясендә археологик казу эшләре вакытында табылган таш корылмалар, агачтан эшләнгән койма калдыклары, көнкүреш әйберләре, шулай ук 929–930 еллар белән даталанган чех тәңкәсе буенча билгеләделәр [Садриев, 2016, с. 161–172].

1438 елда болгарлар тарафыннан төзелгән ныгытылган корылма Алтын Урда ханы Олуг Мөхәммәд гаскәрләренең каты һөҗүменнән соң Казан ханлыгының башкаласына әйләнә [Золотоордынское обозрение, 2014, с. 15]. Рус елъязмаларында Казан XIV–XV гасырлардан искә алына башлый. Алтын Урда дәүләте составында мөһим сәяси һәм сәүдә үзәгенә әверелеп, Казан каласы актив үсеш кичерә. Казанның үсүе һәм ныгуы хәрби низагларсыз гына да бармый. Мәскәү кенәзлеге белән ике арадагы ызгыш-талашлардан соң, 1552 елда Явыз Иван гаскәрләре Казанны яулап ала, шәһәрнең зур өлеше җимерелә, ә татарларны Кабан күленең сазлыклы яр буйларына күчерәләр,

анда соңрак Иске Татар бистәсе барлыкка килә. Казан краенда баш күтәрүләр бастырылганнан соң, шәһәр Россия дәүләте белән бәйле яңа чорга аяк баса.

Урта гасырлар Казанының тарихын өйрәнү һәрвакыт актуаль булды һәм бу өлкәдә яңадан-яңа ачышлар ясала тора. XIX–XX гасыр башында татар тарихы фәне барлыкка килгәннән соң, тикшеренүчеләр татар тарихын, нигездә, төрки-татар фольклорына, төрки этнографик елъязмаларга һәм лингвистик материалларга, шулай ук гарәп, фарсы тарихи документларына, Россия һәм Төркия тарихчыларының хезмәтләренә таянып өйрәнәләр. Хөсәен Әмирхан, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Һади Атласи һ.б. кебек мәшһүр затларыбызның хезмәтләре нигезендә татар халкы тарихы формалаша башлый.

Тарихи нәкыш – тематик картинаның иң катлаулы жанрларыннан берсе. Моңарчы да татар сәнгатендә популяр булган милли тарих һәм тарихи нәкыш темасы 1920–1930 кабаткүтәрелеш кичрә. XX гасыр бүтәнчәрәк кыйммәтләргә өстенлек бирә: 1960 еллар ахырына кадәр Татарстан рәссамнары әсәрләрендә милли тема һәм тарих этнографизм һәм типаж дәрәҗәсендә генә ачыла. Казанның архитектура символы булган Сөембикә манарасы сурәтләре, Касыйм шәһәре (бәреп төшерелгән ханбикәнең соңгы сыену урыны) пейзажлары А.И. Трапицын, С.О. Лывин, В.В. Анютин, Р.А. Гыйләҗев, Г.Л. Эйдинов картиналарында урын ала.

1970–1980 елларда Татарстан тарихи нәкыше панорамасында Ч.Г. Әхмәров, Б.И. Урманче, И.К. Зарипов, Ә.И. Тумашев, К.А. Нәфыйков, Р.М. Вахитов тарафыннан үз чоры өчен яңа әсәрләр языла. Тарихка тирән хөрмәт атмосферасында иҗат итү бу осталарның сәнгатьтә үз юлларын табуында хәлиткеч роль уйный. Бакый Урманче ханнар чоры Казанын Сөембикә образы аша ача (ханбикәнең скульптур портреты яки аксакал сәнгатькярнең график әсәре) [Татарский мир, 2019, с. 372–385]. Шәркый Урта Азия Р.М. Вахитов иҗатына да үз эзен салган. Борынгы Көнчыгыш миниатюрасына охшатып сәнгатьчә стильләштерү алымнары яссы композицияләрдә, төрле төстәге тапларының локаль һәм ачык булуында, офыклар юклыкта чагыла.

Бу осталарның эшләрендә иҗади хыялның бик көчле булуы сизелә. Темаларның һәм сәнгати алымнарның гаҗәеп төрлелегендә төптән уйланылган стиль һәм сәнгати-образлы система тоемлана. Нәтиҗәдә алар иҗатында татар халкының мәдәни истәлекләре, гореф-гадәт һәм йолалары яңа сулыш ала. Нәкыш осталары, архитектураның бөеклеген һәм тантаналылыгын данлап, үз картиналарында мигъмарият пейзажын сурәтлиләр, ерак тарихта калган мәдәниятләрне чагылдыралар.

1980–1990 еллар чигендә милли теманы аңлауда яңа этап башлана. Ф.Г. Халиков иҗатының башлангыч чорында борынгылыкны һәм татар тарихын өйрәнү өстенлек итә. Рәссамның әсәрләренә теманы ышанычлы итеп, җентекләп эшләү хас, ә стилистикада ул рус тарихи

нәкыше (И. Репин, В. Суриков) традицияләренә якын тора [Программа подготовки к празднованию...].

Тарихи темаларга язылган масштаблы полотнолары белән популярлык казанган зур рәссам Ф. Халиков үзенең әсәрләрендә татар тарихының драматик сәхифәләрен гәүдәләндерә. Һәм моны ул, рәссам һәм гражданин буларак, үзенең миссиясе дип саный [Фиринат Халиков, 2012, с. 23]. Аның туган халкының үткәне белән кызыксынуына хәзерге заманда күтәрелгән мәсьәләләр сәбәп була [Современное искусство художников Татарстана, 2005, с. 134].

Сәнгать өлкәсендә башлангыч белемне Ф. Халиков Киров сәнгать училищесында ала (1979–1983). Профессиональ сәнгати белемгә ия булганнан соң, реалистик нәкышнең пленэр пейзаж жанрында эшли.

Казанда Россия Рәссамнар академиясенең иҗат остаханәләренә кергәч (1993), Болгар шәһәренә багышланган әсәрләр циклына тотына. Татарларның килеп чыгышы белән кызыксынуы нәтиҗәсендә 1994 елда ул тарихчы һәм археолог, татар халкы тарихы буенча күпсанлы хезмәтләр авторы Альфред Халиков белән таныша. Фәннипопуляр әдәбият нәшер итү аларның уртак эшенә әйләнеп, басмаларда тарихи реконструкция Ф. Халиковның иллюстрацияләре рәвешендә урын алырга тиеш була. Рәссам, татар халкының тарихын өйрәнү максаты белән, ирекле тыңлаучы сыйфатында Казан университетында укый башлый.

Ф. Халиков тарихи пейзаж жанрында (1995) үз иҗатының төп темасы итеп Казан ханлыгы чәчәк аткан чорны сайлый һәм «Мәңгелек Казан» циклын башлап җибәрә. Аның иҗатында бу тема күбесенчә әлеге шәһәр тарихына карата гомуми кызыксыну уяну белән бәйле була [Фиринат Халиков, 2005, с. 27].

Казан шәһәренең 1000 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек барганда Ф. Халиковның беренче шәхси күргәзмәсе оештырыла. Ул 1996 елның җәендә «Казан» милли мәдәният үзәгендә уза. Күргәзмәдә рәссамның түбәндәге төп эшләре тәкъдим ителә: «Казан өчен сугыш» (1996), «XVI гасырда Казанда кышкы кояшлы көндә» (1996), «Болак ягыннан кышкы Казан» (1996) һ.б.

Шәһәр тарихын өйрәнү белән тарихчылар да, төбәкне өйрәнүчеләр дә, шул исәптән чит ил кешеләре дә җитди шөгыльләнә башлый. Казан шәһәре хакимияте шәһәрнең меңьеллыгы концепциясен әзерләү буенча фәнни-теоретик эш алып бара [Программа подготовки к празднованию...]. Республикада һәм аннан читтә Казанга нигез салыну датасын билгеләү буенча киң күләмле эш җәелдерелә, Казан Кремлендә археологик эзләнүләр башлана, нәтиҗәдә Казанның яулап алынуын яктырткан моңарчы билгеле булмаган чыганаклар билгеле була [Фиринат Халиков, 2012, с. 32]. Ф. Халиков фәнни материалны җентекләп өйрәнә, архив документлары белән эшли, тарихи, археологик, әдәби һәм этнографик мәгълүматларны анализлый. Әзерлек эшләренең башлангыч стадиясендә аның тарафыннан эскизлар һәм караламалар эшләнә.

Ф. Халиков, шулай итеп, беренчеләрдән булып Урта гасырлар Казанының иконографиясен фәнни нигезгә куя. Архив документлары, рәсемнәр һәм телдән сөйләнгән риваятьләр буенча ул реконструкция жанрында борынгы шәһәрнең архитектурасын торгыза («Казан Кремленең барлыкка килү этаплары») [Фиринат Халиков, 2017, с. 7]. Архитектура пейзажында аның барлык элементларының пространствода урнашуын сурәтләү аеруча мөһим. Моның өчен перспективаны да, буяулар нисбәтен дә дөрес күрә белергә кирәк. Барыннан да элек, җирнең яссылыгын һәм күкнең киңлеген дөрес сурәтли белү зарур.

Рәссам үз картиналарында шәһәрнең гүзәл панорамасын тәфсилләп сурәтли. Ерак ата-бабаларыбыз белән бәйләнешне яңадан торгызуга, үткәндәге архитектураны, шәһәрне реконструкцияләүгә омтылыш ачык чагыла. Ф. Халиков һәрвакыт яңа ракурс, «кош очышы» биеклегеннән яңа ноктаны, ел фасылын, шәһәр тормышындагы вакыйгаларны, киң антураж һәм стаффаж сайлый, шәһәрнең чуарлыгын ватандашларының йөрәгендә сакларга тырыша [Фиринат Халиков, 2012, с. 34]. Рәссам картинада Казан ханлыгының тарихи образын гына түгел, ә һәр чорда барган вакыйгаларны да гәүдәләндерү бурычын куя. Шулай итеп, ул татар риваятьләрендә һәм рус елъязмаларында тасвирланган затларны, күренекле шәхесләрне сурәтли.

Полотноларда чагылдырылган сюжетлар күп фигуралы, жанрлы. Бигрәк тә Сөембикә, Олуг Мөхәммәд, Шаһгали, Иван Грозный кебек тарихи шәхесләргә багышланган сюжет линияләрен аерып күрсәтергә мөмкин. Дөнья һәм рус тарихи нәкышендә танылган рәссамнар полотнода сюжетларны халык төркеме фонында чагылдыралар. Ф. Халиков та татар халкын беренче планга чыгарып, шул үрнәккә иярә. Ул халык төркемен картина пространствосын тутыру өчен түгел, ә татар халкының бөеклеген чагылдыру өчен бирә. Ф. Халиков картиналарында халык – вакыйгада катнашучы гына түгел, аеруча мөһим миссия үтәүче [Фиринат Халиков, 2012, с. 37].

Рәссамның «Мәңгелек Казан» сериясенә караган эшләре арасында «Нурлы Казан» (1997) – күп фигуралы һәм масштаблы картиналарның берсе. Картина Бөтендөнья татар конгрессының II корылтае уңаеннан язылა. Полотно өстендә эшләү барышында Ф. Халиков Казанның тарихи архитектурасын һәм ландшафтын гына түгел, ә мәдәни образын да тудыру өчен, көнчыгыш костюмы һәм коралы буенча китапларны тирәнтен өйрәнә. Төп идеяне булдыруда Н. Халитовның Кремль архитектурасы буенча фәнни хезмәте зур роль уйный. Аның фикеренчә, Казандагы хан сарае цитадельдән һәм административ үзәктән тора, соңгысында сарай, диванханә, төрбәләр, сарай мәчете, гвардия һәм хәрәмле хан резиденциясе, казна, хезмәтчеләр өчен биналар урнашкан һәм ул ныгытма дивары белән әйләндереп алынган [Халитов]. Әмма төрле сәбәпләр аркасында аларның уртак эше барып чыкмый, бу рәссам һәм галимнең ханнар чоры Казаны панорамасының форма һәм масштабларына карашлары төрле булу белән бәйле.

Безнең көннәргә Казанның 1701 елга кадәрге шул дәвердә яшәгән рәссамнар тарафыннан ясалган ике гравюрасы гына килеп җиткән. Аларның берсе – Казан Кремленең панорамалы күренеше [Валеев, Валеева-Сулейманова, 2002, с. 82]. Ул Адам Олеарий тарафыннан башкарылган һәм аның Голштин илчелегенең Фарсы иленә сәяхәтен тасвирлаган китабының икенче басмасына (1656) кертелгән. Әлеге гравюра, Адам Олеарий сурәтенең ышанычлы булу-булмавы галимнәр тарафыннан берничә тапкыр шик астына куелуга карамастан, рәссамны иҗатка рухландыручы төп чыганак булып тора [Хузин, Ситдиков, 2005, с. 16].

Архитектура һәм сәнгати стиль формаларын интерпретацияләгәндә, Ф. Халиковка татар шәһәр мәдәниятенең күп кенә югалган таныклама-дәлилләрен, иҗади якын килеп, яңадан тудырырга туры килә. Рәссам тарафыннан алдан ясалган биш реконструкция «Нурлы Казан»ны иҗат иткәндә аеруча әһәмиятле роль уйный. Алар «Казан шәһәренең барлыкка килү этаплары» дип атала, һәм аның туу, гөрләп чәчәк ату чорларын, тарихның борылыш мизгелләрен һәм халык фаҗигаларын чагылдыра. Һәр картина шул үзенчәлеге белән әсир итә: ракурс биеклектән алынган, бу исә шәһәрнең үсеш һәм формалашу этапларын күзәтеп барырга мөмкинлек бирә, борынгы фоторәсем яки киноленталарны карау тәэсире тудыра.

Югарыгы үрдән – дозор манарасы башыннан, күләмнәрне чамалап, күз карашы аска тәгәри һәм сюжетның кульминацион ноктасы – халыкның һәм җиңү яулаган гаскәрләрнең матур чатырда урнашкан патшабикә җитәкчелегендәге хан яраннары белән очрашуы күренешенә барып тоташа. Казан халкы регентша белән очрашуга килгән – баш иеп сәламләргә һәм хәер-фатиха алырга. Гаскәр исә – тугрылыкка ант бирергә. Атлылар төркеме башындагы хәрби җайдак – Казан гвардиясе башлыгы. Мәйданда – сәүдә кибетләре, Көнчыгыш товарлары белән сату-алу бара, ә уңда – чәйханә, аның чуар киемле музыкантлары балконда урнашкан [Фиринат Халиков, 2017, с. 63].

Зур күләмле полотноның максаты – Казанны Казан ханлыгының башкаласы буларак гәүдәләндерү, халыкның «нурлылыгын», шәһәр архитектурасын, татар милли киемен күрсәтү. Бу – үткәнне бүгенге белән бәйли алган, Татарстан Республикасында Казан тарихы турында сөйләүче бердәнбер күп фигуралы, жанрлы һәм тарихи картина.

Яңадан торгызылган Казан образлары рәссам алдына яңа бурычлар куя: шәһәрнең тарихи образын гына түгел, ә анда барган вакыйгаларны да аңларга кирәк.

Урта гасырлар Казанына эчке яктан күз салыйк. Сөембикә ханбикәгә багышланган картиналар сериясе – рәссам шәһәр пространствосын һәм кешеләрне җентекләп сурәтләгән полотноларның берсе. Ханбикә турындагы өч картина (аларны триптих итеп тә карарга була) аның тормышының төрле чорлары турында сөйли. Иң масштаблы һәм эчтәлеге буенча шактый зур эшләрнең берсе – «Сөембикә

белән хушлашу» (2001). Рәссам Казан корылмаларының зур булмаган бер өлешен, ханбикәсен озатучы халыкны күрсәтә.

Полотнода сурәтләнгән күңелсез табигать тә – болытлар белән капланган күзгә соры күк йөзе, елга өстеннән килгән салкынлык һәм томан эченә кереп югалган офыклар – ханбикәсен озата бара кебек. Казан әле матурлыгы белән таң калдыра, аның җимерелер көннәре әле алда [Фиринат Халиков, 2012, с. 58].

Алтын киемнәр кигән ханбикә кояш кебек якты, ул улы Үтәмешне үзенә сыендырган һәм озатырга килгән халыкка моңлы-сагышлы карашын ташлый. Кешеләрнең күзләрендә дә шушы ук моң-зар, коточкыч зур югалту ачысы. Архитектурада таш корылмалар, мәчетләр, хан төрбәләре өстенлек итә, әмма агач корылмалар да, шәһәрнең дошманнан саклану дивары да бар. Таш биналарның алгы якларында милли орнамент һәм гарәп язуы төшерелгән.

Ф. Халиков – Н. Фешин һәм П. Беньков чорларыннан югала башлаган классик реалистик сәнгать кануннары системасын тулаем үзләштергән тәүге рәссамнарның берсе. Аның ата-бабаларыбызның бөеклеген һәм иң яхшы сыйфатларын колачлаган картиналары гаять зур әхлакый-тәрбияви әһәмияткә ия.

Рәссам бүген дә тарихи жанр өстендә эшләүдән туктамый. Сәнгать әсәрләрендә тарихның яңадан-яңа сәхифәләрен ача. Тамашачыны яңа белемнәр белән баета, Урта гасырлар Казан ханлыгы тарихының матурлыгына карап сокланырга өйрәтә.

Рәссам Ф. Халиковның иҗаты Казанның борынгы тарихы, аның барлыкка килү вакыты белән кызыксынуны арттырды, шулай ук Казан Кремле ансамбленең ЮНЕСКО Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирасы «Исемлеге»нә кертелүенә булышлык итте. Рәссам Ф. Халиков иҗат иткән полотналарны киң җәмәгатьчелек Татарстан һәм Россия сынлы сәнгатендәге әһәмиятле күренеш дип таныды. Рәссамның картиналары илебезнең 15 музее фондларында, шул исәптән Казан һәм Мәскәү музейларында, шулай ук АКШ һәм Финляндиядәге шәхси коллекцияләрдә саклана.

**Әдәбият**

*Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Древнее искусство Татарии. Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. 166 с.

*Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Древнее искусство Татарстана. Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. 104с.

Золотоордынское обозрение: Сборник статей. 2014. № 2 (4).

Программа подготовки к празднованию 1000-летия основания г. Казани от 3 марта 2001 года. № 295-р. // https://izo-museum.ru/hazine/vyistavki-i-sobyitiya/hudojniki-tatarstana-obraz-syuyumbike--posledney-tsaritsyi-kazanskogo-hanstva-v-kanun-500-letiya-so-dnya-rojdeniya. Дата обращения: 05.09.2021.

*Садриев Н.Р.* История изучения городской застройки ханской Казани // Поволжская археология. 2016. № 4 (18). С. 161–172.

Современное искусство художников Татарстана / [текст Дина Валеева, Розалина Шагеева]; [фот. Газинур Хафизов, Марат Гарифзянов, Гульнара Сагиева]. Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. 384 с.: ил.

Татарский мир / авторы-сост.: Г.Ф. Габдрахманова, Э.М. Галимова, Д.Ф. Загидуллина, И.Л. Измайлов, А.Р. Салихова, А.Г. Ситдиков, Л.М. Шкляева. Казань: Заман, 2019. 392 с.: ил.

Творческая мастерская живописи в Казани. – Казань: Заман, 2015. – 112 с.: ил.

Фиринат Халиков. Вечная Казань / Текст: *Р.Г. Шагеева*. Казань: Заман. 2005. 192 с.: ил. (Мастера живописи)

Фиринат Халиков. Графика. Скульптура. Дизайн. Казань: Заман, 2012. 208 с.: ил.

Фиринат Халиков: [альбом] / [авторы текста: Р.Г. Шагеева, Р.Р. Магдеев]. Москва: Белый город: Воскресный день, 2017. 63, [1] с.: цв. ил., цв. портр.; 32 см. (Мастера живописи).

*Халитов Н.Х.* Исчезнувшие архитектурные комплексы и памятники Кремля. Источник http://www.rusarch.ru/halitov2.htm

*Хузин Ф.Ш., Ситдиков А.Г.* О локализации в Казанской крепости исторической мечети Кул Шарифа // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2005. Вып. 2.

***Халикова Ирина Илдар кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты аспиранты;*
*Азнакай төбәкне өйрәнү музее директоры*

УДК 821.512.162

*И.А. Габиббәйле*

# АЗӘРБАЙҖАН ӘДӘБИЯТЫН ДӨНЬЯГА ТАНЫТКАН ЯДКЯР: НИЗАМИ ГАНҖӘВИНЕҢ «ҖИДЕ ГҮЗӘЛ»Е

В честь 880-летия выдающегося поэта и мыслителя Низами Гянджяви Президент Азербайджанской Республики объявил 2021 год Годом Низами Гянджяви. Проживший всю жизнь в древнем городе Гянджа Низами Гянджяви знаменит своими бессмертными произведениями, написанными на персидском языке. Низами Гянджяви своим творческим наследием внес значительный вклад в обогащение мировой культуры и литературы. Автор статьи раскрывает глубину и оригинальность поэтики Низами Ганджяви, обращая особое внимание на те произведения поэта, которые на протяжении веков оказывали сильное влияние на татарскую поэзию и письменный лиро-эпический фольклор.

**Ключевые слова:** «Пятерица» Низами Ганджяви, азербайджанское поэтическое наследие, шедевр мировой литературы, поэма.

In honor of the 880th anniversary of the outstanding poet and thinker Nizami Ganjavi, the President of the Republic of Azerbaijan declared 2021 the Year of Nizami Ganjavi. Nizami Ganjavi, who has lived all his life in the ancient city of Ganja, is famous for his immortal works written in Persian. Nizami Ganjavi made a significant contribution to the enrichment of world culture and literature with his creative heritage. The author of the article reveals the depth and originality of the poetics of Nizami Ganjavi, paying special attention to those works of the poet, which over the centuries have had a strong influence on Tatar poetry and written lyric-epic folklore.

**Keywords:** «Five» by Nizami Gandjavi, Azerbaijani poetic heritage, masterpiece of world literature, poem.

Күпгасырлык азәрбайҗан әдәбияты корифейлары пантеонында Низами Ганҗәви исеме, иҗаты күренекле урын алып тора. Дөнья әдәбияты һәм иҗтимагый фикере үсешендә азәрбайҗан әдәбиятының әйдәманлык өлеше шушы исем белән бәйләнгән. Шәрык әдәбиятларындагы кебек үк, Гареб әдәбиятларында да аның белән тиңләшерлек сүз осталары күп түгел. Низами Ганҗәвине Гаребнең Гомер һәм Шекспиры, Россиядә – Лев Толстой белән янәшә куеп чагыштыру урынлыдыр. Шәрык әдәбиятлары мәйданында ул буй җитмәс биеклек булып кала.

Азәрбайҗан әдәбиятында Низами Ганҗәвине Олы Кавказ биеклегенә тиңләп буладыр. Аның «Хәмсә»се («Бишлек») Гобустандагы ташкыя язуларына охшаган – вакыт үзгәрешләренә баш бирмәс ныклыкта.

Низами Ганҗәвинең милли һәм гомумкешелек кыйммәтләрен оста чагылдырган үлемсез иҗатын «Дәдә Коркыд» эпосы белән тиңләштерергә мөмкин. Бу яктан Низами Ганҗәвинең «Хәмсә»се һәм

«Дәдә Коркыд китабы» азәрбайҗан әдәбиятының бәһасез хәзинәсе булып тора.

«Дәдә Коркыд» кебек «Хәмсә» дә – азәрбайҗан иҗади аңының ныклы нигезе, мәңгелек югарылыгы, таҗы ул.

«Дәдә Коркыд» эпосы шикелле үк, «Хәмсә» дә – азәрбайҗан әдәбиятының таҗы һәм хаклы рәвештә дөнья әдәбияты җәүһәре булып санала.

Низами Ганҗәвинең шигъри иҗаты – азәрбайҗан классик лирикасының сирәк очрый торган гүзәл әсәрләреннән. Низами лирикасының нәфис, тәрбияви әһәмиятле сюжет мотивлары лиро-эпик шигырьнең классик үрнәге булып тора. Низами Ганҗәви азәрбайҗан поэзиясендә сюжетлы лирикага нигез сала. Әйтик, мәшһүр «Төнлә минем янга гыйшкым килде» газәле – классик поэтик новелланың оригиналь үрнәге. Поэтик эшләнеше һәм әкияти сюжет характеры белән Низами Ганҗәви лирикасын шәркый язма әдәбияттагы мәшһүр «Мең дә бер кичә» белән тиңләштерергә мөмкин.

«Синнән башка» романсын лирик яңгырашы ягыннан Низами Ганҗәвинең «Гыйшык җан»ы, Узеир Гаҗибәйленең «Аршин мал алан»ы, Былбылның «Бакчадагы чәчәклеге» белән тиңләргә була. «Синнән башка» романсының популярлыгын Низами лирикасы, Узеир Гаҗибәйле музыкасы, Былбылның вокал диапазоны тәэмин итә. «Синнән башка» романсында лирика, музыка, мелодия, вокал берлеге кабатланмас фон тудыра, эстетик тәэсирлелек серенә әйләнә.

Низами Ганҗәви Шәрык шигъриятендә сүз остасы, аның «Хәмсә» берләштергән биш поэмасы югары кимәлдә язылган. Һәр поэма – кабатланмас, камил сәнгать үрнәге.

«Серләр хәзинәсе» – шигърият байлыгының энҗесе булса, «Хөсрәү вә Ширин» – мәхәббәтнең чиксез көче турындагы дастан.

«Ләйлә вә Мәҗнүн» – «Ромео һәм Джульетта»га кадәр күп алдан туган даһи романтик мәхәббәт маҗарасы.

«Җиде гүзәл» – Низами Ганҗәвинең шигырь һәм рух дөньясы.

«Искәндәрнамә» – азәрбайҗан әдәбиятының «шаһнамәсе», Әфләтүн академиясе. Беренче өлеше: «Игъбалнамә» («Язмышлар китабы») – Сократның күренекле «Әңгәмәләр»е дәрәҗәсендә. Икенче өлеше: «Шәрәфнамә» («Дан китабы») – сәнгатьнең Аристотель «Поэтика»сы кебек үк үлемсезлек яулаган бөек һәйкәле.

Сүз сәнгатендә үлмәс ат яулаган Низами Ганҗәви үзе исә дөньяны яулаган Александр Македонскийга тиң (ул аны үзенең «Искәндәрнамә»сендә тарихка кертә). Александр дөньяны кылыч белән буйсындырса, Низами аны каләм белән үзенеке итә.

«Җиде гүзәл» поэмасы шигъри «сәясәтнамә»нең иң беренче үрнәге булып тора. Аның төп мотивлары яңа тип идарәче Бәһрам Гурның ил белән идарә итү сәясәте, башка илләр белән мөнәсәбәтләр коруы белән бәйләнгән. Ике арыслан тырнагыннан патша таҗын тартып алган Бәһрам Гур образында Низами Ганҗәви ил белән идарә итү хокукын монархия режимын урнаштыруга түгел, ә акыл һәм зирәклек,

булдыклылыкка нисбәт итә. Бу XII гасыр шартларында Шәрык дөньясы өчен генә түгел, Гареб масштабында да гадел падишаһ идеалын эзләүдә яңа адым, сәяси хакимлек өчен көрәшне күзаллауның яңа юлы була.

«Җиде гүзәл» – Низами Ганҗәви шигъриятендә шагыйрьнең дөньяга карашын, фәлсәфәсен тәкъдим итү, җиде мәхәббәт маҗарасын хикәяләү. Әлеге поэма – Бәһрам Гурның тормышка һәм кешегә мәхәббәтенә әдәби һәйкәл.

Поэма 1197 елны языла. Хакыйкать һәм әхлак идеяләре күзлегеннән «Җиде гүзәл» әсәре «Хөсрәү вә Ширин» поэмасын дәвам итә, бер үк вакытта «Искәндәрнамә»гә кереш ролен башкара.

«Җиде гүзәл»дә Низами Ганҗәви, «Хөсрәү вә Ширин» поэмасының герое Хөсрәү Пәрвизнең мәхәббәт маҗараларын яңа сәхифәләр белән баетып, сәнгать дөньясына зирәклек һәм мәхәббәт фәлсәфәсе бүләк итә. Шул ук вакытта поэмада гадел идарәче мотивын үстереп, Низами идеал эзләүне яңа биеклеккә күтәрә. Бу яктан Бәһрам Гур образы «Серләр хәзинәсе»ндәге падишаһ Солтан Санҗарның һәм «Хөсрәү вә Ширин» поэмасындагы Хөсрәү Пәрвизнең дәвамчысы, Искәндәрнең башлангычы булып калка. Бәһрам Гурдан башка Хөсрәү Пәрвиз була алмаган кебек, Искәндәр образы да иҗат ителә алмас иде.

Бәһрам Гур образы – Низами Ганҗәвинең иҗади фикерләвендә алмашыну мизгеле: мәхәббәттән зирәклеккә борылыш ноктасы. «Җиде гүзәл»дәге шаһ Бәһрам Гур – идарәче сурәтендә шагыйрь кешелеклелек, гуманизм идеалын гәүдәләндерә. Бу образ мисалында ул киң мәгънәсендә гуманизм манифесты иҗат итә. Шуның белән Низами Ганҗәви шәркый әдәбиятларның күпгасырлык панегирик (мәдхия җырлау) традициясендә өр-яңа юнәлеш ача. Даһи шагыйрь-акыл иясе шәркый әдәбиятларның озын-озак тарихын шаһ династияләрен мактаудан, елъязма рәвешеннән азат итә, панегирик форматка җан өрә, аны әхлакый мотивлар белән баета.

«Җиде гүзәл»дә Бәһрам Гурның төрле илләр гүзәлләре белән әңгәмәләре Низами Ганҗәвинең дөньяга карашы киңлеген, эрудициясен күрсәтә. Низаминың «Искәндәрнамәсе» фәлсәфи-сәяси энциклопедия булса, «Җиде гүзәл» – үз чорының мәдәни-әхлакый энциклопедиясе, дия алабыз. Поэмадагы «Дөньяда мәгълүм күпсанлы китаплардан мин үземә кирәк фикерләрне җыярга тырыштым» кебек юллар шагыйрьнең, язма чыганакларны тирәнтен белеп тә, үз әсәрендә беркемне дә кабатламавына, укучы игътибарына оригиналь әсәр тәкъдим итүенә дәлил булып килә. Поэмада җиде климатик поястагы вакыйгаларны тасвирлау, мөһим күренешләрне чагыштыру, эчтәлекле нәтиҗәләр ясау һәм кызыклы идеяләр җиткерү авторның бөек фикер иясе булуын сөйли. Низами Ганҗәви идеяләре шәркый Яңарыш (Ренессанс) постулатлары белән органик берлектә яңгырый. «Җиде гүзәл» поэмасы азәрбайҗан Яңарышының таҗ әсәре, мөселман яңарышы мәдәниятенең мөһим казанышы булып тора.

Җир шарының җиде климатик урынчылыгындагы илләрнең гүзәлләре хикәяләгән идеяләрне Низаминың үз халкына да, дөнья халыкларына да җиткерергә теләгән фикерләре дип карарга кирәк. Барлык хикәятләрдә камил кеше җәмгыятьне сәламәтләндерү шарты булып килә. Гомумән алганда, «Җиде гүзәл» поэмасы – кеше турында шигъри дастан. Җиде гүзәлнең һәр хикәяте кешелеклелек турында акыл бирә.

«Тиңдәшсез, сихерле күзле» Кытай гүзәленең хикәяте – Яхшылык һәм Явызлык турында баллада. Харәзем принцессасы Назпәри кыйссасы – Низами үзе дә бер улы булган төрки халыкларның әхлакый асылларын саклап калу юлында кичергән җәфаларны шигъри бәян итү.

Славян патшасы кызы, «төрки киемле» матур Насринуш бәяны –Александр Пушкинга кадәр алты йөз ел элек язылган тылсымлы шәрык әкияте, аның сюжеты соңрак рус әдәбиятына үтеп керә.

Һинд чибәре, шагыйрь тарафыннан «гүзәл фәрештә, матурлыгы дүрт көнлек айга тиң» дип җырланган Фирек әкияте – мәхәббәт маҗараларына багышланган романтик шигърият үрнәге.

Мәгъриб падишаһы Азергүр сүзләреннән «нуры көнне һәм йолдызларны каплаган» Маһи сөйләгән бәян тормыш дәресе булып аңлашыла.

Фарсы чибәре, Кәйкавуз нәселеннән, «татлы телле,... тәвә коштай җете матур» Дөрсат хикәяте легендар Кайян династиясе турындагы шәрык повесте булып чыккан.

Юнан чибәре, «Цесарьнең бәхетле кызы» Хумай исә мәхәббәт фәлсәфәсен бәян итә.

«Җиде гүзәл» поэмасында хатын-кыз идеалы Фитнә образында гәүдәләнә. Акыллы, зирәк Фитнә, хакимнең игътибарын җәлеп итеп, аның әйләнә-тирәне бәяләвенә йогынты ясый. Бу образда Низаминың кеше факторына мөнәсәбәте чагылыш таба, аны шагыйрь барлык башка кыйммәтләрдән югары күтәрә. Шул сәбәпле гади кешеләр вәкиле булган Фитнә образы Яңарыш әдәбиятында халык арасыннан чыккан кешенең идеаль сурәте булып аңлашыла.

«Җиде гүзәл» «астраль» әсәр буларак та игътибарга лаек. Поэмада күк йөзе – Кояш, Ай, йолдызлар хакында фикерләр әйтелә, болар Низаминың астрономия фәнендә тирән белемнәренә ишарә ясый.

Моннан тыш, поэмада күк күренешләренә, аларга бәйле вакыйгаларга мөрәҗәгать итү геройларның кәеф-халәтен, тормышка карашын, ышануларын белдерүгә дә хезмәт итә.

Низами Ганҗәвинең «Җиде гүзәл» поэмасы төрки-мөселман дөньясы әдәбиятларына зур йогынты ясый. Поэма традицияләренең тәэсирен «Йосыф һәм Зөләйха» сюжетына иҗат ителгән күпсанлы үрнәкләрдә күрергә мөмкин. «Миһер һәм Мөштәри» («Кояш һәм Юпитер») тибындагы поэмаларда Низами традицияләрен иҗади файдалану күк күренешләрен тасвирлауда аермачык.

Низами Ганҗәвинең башка әсәрләре кебек үк, «Җиде гүзәл» дә фарсы телендә иҗат ителгән. Әлеге фактор шагыйрь иҗатының

таралуында, аның традицияләре киң мәдәни мәйданнарга үтеп керүдә зур роль уйный. Азәрбайҗан укучыларына поэма төрле чорларда халык шагыйрьләре Мамед Рагим һәм Балаш Азероглу тәрҗемәләрендә килеп ирешә. Дөньяга билгеле «Җиде гүзәл» балетын күренекле азәрбайҗан композиторы Гара Гараев Низами поэмасы мотивлары буенча иҗат итә, бу әсәр Азәрбайҗан дәүләт опера һәм балет театрының гына түгел, бәлки күп кенә башка театрлар репертуарыннан да төшми.

Мәшһүр Низами Ганҗәвинең һәр әсәре кебек, «Җиде гүзәл» поэмасы дөньяның күп телләренә тәрҗемә ителгән, Азәрбайҗанда һәм чит илләрдә тикшеренүләр предметы булып хезмәт итә. 800 елдан артык вакыт эчендә поэма үзенең актуальлеген саклаган, мәңгелек мәхәббәт, гуманизм, зирәклек һәм әхлакый кыйммәтләр турындагы дастан буларак укучылар һәм галимнәр өчен әһәмиятен югалтмаган.

Низами Ганҗәвинең «Җиде гүзәл» поэмасы – азәрбайҗан әдәбиятында милли һәм гомумкешелек кыйммәтләрен бер җепкә тезгән һәм дөнья әдәбиятын шәркый аһәң белән баеткан шигъри энҗе, авторның реаль һәм идеаль матурлык турында күзаллаулары өлгесе.

Баку шәһәрендә Бәһрам Гурга һәйкәл исә – «Җиде гүзәл» поэмасына мәрмәрдән салынган хөрмәт билгесе булып тора.

***Габиббәйле Иса Акпер улы,***
*филология фәннәре докторы, академик,*
*Азәрбайҗан Милли Фәннәр академиясенең вице-президенты,*
*Низами Ганҗәви исемендәге әдәбият институты директоры*

УДК 821.512.145

# Ә. КАРГАЛЫЙНЫҢ «РУМЛЫЛАР БЕЛӘН КЫТАЙЛАР АРАСЫНДАГЫ БӘХӘС» ШИГЪРИ ХИКӘЯТЕ

В статье речь идет о «Хикайатес самин» («Восьмом рассказе») из поэтического сборника поэта-суфия Абульманиха Каргалый «Переводы хаджи Абульманиха ал-Бистави ас-Са‘иди», которому было дано условное название «Спор ромейцев с китайцами». Данное повествование является своего рода назира (поэтическим подражанием) к «Маснави» Дж. Руми. В нем продемонстрирована яркая авторская интерпретация известного восточного сюжета. Данное повествование представлено в оригинале и подстрочном переводе на современный татарский язык.

**Ключевые слова:** Абульманих Каргалый, суфийская поэзия, образ зеркала, авторская интерпретация, восточный сюжет, назира.

The article deals with «Hikayates samin» («The Eighth story») from the poetry collection of the Sufi poet Abulmanikha Kargaly «Translations of Haji Abulmanikha al-Bistavi as-Sa'di», which was given the conditional name «The dispute of the Romanians with the Chinese». This narrative is a kind of nazir (poetic imitation) to J. Rumi's «Masnavi». It demonstrates the author's vivid interpretation of the famous oriental plot. This narrative is presented in the original and a subscript translation into the modern Tatar language.

**Keywords:** Abulmanikh Kargaly, Sufi poetry, image of a mirror, author's interpretation, oriental plot, nazira.

Әбелмәних Каргалыйның мөселман әүлияләре тормышы турындагы хикәятләрдән, шулай ук дүрт лирик шигырьдән торган «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних...» җыентыгы (барлыгы 918 бәет) 1845 елда Казанда нәшер ителә. 1889 елда Казан университеты табгыханәсендә Түбән Курса авылында яшәүче Шәмсетдин бине Хөсәен акчасына җыентыкның икенче басмасы дөнья күрә [Каргалый, 1889]. Хәзерге вакытта китап ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана. Әлеге җыентык мөстәкыйль хикәятләрдән тора, әмма темасы, идея эчтәлеге һәм формасы ягыннан ул – бербөтен һәм тәмамланган китап. Һичшиксез, Ә. Каргалыйның бу җыентыкка кергән ун шигъри хикәяте дә рухы һәм эчтәлеге буенча суфилар турындагы әсәрләр рәтенә керә. Күпсанлы суфичыл мотивлар, образлар һәм символлар шуның ачык дәлиле булып тора.

Бөтен хикәятләрнең диярлек сюжеты борынгы легенда һәм риваятьләрдән алынган. Әмма, кызганычка каршы, без күп кенә хикәятләрнең чыганакларын билгели алмадык. Бүгенге көндә бу мәсьәлә бик авырдан хәл ителә яки бөтенләй хәл ителми диярлек. Беренчедән, безнең карашка, татарлар арасында таралган хикәятләр Һиндстан, Греция, Гарәбстан һәм, әлбәттә, Иран халыкларының

борынгы мәдәниятләреннән алынган элементлар һәм сюжетлар бергә үрелеп барган калейдоскоп кебек. Һиндстаннан Борынгы Азия һәм Кавказ территорияләре аша безнең ата-бабаларыбыз яшәгән җирләргә килеп ирешкәнче берничә үзгәреш этабы кичергән мондый хикәятләр гади халык арасында аеруча популяр булган; алар аерым шигъри җыентыклар булып басылып чыккан һ.б. Еш кына бу хикәятләргә яңа сюжетлар, мотивлар өстәлеп, алар шулкадәр үзгәргән ки, оригиналлары белән уртаклыклар бик аз калган. Кайбер хикәятләрдә татар фольклорыннан алынган мотивлар һәм символларның йогынтысы да сизелә.

«Икенче хикәят»тә («Хикәятес-сани») җыентык авторы үзенең кайбер хикәятләрен имам әл-Газалиның «Тәфсире кәбир» («Зур тәфсир») һәм «Мишкят әл-әнвәр» («Нурлар чыганагы») дигән ике китабыннан алуын әйтә. Әмма, чынлыкта, Ә. Каргалыйның шигъри хикәятләре белән әлеге китаплар арасында әлләни уртаклык юк, һәрхәлдә, аларны оригиналларга, бигрәк тә «Мишкят әл-әнвәр» кебек фәлсәфи-дини трактатка тиңләп булмый. XIX гасырда татарлар арасында киң таралган Коръән тәфсире «Тәфсире кәбир»гә килгәндә, Ә. Каргалый үз әсәрләренә пәйгамбәрләр тарихыннан алынган кайбер сюжетларны кертеп җибәрә, аерым алганда, сүз җыентыкның беренче һәм өченче хикәятләре («Хикәятел-әүвәл», «Хикәятес-сәлис») турында бара. Ни өчен Ә. Каргалый имам Газалиның «Мишкят әл-әнвәр» әсәрен чыганакларның берсе итеп күрсәткән соң? Бу дәвердә татар шагыйрьләренең имам Газали, Ф. Гаттар, Низами, Фирдәүси һ. б. кебек Көнчыгыш классикларының күренекле әсәрләрен оригиналлар буларак күрсәтү тенденциясе татар авторлары арасында шактый киң тарала һәм гадәти күренешкә әверелә. Әмма бу дөреслеккә туры килми. Мәсәлән, Һәмдәминең XVIII гасыр башында язылган «Нәсыйхәтнамә» әсәрен өйрәнгән Ф. Яхин әлеге авторның иҗатына да шундый ук тенденция хас булуын ассызыклый. Галим фикеренчә, Һәмдәми үзе сюжетларны Ф. Гаттарның «Панднамә»сеннән алуын расласа да, бу чынбарлыктан ерак, һәм «Нәсыйхәт-намә», һичшиксез, татар язучысының оригиналь әсәре булып тора [Яхин, б. 16].

Гыйбрәтле хикәянең төп сюжетын интерпретацияләү татар шагыйренең ун шигъри әсәренә дә диярлек хас. «Хикәятес-самин» («Сигезенче хикәят») – Ә. Каргалый җыентыгындагы ун хикәянең берсе. Ул Җ. Руминың «Мәснәви»енә үзенә күрә нәзирә буларак язылган. Шартлы рәвештә без аны «Румлылар белән кытайлар арасындагы бәхәс» дип атадык. Бу хикәяттә шулай ук автор интерпретациясе дә ачык сизелә: бөек фарсы классигының оригиналь әсәрендә күрсәтелгәнчә, диварны тутыктан чистартмыйлар һәм шомартып ялтыратмыйлар, ә көзге эләләр. Көнчыгышның бөек каләм иясе яшәгән һәм иҗат иткән чорда көнкүрештә көзгедән файдаланмаганнар әле, ул соңрак – 1279 елда уйлап табылган. Әмма моның белән хикәятнең асылы үзгәрми бит: Җ. Руми һәм Ә. Каргалый әсәрләрендә ялтырап

торган дивар да, күзге дә бу дөнья ләззәтләреннән азат, Аллаһны һәм ул бар иткәнне чагылдырган чиста һәм тәкъва суфи йөрәген символлаштыра. Шулай итеп, Ә. Каргалый үз әсәренә үзенчәлекле суфи күзге образын кертә. Һәм ул сюжет линиясенең гомум нигезенә үрелеп, төп образга әйләнә.

Ә. Каргалыйның «Сигезенче хикәят»е җыентыкка кергән башка хикәятләр кебек үк югары стильдәге татар әдәби телендә язылган, бу – хикәят жанрына караган әсәрләрнең барысына да хас сыйфат. Әсәрдә хәзерге татар укучысына аз аңлаешлы гарәп, фарсы сүзләре дә, әйләнештән чыккан борынгы төрки сүзләр, катлаулы грамматик формалар, сөйләм әйләнмәләре, диалектизмнар күп. Шуңа күрә укучылар игътибарына оригинал текст белән янәшә аның безнең тарафтан башкарылган сүзгә-сүзгә тәрҗемәсе дә тәкъдим ителә.

| **Хикайәтес-самин** | **Сигезенче хикәя** |
|---|---|
| 1. Хөҗҗәт-әл-ислам Газали хәзрәте<br>Диде бер көн бу гүзәл хикәяте. | 1. Исламны дәлилләүче Газали хәзрәте<br>Сөйләде бер көн бу гүзәл хикәятне. |
| 2. Халь илә хальнең миянында мисал<br>Кәлтерүбдер, беләсен, әй хуш хисал. | 2. Хәл белән хәлнең асылы [турында] мисал<br>Китереп (сөйләде ул), белегез, әй, хуш холыклылар. |
| 3. Чин илә Румдан ике таифәләр<br>Җәмгъ улыб бер падишаһә кәлделәр. | 3. Кытай белән Византиядән ике төркем кешеләр,<br>Бергә җыелып, бер патшага килделәр. |
| 4. Диделәр һәр бере бер гарзы: һөнәр<br>Күстәреб, шаһ янында гыйззәт мәгәр. | 4. Һәр кайсы бер теләк белдерде: һөнәр<br>Күрсәтеп, шаһ янында кадер-хөрмәтле була. |
| 5. Йә, болар кем? – диделәр. – Әй шәһрияр,<br>Бездәен остаз юк эндар-дияр. | 5. «Йә, болар кем? – диделәр. – Әй патша,<br>Бездән дә остараклар юк бу илдә!» |
| 6. Япаруз хасыр вә мөнакъкаш ба гыймад.<br>Касры Шәддадтан дәхи әүла зияд. | 6. Ясарбыз сараеңны бизәкләр төшерелгән, колонналар белән.<br>Шәддад сараеннан гүзәлрәк булыр. |
| 7. Әйләйүбән фикр илә дәгъвалары<br>Бер берендән маһируз диб һәрбере. | 7. Горурланып даулашалар [күкрәк киереп],<br>Бер-береннән остарак дип һәрбере. |

| | |
|---|---|
| 8. Гакыйбәт шаһ бер сарай күстәрер:<br>«Дир ки, бондан халеңез мәгълүм улыр. – | 8. Соңында шаһ бер сарайны күрсәтте:<br>«Хәлегез шуннан мәгълүм булыр, – дип әйтте. – |
| 9. Ике диварына әйләң зиннәти<br>Вирүбән, изһар идәсез сәнгати». | 9. Ике диварына бизәк төшерәсез,<br>Сәнгатегезне күрсәтәсез». |
| 10. Дотдылар бер җанибне румилар,<br>Дотды чинилар дәхи руи дигәр. | 10. Бер як диварга кереште румлылар,<br>Бүтән якка кереште кытайлар. |
| 11. Ара йирдә дотдылар һәм пәрдәләр;<br>Бер-беренә мотталигъ улмаялар. | 11. Арага кордылар пәрдәләр:<br>Бер-беренең эшен күрмәсеннәр [дип]. |
| 12. Дөрлү-дөрлү нәкыш кылды румилар,<br>Дотды чинъилар дәхи руи дигәр. | 12. Төрле-төрле бизәк төшерде румлылар,<br>Үз якларында булдылар кытайлар. |
| 13. Дөрлү-дөрлү рәң илә мәнкуш җидар,<br>Нә эшләдеке, нә күрелдеке бар?! | 13. Төрле төстәге рәсемнәр белән бизәлгән дивар,<br>Эшләнгәне, күрелгәне кайда бар?! |
| 14. Сәнгать илә дәхи ошбу чинилар<br>Ул тараф дивара сайкал ордылар. | 14. Зур осталык белән кытайлар<br>Үз як диварларына көзге куйдылар, |
| 15. Һәм мөкайад улмады гайрә болар,<br>Эшемез улды тәмам, дир румилар. | 15. Башка бернәрсә эшләмәде болар,<br>«Эшебез тәмам булды», – диләр румлылар. |
| 16. Кем безем дә эшемез улды тәмам,<br>Диде чин әһле дәхи башаз вә кам. | 16. «Безнең дә эшебез тәмам булды!» –<br>Диделәр кытайлар шатлык белән. |
| 17. Патшаһ әйдүр, гаҗәп бу сүзеңез.<br>Йук дорыр диварда һич монкушеңез. | 17. Падишаһ әйтә: «Гаҗәб бу сүзегез,<br>Юк ич диварда һичнинди бизәгегез». |
| 18. Бонлар әйдүр сәнгатемез би гоман,<br>Заһир улыр пәрдә кәтдеке заман. | 18. Болар әйтә: «Сәнгатебезне, һичшиксез,<br>Пәрдәне алгач күрерсез». |
| 19. Боерыр шаһ, рәвгъ идәсез пәрдән,<br>Күрәлем кем бу гаҗәеб кәрдән. | 19. Боерды шаһ: «Күтәрегез пәрдәне,<br>Күрик әле бу гаҗәеп нәрсәне!» |
| 20. Әйләделәр шул заман рафгъ хиҗаб,<br>Нә күрерләр, күргел имди шәйх-у шаб. | 20. Шул чагында күтәрделәр пәрдәне,<br>Ни күрерләр, күрделәр карты-яше. |

| | |
|---|---|
| 21. Әһле румның кылдыгы дөрлү нөкүш,<br>Нәчә рәңлә дөздеке мәрге вә хуш. | 21. Румлылар төшергән төрле бизәкләр,<br>Ничәмә-ничә төс белән ясалган гүзәл кошлар. |
| 22. Чинилар диварында улды гәян,<br>Калды хәйран шаһ илә пир вә җәван. | 22. Кытайлар диварында ап-ачык булып күренде,<br>Шаһ белән карты-яше хәйран калды, |
| 23. Укыдылар бәрәкаллахны һамин,<br>Чиниларә сәдъ-һәзаран афәрин. | 23. « Бәрәкалла!» – дип шул чак<br>Кытайларга йөз-меңнәрчә афәрин укыдылар. |
| 24. Имди белдең ошбу хали, әй газиз,<br>Фәһм идәрсәң уласән сахибе тәмиз. | 24. Инде белдең бу эшне әй, газиз,<br>Уйлап баксаң, аера белерсең. |
| 25. Әһле заһирлар дорыр нәккашы дар,<br>Анларың һимmәтләре-нәкыш дивар. | 25. Әһле заһирлар – йорт бизәүчеләр,<br>Аларның эшчәнлеге – стена бизәү. |
| 26. Әһле батыйндыр шул чинилар мисал,<br>Табылыр анларда мәҗмүгъ әл хисал. | 26. Ходайга күңел белән ышанучылар шул кытай осталары кебек,<br>Аларда төрле-төрле хасиятләр табылыр. |
| 27. Чук тәкәллефлә улан рәң вә нөкуш<br>Би тәкәллеф табылыр анларда хуш, | 27. Күп (тырышлык) ясалмалылык белән булган төс һәм бизәк<br>Аларда болай гына да бик әйбәт табылыр хезмәт белән. |
| 28. Әһле заһир михнәтилә нәчә саль<br>Табдыгы гыйльме ходаи зөлҗәлал. | 28. Әһле заһир ничә ел (михнәт чигеп)<br>Ходай гыйлемен тапса. |
| 29. Әһле халә би тәкәллеф, би кәсеб<br>Фазыл илән эксәре әйләр нәсыйб. | 29. Халь әһелләре интегүсез, кәсепсез генә<br>Белемлелек белән күбрәк нәтиҗәгә ирешәер. |
| 30. Йәки һәрбер шәйхе шәрга раст идәр.<br>Нә идәрсә шәргылә дугры кидәр. | 30. Ягъни һәрбер шәех шәригать законын раслар,<br>Нәрсә эшләсә дә шәригатькә туры килер. |
| 31. Әһле инкярә бу сүз кылмаз әсәр,<br>Зира дилләре хәҗәр, гүшләре кәр. | 31. Инкяр әһленә бу сүз тәэсир итмәс,<br>Чөнки күңелләре-таш, колаклары ишетмәс. |



Ә. Каргалыйның «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди» җыентыгындагы «Сигезенче хикәят»нең беренче битләре

## Әдәбият


*Каргалый Ә.* Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди. Казан: Казан ун-тының табгыханәсе, 1889. 54 б.

*Яхин Ф.З.* Һәмдәминең «Нәсыйхәт-намә» әсәре // Әдәбият чыганаклары һәм текстология. Казан: ТР ФА Г. Ибраһимов исем.ТӘҺСИ, 1992. Б. 16.



*Текстны басмага филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Язма һәм музыкаль мирас үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре*
***Хасавнех Алсу Әхмәдулла кызы*** *әзерләде*

# И. САБИТОВА, Г. САБЕРОВАНЫҢ «ҮСЕМЛЕК АТАМАЛАРЫНЫҢ ТАТАРЧА-РУСЧА АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕГЕ» (Казан: ТӘҺСИ, 2020. 216 б.) ТУРЫНДА

Татар лексикографиясендә биология терминнарын туплап, аларның башка телләрдәге (рус, латин) эквивалентларын биргән, аңлатмалары китерелгән махсус сүзлекләр шактый. Үсемлек һәм гөмбә атамаларын җыеп биргән сүзлекләр дә бар. Мондый сүзлекләр төзү тәҗрибәсе К. Насыйри исеме белән бәйле. Галимнең «Гөлзар вә чәмәнзар» («Үләнлек һәм чәчәклек», 1894), «Хәвасы нәбатат» («Шифалы үләннәр», 1894) сүзлекләренә телебездә кулланылышта йөргән фитонимнар махсус атамалар буларак тупланган. Үсемлек һәм гөмбә атамалары, биология терминнарының аерым бер төркеме буларак, А. Халидов, В. Гаранин төзегән һәм «Табигать әлифбасы» сериясендә чыккан «Русча-татарча, татарча-русча биология терминнары сүзлеге»нә (1996), Г. Саберованың «Татарча-русча-латинча үсемлек атамалары сүзлеге»нә дә (2002) теркәлгән.

Татар терминологиясен өйрәнгән Ф. Фәсиев әле узган гасырның 60 нчы еллары азагында ук биология терминнарына күзәтү ясап, «бу тармакта объектларның күп (ун, хәтта йөз меңнәрчә) булуы эшне читенләштерә, әзер атамалар җиткереп булмый» дип яза. Матбугат, мәктәп-мәгариф, авыл хуҗалыгы практикасындагы һәм халык сөйләмендәге атамаларның еш кына туры килмәвен ассызыклый. Шуңа да бу тармакта терминологик сүзлекләр төзү кирәклегенә басым ясый, аларга фәнни терминнар да, халык телендәге вариантлар да (ачыклау өчен) кертелергә тиешлеген әйтә. XX гасырның 90 нчы елларыннан соң махсус сүзлекләр басылып чыгуга карамастан, кайбер атамаларның семантикасы төгәл билгеләнмәү, биология фәне һәм терминологик системаның һәрвакыт үсештә булуы сәбәпле, бу мәсьәлә бүген дә актуальлеген югалтмый.

Мәгълүмат алу мөмкинлекләре киңәю, фәннең яңа өлкәләре, яңа технологияләр барлыкка килү һәм аларның тизләтелгән үсеше терминологик сүзлекләргә дә үзгәрешләр кертте. Кулланучыларның ихтыяҗыннан чыгып, сүзлек мәкаләсе тәрҗемә, аңлатма, синоним, контекст, орфоэпик помета кебек мәгълүмат категорияләрен үз эченә ала башлады. Шуңа да бу өлкәдә бүгенге көндә комплекслы сүзлекләр өстенлек итә.

Тәкъдим ителгән «Үсемлек атамаларының татарча-русча аңлатмалы сүзлеге» әнә шул үзенчәлекләрне истә тотып эшләнгән. Алда әйтелгән сүзлекләрдән ул материалны киңрәк колачлавы белән дә аерылып тора. Монда ике меңгә якын атама сигез тематик төркемдә (үсемлекләр белән бәйле гомуми төшенчәләр; агач, куак һәм ярымкуаклар, үсемлекләр; лианалар һәм үрмәләп үсә торган үсемлекләр; суүсемнәр, түбән төзелешле һәм споралы үсемлекләр; гөмбәләр;

үсемлек бергәлекләре атамалары; үсемлекләр анатомиясе, физиологиясе белән бәйле атамалар) алфавит тәртибендә бирелә.

Сүзлек мәкаләсе терминологик сүзлекләрнең телара аңлатмалы төрләренә хас структурага ия. Ул башта калын хәрефләр белән теркәлгән баш сүзне, аннан якты хәрефләр белән китерелгән русча эквивалентны, аннан соң бирелгән аңлатма һәм иллюстратив материалны үз эченә ала:

> **АЛМАГАЧ** ЯБЛОНЯ. Гөлчәчәклеләр семьялыгыннан ак яки алсу чәчәк ата, эчендә кара орлыгы булган хуш исле җимеш (алма) бирә торган агач. *Алмагачлар һәм чия чәчәк атканда тау битләвенә кабат ап-ак кыш әйләнеп кайткандай була (А. Тимергалин).*

Әйтергә кирәк, иллюстратив материал, нигездә, матур әдәбияттан китерелә. Бу исә үсемлек атамаларының көндәлек сөйләмдә, әдәби телдә еш кулланылуына бәйле.

Тематик төркемнәргә бүлү, беренче карашка, сүзлек белән эшләүне кыенлаштыра кебек. Әмма сүзлеккә теркәлгән русча-татарча атамалар күрсәткече бу очракта ярдәмгә килә. Шул ук вакытта мондый бүленеш атамаларны нәкъ шул микросистеманың берәмлеге итеп карарга, белгечләргә атаманы үз төркемчәсе буенча табарга мөмкинлек тудыра. Лексик-семантик вариантларны күрсәтү исә атаманың терминнар системасында күпмәгънәле булуын күрсәтеп тора:

> **ҖИМЕШЛЕК**[1] ПЕСТИК. Чәчәкнең аналык органы; җимшәнлек. *Бөртекчә – коры җимеш, аның элпәсыман җимешлек тирәлеге орлык кабыгына тоташып үсә, һәм шуңа күрә аны орлыктан аерып алып булмый (Ботаника).*
>
> **ҖИМЕШЛЕК**[2] ФРУКТОВЫЙ САД. Җимеш бакчасы; җимеш агачлары үскән урын. *Аска караса, гаҗәеп матур күренеш: гөлбакча, җимешлек, кәүсәр күле, хур кызлары... (С. Поварисов).*

Сүзлек аңлатмалы булуы белән дә кыйммәтле. Аңлатмалар киң, авторлар алар ярдәмендә укучыга теге яки бу үсемлек, гөмбә турында (чәчәге, яфрагы, кәүсәсе, тамыр системасының зурлыгы, формасы, төсе, исе һ.б.ш.) тулы мәгълүмат бирүне максат итеп куйган. Бу яктан сүзлек кечкенә энциклопедиягә тиң. Шул ук вакытта аңлатмаларда үсемлекне атауга нигез булган төп билге дә ачыла:

> **ЕЛАНБАШ** ЗМЕЕГОЛОВНИК. Иренчәчәклеләр семьялыгыннан күгелҗем шәмәхә яки ак чәчәкләре формасы белән елан башын хәтерләткән берьеллык үләнчел үсемлек; умыл.

Сүзлек диалекталь атамаларны һәм фонетик вариантларны теркәве белән дә әһәмиятле. Алар *диал.* тамгасы белән аерылып бирелә:

> **АКБАШ**[1] *диал. к.* **әнис**. *Су буенда акбаш – әнисләр хуш ис тарата (Казан утлары).*
>
> **АКБАШ**[2] *диал. к.* **әнеч**. *Ишегалдында ямь-яшел: әнечтер, акбаштыр – болын инде менә (Р. Газиз).*
>
> **АКБАШ**[3] *диал. к.* **меңьяфрак**.

Мондый атамаларны кулланылыш даирәсен күрсәтеп терминологик сүзлекләргә туплау термин булмаган сүзләрне ачыклауга, терминнар системасын камилләштерүгә хезмәт итә.

Синоним атамалар сүзлектә традицион рәвештә я аңлатмадан соң өтер аша, я беренчесенә *к.* (карагыз) тамгасы белән җибәрелеп күрсәтелгән:

**БӘРЧӘ** *к.* **себеркәч**.
**КАБЫК**[1] КОРА. Агачның үзагачтан аерылып торган тышкы катлавы; кайры.

Синонимнарны сүзлеккә теркәү, билгеле булганча, тел байлыгын күрсәтүгә, фитонимик терминология составын тулырак күзалларга, дублетлар һәм триплетларның кайсы ешрак кулланылганлыгын, доминанталарны билгеләргә ярдәм итә.

Монда классификация терминнары да (алар янында *күпл.* пометасы куелган), искергән атамалар да (алар *иск.* тамгасы белән аерылып тора), кайбер җыйма исемнәр дә (*җиләк-җимеш, чыбык-чабык*) урын алган.

Татар телендә үсемлекләргә бәйләнешле кайбер мәкаль, әйтем, сынамыш һәм ышануларны туплап бирү дә хезмәтне баета. Шул рәвешле сүзлек фәнни мәгълүмат кына биреп калмый, ә халыкның озак вакытлар үсемлекләрне күзәтүләренә нигезләнгән тәҗрибәсе белән дә таныштыра.

И. Сабитова һәм Г. Саберованың «Үсемлек атамаларының татарча-русча аңлатмалы сүзлеге» уңай бәяләнергә хаклы. Монда үсемлек һәм гөмбә атамаларын туплау һәм системага салу буенча зур эш башкарылган. Сүзлек аерым тармак белгечләренә һәм гомумән киң катлау укучыга гамәли кулланма буларак тәкъдим ителә.

***Галимова Ольга Николаевна,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 39

*Р.Ф. Сафиуллина*

# «МИЛЛИ-МӘДӘНИ МИРАСЫБЫЗ: УДМУРТИЯ ТАТАРЛАРЫ» (Казан, 2021. 2 нче басма, 400 б.) КИТАБЫ ТУРЫНДА

Статья посвящена второму изданию сборника «Национально-культурное наследие: татары Удмуртии», изданного Институтом языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. В книге собраны научно-популярные труды ученых Института, написанные по материалам научных экспедиций на территорию Удмуртии в 2012 г. и более раннего периода. В статье рассказывается о каждом из трудов, вошедших в сборник. Также уделяется внимание тематико-смысловым особенностям и структуре книги. Научной новизной данной статьи является анализ каждого труда, вошедшего в книгу «Национально-культурное наследие: татары Удмуртии». Выясняется, в какой степени статьи раскрывают тему «национально-культурное наследие татар Удмуртии». В то же время, высказано мнение об актуальности книги в целом, о ее успешном творческом и научном решении. В статье проходит мысль о важности возвращения народу исконно народного. По мнению автора, второе издание книги еще раз доказывает, что татарский народ является единой и неделимой нацией, имеющей богатую историю и национально-культурное наследие.

**Ключевые слова:** Татары Удмуртии, ИЯЛИ имени Г. Ибрагимова, научная экспедиция, наследие, второе издание.

The article is devoted to the second edition of the collection «National and cultural heritage: Tatars of Udmurtia» published by the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan. The book contains popular scientific works of the Institute's scientists, written based on the materials of scientific expeditions to the territory of Udmurtia in 2012 and earlier. The article describes each of the works included in the collection. Attention is also paid to the thematic and semantic features and structure of the book. The scientific novelty of this article is the analysis of each work included in the book «National and Cultural Heritage: Tatars of Udmurtia». The article examines to what extent the articles cover the topic «national and cultural heritage of the Tatars of Udmurtia». At the same time, an opinion was expressed about the relevance of the book, about its successful creative and scientific solution. The article reflects the idea of the importance of returning to the people the original folk. According to the author, the second edition of the book proves once again that the Tatar people are a single and indivisible nation with a rich history and national and cultural heritage.

**Keywords:** Tatars of Udmurtia, IYALI named after G. Ibragimov, scientific expedition, heritage, second edition.

Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты 2009 елдан Россиянең татарлар күпләп яшәгән аерым төбәкләренә даими рәвештә комплекслы фәнни экспедицияләр оештыра. Мондый экспедицияләрдә татар теленең

диалектлары, халык иҗаты, археография, милли музыкаль мирас һәм тасвирый сәнгать өлкәләренә караган материаллар туплана, өйрәнелә, һәрьяклап анализлана һәм китап булып дөньяга чыга. Татарлар яшәгән төбәкләргә багышланган әлеге китаплар сериясе «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» дип атала. Бу сериядәге китапларның беренче басмасы үз укучысын тиз тапты һәм матбугатта уңай бәя дә алды [Мөхәммәтҗанова, б. 172–174].

Мәгълүм булганча, быел Бөтенроссия халык санын алу кампаниясенең чираттагысы үткәрелә. Шушы уңайдан 2021 елда «Милли-мәдәни мирасыбыз» циклына кергән китапларның тулыландырылган, төзәтелгән яңа басмалары нәшер ителде. Әлеге сериянең икенче басмасы бишенче китапта Удмуртия Республикасының Балезино, Глазов, Юкамен районнарында көн күрүче милләттәшләребезнең тарихын, тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, мәдәниятен, халык иҗатын, кульязмаларын барлау-тикшерү нәтиҗәләре чагылыш таба.

Китап татарча-русча кереш мәкалә белән ачыла. Авторы – Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ директоры, филология фәннәре докторы Ким Миңнуллин. Мәкалә Удмуртия татарлары яшәгән авыллар һәм фәнни экспедицияләр тарихыннан мәгълүмат бирә, шулай ук экспедицияләр нәтиҗәләре һәм китапның структурасы белән таныштыра [Милли-мәдәни мирасыбыз..., 2021, б. 6–25]. 1950 елларда ук Институт Удмуртия Республикасына экспедицияләр оештырган. 2012 елның июнендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре – этнографлар, археографлар, фольклорчылар һ.б. белгечләр – яңадан Удмуртия Республикасы районнарына комплекслы экспедициягә китә (экспедициянең җитәкчесе – филология фәннәре кандидаты И.И. Ямалтдинов) [Милли-мәдәни мирасыбыз..., 2021, б. 22].

Татарстанның Халыклар дуслыгы йорты директоры Ирек Шәриповның **«Һәр төбәкнең үз сере»** мәкаләсеннән мәгълүм булганча, Удмуртия республикасында хәзерге вакытта 100 мең чамасы татар бар. Милләттәшләрнең «14 проценты гына авыл җирлегендә яши, ә 86 проценты... шәһәр мохитендә, башка милләтләр арасында гомер кичерә. Шуңа да карамастан, Удмуртия татарларының телне, динне, гореф-гадәтләрне кадерләп саклаулары, алардагы миллилек хисе бик күпләргә үрнәк итеп куярлык» [Милли-мәдәни мирасыбыз..., 2021, б. 26], ди автор якташлары турында.

Тарих фәннәре докторы, археограф Марсель Әхмәтҗанов эзләнүләреннән күренгәнчә, Удмуртия татарларының ерак бабалары Болгар дәүләтендә яшәгән, алар төньяктагы халыклар белән сәүдә мөнәсәбәтләрендә торган Ахметзянов, с. 87]. Галим бу хакта «**Тел, гадәт вә әхлак алмашып (**Татар һәм удмурт тарихыннан уртак сәхифәләр)» дип аталган мәкаләсендә дә яза. Удмуртиянең кайбер авылларында яшәүче татарлар бередәге удмуртлар һәм бисермәннәр белән аралашып көн күргәннәр (мәсәлән, кыз алыша, кыз бирешә торган булганнар). «Болгарлар белән бәйле 1323 елгы кабер ташы,

Бигер-Шай каберлекләре кебек тарихи истәлекләр XIV гасыр башында Чыпца буйларында татар авыллары булганлыгы турында сөйли. Гасырлар узган саен әлеге фикерләрне раслый торган фактлар өстәлә бара», – дип яза мәкалә авторы [Милли-мәдәни мирасыбыз..., 2021, б. 31]. Нократ елгасы буйларында яшәүче татарларның иң борынгы тарихы Карабәккә барып тоташа. Аның нәселеннән булган Касыймовлар, Дәүләтьяровлар, Мөрсәлимовлар, Байкиевлар, Апачевлар, Янчуриннар, Хуҗасәетовлардан калган борынгы шәҗәрәләр, аларга урыс патшалары биргән ярлык-грамоталар турында да әйтелә. Андый документларда милләттәшләребез тарихы да шактый тулы чагылыш таба.

«Милли-мәдәни мирасыбыз: Удмуртия татарлары» китабының икенче басмасында археограф Айдар Гайнетдинов мәгълүматларына [Милли-мәдәни мирасыбыз..., 2021, б. 78] караганда, 2012 елда Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ оештырган комплекслы экспедиция Балезино, Кистем, Дасис (Засеково), Паюра, Татар Парҗысы, Палагай, Уръякала, Әхмәди, Иманай, Пүчинкә авылларын колачлаган. Галим фикеренчә, Габделбәр Кәчимовның 1910 елда үз кулы белән язган дәфтәре кыйммәтле табыш булып саналырга хаклы. Шулай ук 1903–1904 елларда Палагай авылы елъязмасы да игътибарга лаек. Елъязмада авыл кешеләренең көнкүреше, ел әйләнәсендәге мәшәкатьләре: чәчү, урып-җыю, һава торышы, җыеп алынган уңышка кадәр теркәлеп барган. Элек сабан туйларын яз көне, апрель аенда уздырганнар. Мәсәлән, «1904 елда Тегермән, Тутай авылларында 19 апрельдә дүшәнбе көн, Палагай авылында 21 апрельдә чәршәмбе көн, Кечкенә Палагай авылында 22 апрельдә кече атна көн (пәнҗешәмбе) үткәрелгән. 23 апрельдә инде сабан чәчәргә чыкканнар». М. Әхмәтҗанов фикеренчә, мондый төр язулар дәүләтчелек сакланганда теркәлгән, халкыбыз аларны дәүләтчелеген югалтканнан соң да тырышып дәвам иткән [Милли-мәдәни мирасыбыз..., 2021, б. 96].

Удмуртия республикасында Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ галимнәре ачыклаган кыйммәтле табылдыклар арасында Шәехбаба хакындагы мөнәҗәтләр, имам Газалинең сирәк басмалардан саналган «Әййүһәл-вәләд», Габдулла Ушмавиның Татар Парҗысы авылы турындагы язмалары, татар шәҗәрәләре, һ.б. уникаль хезмәтләр бар, алар турында җыентыкта шактый мәгълүмат бирелә.

Диалектологлар Дөрия Рамазанова һәм Миңнира Булатова мәкаләсеннән күренгәнчә, Удмуртиядәге милләттәшләребезнең теле татар әдәби теленнән аерылып тора. Төбәк татарларына Нократ сөйләше хас [Милли-мәдәни мирасыбыз..., 2021, б. 97]. Җирле сөйләш вәкилләре барлыгы кырыкка якын авылда – Нократ елгасының бер тармагы булган Чыпца елгасы бассейнында яши. Нократ сөйләшендә әдәби телдә булмаган диалекталь сүзләр очрый. Аларның күпчелеге төрки-татар сүзләре, шулай ук башка телләрдән кергән алынмалар да байтак.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология

фәннәре докторы Флера Баязитованың «Чишмә күзләр күп бездә» (Урта диалектның нократ сөйләше)» мәкаләсендә нократ сөйләшенең фонетик, грамматик, лексик һ.б. үзенчәлекләренә анализ ясала. Шулай ук милли йолаларны, гореф-гадәтләрне тасвирлаганда да җирле сөйләш үрнәкләрен очратабыз. Алар кеше тормышының башыннан ахырына кадәр булган барлык вакыйгаларны да колачлавы, шул ук вакытта җирле сөйләш үзенчәлекләренең барлык нечкәлекләрен саклавы белән әһәмияткә ия.

Китапта Удмуртия татарларына хас гомуми мәгълүматтан тыш, аерым татар авыллары турындагы мәгълүматка да байтак урын бирелгән. Мәсәлән, төбәктәге иң зур татар авылы Кистемдә хәзерге вакытта 300 дән артык хуҗалык бар, анда 805 кеше яши. Авыл элек-электән бу якта яшәүче татарларны берләштереп торган рухи мәркәз ролен уйнаган. Авылларда үткәрелә торган бәйрәмнәр, йолалар, әлегәчә саклаңган күркәм гореф-гадәтләр хакында фольклорчы, филология фәннәре докторы Илсөяр Закированың «Тәгәри ките йомгагым» мәкаләсе игътибарга лаек [Милли-мәдәни мирасыбыз..., 2021, б. 204]. И. Закирова фольклор үрнәкләрен фәнни структуралаштырган, жанрлар буенча бүлеп урнаштырган: «Мифологик образлар турындагы ышанулар», «Им-том, магия, бала багу белән бәйле ышанулар», «Риваять-легендалар, сөйләкләр» һ.б.

Басманы әзерләгәндә хәзерге экспедиция материалларына гына түгел, элеккеге эзләнүләргә дә зур әһәмият бирелә. Димәк, Институт галимнәре буыннар бәйләнешен һәм фәнни тикшеренүләрдәге эзлеклелекне сакларга омтыла. Мисалга, басмада фольклорчы галим, филология фәннәре докторы Хуҗиәхмәт Мәхмүтовның 1956 елгы фольклор экспедициясеннән **«Үткәннәргә кайту»** дип аталган көндәлеге [Милли-мәдәни мирасыбыз..., 2021, б. 352], шулай ук фольклорчы галим, филология фәннәре кандидаты Ленар Җамалетдиновның **«Җырлы төбәк (**Удмуртия татарларының халык иҗаты)**»** мәкаләсе [Милли-мәдәни мирасыбыз..., 2021, б. 219] урнаштырылган.

Фольклор үрнәкләреннән җыентыкта Удмуртиядә яшәүче татарлардан язып алынган күпсанлы сюжетлы һәм кыска җырлар, әкиятләр, мәкаль-әйтемнәр һ.б. китерелгән. Удмуртия татарларының гаять бай музыкаль фольклорга ия булуы Эльмира Каюмованың **«Песни живут дольше века»** мәкаләсендә дә [Милли-мәдәни мирасыбыз..., 2021, б. 243] конкрет мисаллар белән исбатлана. Төбәк татарлары халык җырларын яратып башкара һәм хәтерендә саклый. Бәетләр, мөнәҗәтләр кебек, көйләп әйтелә торган тезмә жанр үрнәкләренә дә китапта зур урын бирелә.

Җыентыкның шактый өлешен җирле татарларның тасвирый-гамәли сәнгатенә багышланган мәкаләләр алып тора. Монда халыкның кием-салым, текстиль, савыт-саба, йорт интерьерын бизәве, үзгә милли орнаментлы предметлар, аларны эшләү ысуллары, гомумән, тасвирый-гамәли сәнгать һәм һөнәрчелек киң планда яктыртыла. Милли архитектура үзенчәлекләре, аеруча, йорт салу һәм

агач эшкәртү сәнгате һ.б. турында тикшеренүләр бай һәм эчтәлекле. Людмила Шкляеваның **«От колыбели до крыльев мельницы** (Искусство резьбы по дереву у татар,проживающих в районе реки Чепца)» [Милли-мәдәни мирасыбыз..., 2021, б. 321]; Илүсә Фәрахованың **«Изба красна углами»** [Милли-мәдәни мирасыбыз..., 2021, б. 243]; Дания Нуртдинованың **«Родина мастеров»** дип аталган [Милли-мәдәни мирасыбыз..., 2021, б. 243] күләмле мәкаләләре – шундыйлардан. Әлеге һәм башка фәнни-популяр язмаларның оригиналда – Татарстанның ике дәүләт телендә бирелүе китапның уңышы дип санала ала, чөнки татарча-русча китапны укучылар аудиториясе тагын да киңрәк.

«Милли-мәдәни мирасыбыз: Удмуртия татарлары» җыентыгының икенче басмасында Удмуртия авылларында гына түгел, шәһәрләрдә яшәүче татарлар турында да мәгълүмат бар [Милли-мәдәни мирасыбыз..., 2021, б. 379]. Удмуртия Республикасында яшәүче милләтләр арасында татарлар сан ягыннан өченче урында тора, ә милләттәшләребезнең күпчелеге (чама белән 70 мең кеше) Ижауда гомер сөрә, шулай ук Сарапул, Глазов, Можгада һ.б. яши. Удмуртия татарларының үткәне һәм бүгенге проблемалары турындагы язмаларны Ижауда чыга торган «Яңарыш» газетасы даими яктыртып бара. Шәһәр татарлары милли-мәдәни мохиттә яшәү, милли чаралар үткәрү мөмкинлегенә дә ия [Милли-мәдәни мирасыбыз..., 2021, б. 384].

Шулай итеп, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тикшеренүләрен туплаган яңа басмага тарих-археография, фольклористика, диалектология, этнография, сәнгать белеме буенча мәкаләләр, экспедициядә тупланган милли-мәдәни ядкярләр үрнәкләре кергән. «Милли-мәдәни мирасыбыз: Удмуртия татарлары. (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән)» китабына шушы төбәктәге татарларның динен, телен саклап яшәргә омтылуы, җирле осталарның, халык талантларының үз хезмәте белән тормыш-көнкүрешләрен матурлавы, иҗат җимешләре белән халкыбызның милли-мәдәни мирасы хәзинәләренә зур өлеш кертүе хакындагы язмалар эчтәлекле һәм мәгълүматлы. Халыктан җыеп алган милли-мәдәни мирасның кире халыкка кайтарылуы гаять мөһим. Әлеге китап – Институт галимнәренең бу эшне дистә еллар буена намус белән башкарып килүенә ышанычлы бер дәлил.

Бөтенроссия халык санын алу кампаниясе алдыннан әлеге басма аеруча актуаль һәм ул милләтебезнең бердәм һәм бүленмәс, зур, бай тарихка ия халык булуын тагын бер кат раслый. Удмуртиядә көн күрүче татарларның үткәне һәм бүгенгесе хакында шактый тулы фәнни мәгълүмат бирә торган бу китап шушы төбәк халкы өчен генә түгел, башка регионнарда яшәүче милләттәшләребез дә, шулай ук төрки халыклар, бигрәк тә төрки илләр галимнәре өчен дә кызыклы булыр.

Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты нәшер иткән «Милли-мәдәни мира-

сыбыз: Удмуртия татарлары. (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән)» җыентыгының икенче басмасы фәнни-популяр тел белән язылган, бай фотоматериал белән иллюстрацияләнгән. Ул киң катлау укучыга тәкъдим ителә.

**Әдәбият**

*Ахметзянов М.* Татарская археография. Отчеты о результатах археграфических экспедиций: 1972–2010 гг. Ч. 2. Казань, 2011. 180 с.

*Генинг В.Ф.* Археологические памятники Удмуртии. Ижевск: Удмурткнигоиздат, 1958. – 192 с.

Милли-мәдәни мирасыбыз: Удмуртия татарлары. Казан, 2013. 1 нче басма. 384 б. (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән; бишенче китап).

Милли-мәдәни мирасыбыз: Удмуртия татарлары. Казан, 2021. 2 нче басма. 400 б. (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән).

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Милли-мәдәни мирасыбыз: Удмуртия татарлары// ФәнниТатарстан. 2014. № 2. Б. 172–174.

***Сафиуллина Рузия Фәһим кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

# Н.М. ЙОСЫПОВАНЫҢ «XX ГАСЫРНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫ ТАТАР ШИГЪРИЯТЕ: ТРАДИЦИЯЛӘР ҺӘМ ЯҢАЧАЛЫК» (Казан: «Школа» редакция-нәшрият үзәге, 2021. 296 б.) КИТАБЫНА БӘЯЛӘМӘ

Хәзерге татар поэзиясен узган гасыр шигърияте белән бәйләп, киң җәмәгатьчелеккә даими рәвештә нәзари-тәнкыйди фикер җиткерә баручы әдәбият галимнәре арасында филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты профессоры Нурфия Йосыпованың хезмәтләре аерым урында. 2002–2021 еллар аралыгында галимәнең татар шигъриятенә этрафлы гыйльми анализ тәкъдим иткән 5 монографиясе, урта һәм югары мәктәп өчен 26 санда уку-укыту ярдәмлеге дөнья күрде. Н. Йосыпова – «Габдулла Тукай» энциклопедиясе (2016), сигез томлык «Татар әдәбияты тарихы» авторларының берсе. Соңгы елларда гына профессор әдәбият гыйльмиятенә шигъриятне нәзари һәм тәнкыйди яссылыкта бәяләгән өч монография бүләк итте (*Юсупова Н.М.* Система образов-символов в татарской поэзии первой половины XX века. Казань: Ихлас, 2018. 312 с.; *Юсупов А.Ф., Юсупова Н.М.* XX гасырның беренче яртысы татар поэзиясе: стиль һәм образлы сурәт тудыру үзенчәлеге. – Казан: «Школа» редакция-нәшрият үзәге, 2020. 172 б.; *Йосыпова Н.М.* XX гасырның икенче яртысы татар шигърияте: традицияләр һәм яңачалык / Н.М. Йосыпова. Казан: «Школа» редакция-нәшрият үзәге, 2021. 296 б.).

«XX гасырның икенче яртысы татар шигърияте: традицияләр һәм яңачалык» (Казан, 2021) хезмәтендә әдәбият галиме XX гасыр татар поэзиясенә нәзари күзәтү ясый, бер гасырлык шигърияткә структураль-семиотик анализ яссылыгында гыйльми бәя тәкъдим итә.

Фәнни монографиянең «XX гасырның беренче яртысы татар поэзиясе: традицияләр һәм яңарыш нигезләре» дип исемләнгән беренче бүлегендә галимә тарафыннан милли поэзиянең алты дистә еллык дәверенә этрафлы күзәтү урын алган. Гасыр башы шигърияте хакында фикер йөрткәндә, университет профессоры Й. Акчура, Г. Сәгъди, Г. Гобәйдуллин, Җ. Вәлидиләрнең шул чорда төрле басмаларда дөнья күргән нәзари-тәнкыйди карашларын нигез итеп ала, күтәрә, нәтиҗә ясый. «XX йөз башы татар поэзиясендәге күп үзгәрешләр шәхес концепциясе алмашынуга бәйле» (7 б.) икәнлеген бәяләгәндә, Г. Тукай, М. Гафури, Н. Думавиларның мәгърифәтчелек рухы белән сугарылган шигъриятендә «татар халкының рухи юлбашчысы булып торырлык әдип» образы бирелеше игътибарга алына. Мәгърифәтчелек күтәргән идеяләрнең Г. Рәшиди, Я. Мамишев, Г. Гайнуллин-Чокрый, Х. Исхакый, К. Хаммадов поэмаларында урын алуы билгеләп үтелә. Профессор Н. Йосыпова карашынча, милли шигъриятнең бу дәверендә «жанр эзләнүләре аеруча лиро-эпик төрдә колач җәя» (27 б.). Романтик иҗат принципларының лиро-эпикада көчле яңгыраш алуын дәлилләү өчен, фольклор мотивларыннан, дини сюжетлар кулла-

нылышы ягыннан Ф. Бурнаш, Б. Мирзанов, К. Юлдаш, Д. Гобәйди, Х. Исхакый поэмаларына мөрәҗәгать ителә. Бу урында галимәнең «XX гасыр башында мифологик сюжетларны яңарткан яки әсәр материалында яңа миф тудырган, матурлык концепциясенә таянып, милли яшәешне яңарту омтылышын алга куйган бер төркем модернистик» поэмаларга, аерым алганда, Б.Мирзановның «Җен туе», М. Гафуриның «Адәм вә Иблис», Һ. Такташның «Газраилләр», Г. Сөнгатинең «Хозер», Н. Думавиның «Шәрык даһие», шулай ук төрки-татар мифларына мөрәҗәгать итеп язылган И. Шаммаси, Г. Сөнгати, Г. Харис әсәрләренә анализлары игътибарга лаек. Анализлар нәтиҗәсе буларак «модернистлар иҗатында поэманың традицион кануннардан баш тарткан антижанр формасы барлыкка килүе», «дини-дидактик эчтәлекле сюжет дөньяви фикерләрне җиткерүгә буйсындырылуы» (237 б.) хакында нәзари карашлар дәлилләнә. Фикерләрне үстереп, шигърияттә нәсер, баллада, сонет жанрларының активлашуын раслау максатыннан Г. Рәхим, Г. Сөнгати, Ф. Әмирхан әсәрләренә бәя тәкъдим ителә.

1920–1950 еллар татар поэзиясе тарихында үзенчәлекле чор буларак бәяләнә. Галимә С. Сүнчәләй, Ф. Бурнаш, В. Җәлал, С. Кудаш, Т. Ченәкәй һ.б. иҗатларында яңгыраш алган фикерләргә таянып, «егерменче еллар татар шигъриятендә әле XX гасыр башы татар поэзиясе традицияләрен дәвам итү яки поэзияне шул нигездә яңарту омтылышы көчле саклана» (32 б.), дигән нәтиҗә ясый. Әдәбият галиме Д.Заһидуллина карашларыннан этәрелеп, Н. Йосыпова бу чорда «форма эзләнүләре аша трансформация кичергән» (32 б.) Х. Туфан, Г. Кутуй, Һ. Такташ, К. Нәҗми һ.б. авторлар иҗатларына туктала, аерым алганда, Х. Туфанның «Татарстанда» поэмасына, «тартышчы» геройны тәкъдим иткән «Сынган кашлар» шигыренә һ.б. әсәрләренә, Г. Кутуйның «Көннәр йөгергәндә» дип исемләнгән футуристик, К. Нәҗминең «Өермәләр» җыентыкларына имажинистик эзләнүләр ноктасыннан тирән фәнни бәя бирә. Галимәнең егерменче елларда хөкем сөргән гыйсъянчылык фәлсәфәсенә мөнәсәбәтле фикерләре игътибарга лаек. Г. Халитнең «гыйсъянчы герой XX йөз башы бунтарь шәхесеннән аерыла» дигән карашын, Н. Йосыпова «татар әдәбиятындагы гыйсъянчы геройның көрәш мәйданы үзгәрә» (42 б.), дип үстерә, бу яссылыкта Һ. Такташ, К. Нәҗми, М. Җәлил, Х. Туфан шигъри текстлары бәяләнә. Профессор 1920 елларның урталарыннан соң татар поэзиясендәге авангард эзләнүләрнең сүлпәнәюенә бәйле карашларын җиткергән урында Һ. Такташның «Иҗадиятем хакында» дип исемләнгән программ мәкаләсен шәрехли һәм «...Һ. Такташ татар поэзиясе өчен үзгә, интонацион шигырь – сөйләү шигырен мәйданга чыгара» (44 б.), дигән нәтиҗә ясый. Утызынчы еллар шигъриятенә бәя биргән вакытта да Һ. Такташның «Әдәбият нинди булырга тиеш» дип исемләнгән мәкаләсенә мөрәҗәгать итеп, «шушы чордан Такташ әдәбияттагы форма эзләнүләрен сыйнфый көрәштән читләшү буларак тәнкыйтьли башлый» (51 б.), дип, чор йөзенә төгәл, анык бәя теркәп куя. Шул рәвешле, хезмәтнең эчтәлеген үтәли сызучы тагын

бер гыйльми аспект аермачык: галимә һәрдаим әдәби барышта аерым иҗатчы шәхесе тоткан урынны ассызыклап, билгеләп бара. 1934–1941 еллар аралыгы белән тамгаланган утызынчы еллар татар поэзиясендә социалистик реализм агымына мөнәсәбәтле үзенчәлекләрне аерып куйган хәлдә, әдәбият галиме Ә. Фәйзинең «яңа идеологиянең зыялылар тормышында чагылышын үзәккә куйган» (56 б.) «Флейталар» поэмасын, С. Хәкимнең «Тукайга багышланган шигъриятқә эчтәлек һәм форма яңалыгы алып килгән» (57 б.) мәгълүм поэмаларын, «Совет фольклорын җыйнарга чынлап керешергә» мәкаләсен язып, либреттолар тәкъдим иткән М. Җәлил әсәрләрен анализлап һәм ассызыклап үтә. «Лирик герой концепциясенең үзгәреш кичерә башлавы» (64 б.) хакында һәм «халык авыз иҗатыннан килгән образларны, символик образ-детальләрне куллана башлау... халык җырларына хас яңгыраш һәм вәзен формаларын, структураны яңартырга мөмкинлек бирә» (64 б.) дигән нәтиҗә ясап, галимә «агымдагы чор татар поэзиясенең идеологик кысаларга сыешып бетмәвен» (65 б.) дәлилли. Бөек Ватан сугышы чоры татар поэзиясен анализлап, Н. Йосыпова 1920–1930 елларда башланган яңарышның дәвам иттерелүе, сугыштан соңгы еллар татар поэзиясенең «ХХ гасырның алтмышынчы елларында булачак өченче «шартлауга» җирлек әзерләвен ассызыклый (86 б.).

Фәнни монографиянең икенче бүлегендә 1960–1980 еллар татар поэзиясе эчтәлек һәм форма өлкәсендә эзләнүләр ноктасыннан бәяләнә. Казан университеты профессоры Н. Йосыпова киң җәмәгатьчелеккә классик әдипләребез Х. Туфан, С. Хәким, И. Юзеев, Р. Харис, Р. Фәйзуллин, М. Әгъләмов, Зөлфәт иҗатларына саллы нәзари бәя тәкъдим итә. Әйтергә кирәк, соңгы биш-җиде елда әдәбият гыйльмиятендә милли поэзиянең әлеге дәверенә академик Д. Заһидуллина тарафыннан этрафлы анализ бирелде (Заһидуллина Д.Ф. 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 383 б.). Н. Йосыпова әдәбият галимнәренең хезмәтләренә һәрдаим мөрәҗәгать итә, библиографиядә йөзгә якын фәнни хезмәткә сылтама бар. Монография авторы бу бүлектә остазлары академиклар Т. Галиуллин, Д. Заһидуллина хезмәтләреннән этәрелеп, яңа фәнни ачышлар, бу чор поэзиясен анализлауның үзенчәлекле юлын тәкъдим итә. Рус әдәбияты галимнәре Ю. Богомолов, И. Кукулин, Н. Лейдерман, А. Бочарев һ.б.ның әдәбиятның бу дәверенә мөнәсәбәтле фикер-карашларын өйрәнеп, галимә милли поэзиябезнең гаҗәеп тирән үзенчәлекләрен, бөеклеген шигъри текстларны җентекләп анализлау аша ача. Профессор әдәби дәвернең яңалыгы хакындагы гыйльми карашларны үстерә, кайберләрен кайта-кайта ассызыклый. Әйтик, Г. Афзалның гражданлык лирикасында активлашкан иҗтимагый тәнкыйтьнең Ф. Яруллин, Ш. Анак, Р. Мингалим, К. Сибгатуллин шигъриятендә күтәрелүе, Х. Туфан, С. Баттал, Р. Фәйзуллин, Роберт Әхмәтҗанов, Рәшит Әхмәтҗанов, М. Әгъләмовларда көчле яңгырашы шигъри текстларны анализлап дәлилләнә. Галимә

карашынча, «авангард эзләнүләр милли шигърияттә үзенә бер дәрт белән иҗатка килеп кергән «Р. Фәйзуллиннар буыны» бер дулкынга җыя» (95 б.), «бу буын, бердән, С. Рәмиев, Дәрдемәнд иҗаты традицияләрен үстерсә, икенче яктан, милли шигърияткә рус поэзиясенең, «шаулы эстрада» вәкилләре иҗатының йогынтысы көчәя» (96 б.). Күпсанлы шигъри текстларга филологик анализ бирү барышында Н. Йосыпова «сабыр лиризмга, төгәл ритмикага беренчеләрдән булып өстенлек бирә башлаган Г. Рәхим, соңрак кушылган «салмак лириклар» Р. Мингалим, Р. Гаташ, Зөлфәт, С. Хәким, Г. Зәйнашева, К. Булатова, К. Сибгатуллин һ.б. шигъриятләрендә тематик төрлелек, «фольклор стиле», «халык авыз иҗатыннан килгән образларны, мотивларны файдалану» (98 б.) хакында нәтиҗә ясый. Галимә романтик поэзия, фәлсәфи лирика, интеллектуаль шигъриятнең үсешен бер эзлеклелектә карый. С. Сөләйманова, Ш. Анак, Ә. Баянов һәм классикларыбыз Зөлфәт, Р. Фәйзуллин һ.б. иҗаты аша эчтәлек һәм форма өлкәсендәге эзләнүләрне аерып куя, дәлилли. Т. Галиуллин карашларын үстереп, Н. Йосыпова «Х. Туфан шигърияте – 1960–1980 еллар әдәбиятында салмак лирика агымының төп үзенчәлекләрен билгеләүче иҗат» (126 б.), дип аныклап куя. Д. Заһидуллина фикерләрен дәвам итеп, галимә С. Хәким поэзиясендә «туган җирне изгеләштерү, мифлаштыру тенденциясен» (131 б.) ассызыклый, әдипнең тәнкыйди-публицистик мирасының кыйммәтен «әдәбият тарихында тирән эз калдырган шагыйрьләр мирасын барлау, әдәби процесска керткән өлешен тәгаенләп кую» (138 б.) дип тамгалый. Д. Заһидуллина, А. Даутов карашларын үстереп, Н. Йосыпова И. Юзеев шигъриятендә «кешенең Яшәешне һәм үз-үзен танып белүе, кеше гомеренең кыйммәте, кеше язмышы, яшәү мәгънәсе хакында фикерләр әйдәп баруы» (157 б.) турында нәтиҗә ясый. Р. Харисның интеллектуаль поэзиясен анализлап, шагыйрьнең татар шигъриятен яңа сыйфатлар белән баетуын дәлилли. Р. Фәйзуллинның «көнчыгыш әдәби үзенчәлекләрен иҗади үзләштереп, татар әдәби җирлегенә «яраклаштыруы», шагыйрьнең иҗади ачышлары «әдәби традицияләрнең үсешенә, фәлсәфә тирәнәюгә һәм әдәбиятара мәдәни диалогның көчәюенә дә көчле йогынты ясый» (192 б.), дигән нәтиҗәгә килә. Галимә М. Әгъләмов иҗатында яңа караш, яңа анализ юлы тәкъдим итеп, әдип шигъриятендә «милләт язмышы – шәхес язмышы – шагыйрь язмышы чылбыры»н (210 б.) аерып куя, әдипне «шигърияттә алдагы буыннарга иҗади тәҗрибәләр ясау мәйданын, чын мәгънәсендә шигъри мәктәбен калдыра» (216 б.), дип күтәрә, лаеклы төстә данлый. Зөлфәт шигъриятенә анализ белән танышканнан соң, галимәнең фикер-карашлары тирәнлеген Зөлфәтнең бер шигъри тезмәсен үзгәртеп, «Фәнни сүзем минем – саф тылсымым» дип бәялисе килә: «Үз кичерешләре аша халык язмышын җиткерә алган, милләтенең бүгенгесе һәм киләчәге өчен борчылган, кешелекнең имгәнгән яшәеш кануннарын савыктыру омтылышы белән янган шигърияте Зөлфәтнең үз мәсләгенә тугры калуын раслый» (243 б.).

Китапның өченче бүлеге «1980–2000 елларда татар поэзиясе: шигъриятне яңарту юлында эзләнүләр» дип исемләнә. Профессор, әдәбият галиме Н. Йосыпова милли поэзия мәйданына алтмышынчы елларда килеп кергән мәгърур буынның 1980–2000 еллар аралыгында да сайлаган кыйблага – шигъриятне «эчтәлек һәм форма ягыннан тирәнәйтүгә, яңарыш тенденцияләренә» (277 б.) тугры калуын, алар алып кергән яңарышның «XX йөз башында булачак әдәби-сәнгати, фәлсәфи эзләнүләргә ныклы нигез салуын» дәлилли (278 б.).

Әдәбият гыйльмияте тарихында яңа сүз булып танылачак фәнни монографиянең дәвамы буларак, галимәнең гаҗәеп талантлы хәзерге буын шагыйрьләр иҗатына, аерым алганда, Лилия Гыйбадуллина, Луиза Янсуар, Йолдыз Миңнуллина, Булат Ибраһимов һ.б. иҗатлары хакында фәнни-гыйльми сүзен ишетәсе килә.

***Гайнуллина Гөлфия Расил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан федераль университеты доценты*

УДК 81′1

*Э.Х. Кадирова*

# ЛӘЙЛӘ МӘХМҮТОВА – ТАТАР ТЕЛ БЕЛЕМЕ ТАРИХЫНДА ТИРӘН ЭЗ КАЛДЫРГАН ШӘХЕС

В научном наследии Лейли Тагировны Махмутовой, представленном трудами по грамматике, лексике и фразеологии современного татарского литературного языка, исторической диалектологии татарского языка, татарской лексикографии, татарской диалектологии, особое место занимает западный диалект татарского языка. В данной статье описывается ее научная деятельность и вклад в развитие диалектологии.

**Ключевые слова:** лингвистическая персонология, татарское языкознание, татарская диалектология, диалектная лексикография, Лейла Тагировна Махмутова.

In the scientific heritage of Leyli Tagirovna Makhmutova represented by works on grammar, vocabulary and phraseology of the modern Tatar literary language, historical dialectology of the Tatar language, Tatar lexicography, Tatar dialectology, a special place is occupied by the Western dialect of the Tatar language. This article describes her scientific activities and contributions to the development of dialectology.

**Keywords:** linguistic personology, Tatar linguistics, Tatar dialectology, dialect lexicography, Leila Tagirovna Makhmutova.

Үзенә кадәр эшләгән билгеле галимнәрнең хезмәтен лаеклы дәвам итеп, татар тел белеме фәнен яңа югарылыкка күтәргән, 25 ел дәвамында ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих (сәнгать) институтының күп тармаклы, иң эре тел секторын җитәкләгән, төрки диалектология өлкәсендә СССР күләмендә танылу алган, 150 гә якын фәнни хезмәт авторы, филология фәннәре кандидаты Ләйлә Мәхмүтова – татар тел белеме тарихында уникаль, тирән эз калдырган шәхес.

Ләйлә Таһир кызы Мәхмүтова 1925 елның 25 августында Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районы Муса авылында үз чорының актив җәмәгать эшлеклесе Таһир ага Мәхмүтов гаиләсендә дөньяга килә. Таһир ага укымышлылар нәселеннән. Аның әтисе Хәбибулла агай ике тапкыр Мәккәгә һәм Мәдинәгә хаҗ кыла. Беренче тапкыр – 17 яшендә. Хаҗдан кайтканда, ул Төркиядә туктала һәм, балдакларга язу төшереп акча эшләп, шул якларда сәяхәт кыла. Хәбибулла 35 яшендә туган авылына кайта һәм өйләнә. Ләйләнең әтисе Мөхәммәдтаһир гаиләдә унберенче бала була. Хәбибулла бабай малайларның берсен шәһәргә укырга җибәрсә, икенчесен авылда калдыра. Мөхәммәдтаһиргә Казанда белем алу бәхете тия. Ул Мөхәммәдия мәдрәсәсен тәмамлый, Казанда кала. Мөхәммәдтаһир язучылар белән аралаша: Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов белән таныш була,

«Әлислах» газетасы редакциясендә эшли. Баштарак начар почерклы язучыларның әсәрләрен күчереп язу белән шөгыльләнсә, соңрак үзе дә авыл хуҗалыгын популярлаштыру юнәлешендә мәкаләләр бастыра. Мөхәммәдтаһир Санкт-Петербург педагогика институтында читтән торып укый һәм рус-татар мәктәбе укытучысы белгечлеген ала. Ул Казанда атаклы сәнәгатьчеләр нәселеннән булган Нәгыймә Әхсән кызы Аитова белән танышып гаилә кора. Укымышлы, гарәп һәм фарсы телләрен яхшы белгән шәһәр кызы сөйгәне белән ерак бер авылга китеп бара. Бер-бер артлы 5 балалары туа. Бу елларда ире күрше авылларда укыта. Соңыннан гаилә Хвалын шәһәренә күченә. Биредә Таһир Мәхмүтов рус-татар башлангыч мәктәбен ачуга ирешә һәм пенсиягә чыкканчы анда эшли. Шәһәрдәге татарлар үз балаларын бу мәктәпкә башлангыч белем алырга җибәргәннәр. Бу Т. Мәхмүтовның педагогик осталыгы турында сөйли. Мәхмүтовлар гаиләдә татарча гына сөйләшәләр. Гаиләдәге туган телгә, туган әдәбиятка мөнәсәбәт нәкъ менә шул вакытларда ук кызда татар телен тирәнтен өйрәнүгә омтылыш уяткан булса кирәк.

Мәктәпне тәмамлаганнан соң Ләйлә Ленинград дәүләт университетының Көнчыгыш телләр факультетына укырга керә. Студент вакытында ук нык кызыксынучан Ләйлә Мәхмүтовага университетта Н.К. Дмитриев, С.Е. Малов, А.Н. Кононов, А.К. Боровков, В.М. Жирмунский кебек атаклы тюрколог-галимнәр белем бирә. Моннан тыш ул факультатив рәвештә гарәп теле һәм иранистика буенча академик И.Ю. Крачковский укыган лекцияләргә, СССР Фәннәр Академиясенең мөхбир әгъзасы А.Ю. Якубовскийның Якын һәм Урта Көнчыгыш мәсьәләләре буенча махсус курсларына йөри. Ләйлә уку барышында Сталин стипендиясе ала. Ул 1948 елда университетны кызыл дипломга тәмамлый һәм 1948–1952 елларда аспирантурада белем ала.

Ләйлә Мәхмүтова 1952 елда (вакытыннан алда) «Татар теленең касыйм сөйләше үзенчәлекләре» («Особенности касимовского говора татарского языка») темасына кандидатлык диссертациясен яклый. Бу хезмәт сөйләшләрне өйрәнүгә багышланган тикшеренүләрнең калыбы буларак бәяләнә. Аның зур күләмле, тирән эчтәлекле мәкаләләрендә һәм диссертациясендә әлеге тарихи яктан үзенчәлекле сөйләшкә караган уникаль лексик һәм фонетик тел материалы урын ала.

1952 елда Ләйлә Мәхмүтова Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына (1998 елдан – Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) эшкә урнаша. Яшь булуга да карамастан, кызыксынучан, талантлы, тирән белемле, эзләнүчән Ләйлә Таһир кызы диалектология юнәлешендә тикшеренүләрен дәвам итә. Институтта ул башта – кече фәнни хезмәткәр, 1959 елдан өлкән фәнни хезмәткәр була. 1961 елның беренче июненнән Институтта тел секторының җитәкчесе итеп билгеләнә һәм лаеклы ялга (1986 елның 31 мае) киткәнгә кадәр шул вазифаны башкара.

Ләйлә Таһир кызы Мәхмүтованың фәнни эшчәнлеге киңкырлы. Татар диалектологиясе, лексикографиясе, лексикологиясе, тарихи

диалектология, татар теле тарихы өлкәләрен өйрәнүгә зур өлеш керткән галимәнең фәнни мирасында татар сөйләшләре аерым урын алып тора. Ул аларны өйрәнүгә кырык елга якын гомерен багышлый. Диалектологиянең татар тел белеменең мөстәкыйль тармагы дәрәҗәсенә күтәрелүендә Ләйлә Мәхмүтованың өлеше бик зур. 1960–1970 елларда Ләйлә Таһир кызы мөдирлек иткән тел секторының берничә хезмәткәреннән торган төркем киң территориядә таралган татар сөйләшләрен җентекләп өйрәнүгә керешә. 1954–1957 елларда Ләйлә Мәхмүтова җитәкчелегендә Башкортстанның төньяк-көнбатыш районнарына берничә экспедиция оештырыла. Л.Т. Мәхмүтова җыелган материалларга һәм архив чыганакларына нигезләнеп, үзенең «О татарских говорах северо-западных районов Башкирской АССР (по материалам экспедиции 1954–57 гг.)» исемле күләмле мәкаләсен бастыра [Махмутова, 1962]. Ул анда бу төбәктә яшәүчеләрнең теле татар әдәби теленә бик якын булуын ассызыклый. Автор, татар диалектологлары арасында беренче булып, «башкорт», «типтәр», «мишәр» этнонимнарын тарихи-лингвистик яктан өйрәнү зарурлыгын ассызыклый.

Галимәнең күпсанлы мәкаләләрендә татар сөйләшләренә нисбәтле кыйммәтле материаллар, кызыклы фактлар урын ала һәм алар татар тел белемендә, татар диалектологиясендә булган аерым мәсьәләләрне ачыклауда зур әһәмияткә ия. Аның күп мәкаләләре көнбатыш диалект сөйләшләрен өйрәнүгә карый. «Краткие заметки о хвалынском говоре мишарского диалекта татарского языка» (1966), «К монофтингизации дифтонгов в мишарском диалекте татарского языка» (1973), «Некоторые наблюдения над лексикой мишарских говоров (к мишарско-мордовским заимствованиям)» (1976), «Формы прошедшего времени в мишарском диалекте татарского языка» (1976), «О характере и некоторых типах русских заимствований в мишарском диалекте татарского языка» (1978), «Некоторые материалы по лексике мишарского диалекта татарского языка (тюркский пласт)» (1979), шулай ук озак еллар бергә эшләгән хезмәттәше Наҗия Борһан кызы Борһанова белән берлектә язылган «К вопросу об истории образования татарских диалектов и говоров» (1962), «О диалектном членении татарского языка» (1962), «Диалекты татарского языка» (2010) мәкаләләрендә сөйләшләрне бүлү һәм классификацияләүнең теоретик мәсьәләләре, аларны тикшерү һәм тасвирлау методлары, диалект материалларын фәнни шәрехләү принциплары карала, шулай ук сөйләшләрне чагыштырып анализлау ысуллары, комплекслы якын килү (ягъни анализлау вакытында башка чиктәш фәннәр буенча мәгълүматларны да куллану) мөмкинлекләре өйрәнелә.

Галимә тарихи аспектта телне һәм шул телдә сөйләшүчеләрне (носители языка) өйрәнүдә диалектларга мөрәҗәгать итүнең әһәмиятен һәрдаим ассызыклый. Кызганыч, татар язма истәлекләренең күпчелек өлеше безнең көннәргә кадәр килеп җитми. Л. Мәхмүтова моны билгеләп, диалектологик мәгълүматларның шушы шартларда

сөйләм теле һәм аның язма әдәби варианты тарихын өйрәнүдә мөһим чыганак булуын әйтә. Галимә тарихи чыганаклар аша тел (бигрәк тә аның диалектлары) үсешен күзәтү мөмкинлеген «Татарский язык в его отношении к древнеписьменному памятнику Codex Cumanicus по данным лексики: краткий анализ и приложение» [Махмутова, 1982], «О некоторых татарско-куманских параллелях (по материалам фонетики и грамматики)» [Махмутова, 1985, с. 117–142] кебек зур күләмле мәкаләләрендә ача. Ул аларда кыпчак (Codex Cumanicus буенча) һәм татар телләре арасындагы фонетика һәм грамматика өлкәләренә караган охшашлыкларны анализлый.

Экспедиция материалларына нигезләнеп язылган мәкаләләр (кереш характерындагы мәкаләләр, тикшеренү мәкаләләре, текстлардан үрнәкләр) арасында Л.Т. Мәхмүтованың Н.Б. Борһанова белән берлектә язылган «К вопросу об истории образования и изучения татарских диалектов и говоров» хезмәтендә урта һәм көнбатыш диалектларны өйрәнү тарихы, әлеге ике диалектның фонетика, морфология өлкәләрендә дифференциаль билгеләре китерелә. Мәкаләдә Казанда үткәрелә торган диалектологик өйрәнүләргә куелган теоретик таләпләр дә урын ала. Шул ук җыентыктагы «Основные характерные черты мишарских говоров на территории Пензенской области» [Махмутова, 1962] дигән тирән эчтәлекле мәкаләдә бу төбәктә яшәгән татарларның теленә караган үзенчәлекләр тупланган материалларның телен ачык күзалларга мөмкинлек бирә. Автор әлеге мәкаләсендә экспедицияләрдә тупланган бай тел материалын фәнни тасвирлау бурычын куя. Анда сөйләшнең фонетик һәм морфологик үзенчәлекләренә зур урын бирелә. Төрки телләр буенча күренекле галим, филология фәннәре докторы Ә.Р.Тенишев бу җыентыкларга язган рецензиясендә Казанда диалектологик тикшеренүләрнең киң колач белән үсүен ассызыклый, хезмәттәге барлык мәкаләләргә карата үз фикерен белдерә, аларны югары бәяли. Пенза өлкәсендә туып үскән галимә Л.Т. Мәхмүтованың җыентыктагы 37 битлек «Основные характерные черты мишарских говоров на территории Пензенской области» мәкаләсенә тәфсилле анализ ясый, ә «Некоторые наблюдения над лексикой касимовского говора татарского языка» мәкаләсендә [Махмутова, 1962] «яңа лексик материал китерелгәнлеген һәм аның диалектологик сүзлек өчен кыйммәтле чыганак булуын» әйтә [Тенишев, 2006, с. 68].

Барлык төрки телләр диалектларының лексик һәм фонетик-грамматик төзелешен бер юнәлештә тикшерүнең аерым әһәмиятен исәпкә алып, Тюркологлар комитеты төрки телләр диалектларын өйрәнүнең кыскача схемасын эшләүне Л.Т. Мәхмүтовага йөкли. Авторның әлеге хезмәте («Краткая схема описания тюркских диалектов») «Советская тюркология» журналында басылып чыга [Махмутова, 1983].

Л.Т. Мәхмүтованың 1978 елда Мәскәүдә «Фән» нәшриятында басылган «Опыт исследования тюркских диалектов: мишарский диалект татарского языка» монографиясе – аның капиталь хезмәте

[Махмутова, 1978] һәм ул классик тикшеренү статусына ия. Китапта, күп кенә тарихи һәм архив чыганаклары аша, көнбатыш диалект вәкилләрен күчереп утырту юнәлешләре, авылларның килеп чыгышы турында, аларның элек яшәгән урыннарда калган татарлар белән генетик бәйләнешләре хакында фикерләр урын ала. Автор аларны үзе туплаган тел материаллары белән үреп бирә. Галимә көнбатыш диалектның фонетикасы һәм морфологиясен татар әдәби теле белән чагыштырып, тирәнтен анализлый. Өстәмә чагыштырма материал сыйфатында башка кардәш һәм хәтта кардәш булмаган теллләрдән дә мәгълүматлар җәлеп ителә. Хезмәткә галимнәр тарафыннан бүген дә югары бәя бирелә.

Ләйлә Мәхмүтова татар диалектологиясе ирешкән уңышларны популярлаштыру, киң масса укучыларга җиткерү эшенә дә сизелерлек өлеш кертә. Галимә – «Татар диалектологиясе буенча материаллар» дип аталган 9 томлы хезмәтнең (1955, 1962, 1974, 1976, 1978, 1983, 1988, 1989, 1990) редакторы һәм төзүчесе. Тупланган материалның киңлеге һәм күптөрлелеге безгә татар авылларында яшәгән буынның тере сөйләмен җиткерә, аларның дөнья картинасын күз алдына китерергә мөмкинлек бирә, чөнки анда халыкның традицион тамашалары, милли стереотиплар, иске көнкүреш детальләре һәм шул еллар крестьян тормышы чынбарлыгы үзенчәлекле үрелеп бара. Бу хезмәтләр диалект системасының фонетик, грамматик һәм лексик үзенчәлекләре күзлегеннән генә түгел, бәлки XX гасырның икенче яртысында татар авылы кешесенең тел шәхесе (Языковая личность сельского жителя) үзенчәлекләрен реаль гәүдәләндерү буларак та, тикшеренүчеләр тарафыннан укыла, укылыр һәм интерпретацияләнер.

1955, 1962 елларда Л.Т. Мәхмүтова тырышлыгы белән Татарстаннан читтә (Пенза, Самара, Киров өлкәләрендә, Мордовия, Удмуртия, Башкортстанда) киң таралган татар сөйләшләрен җентекләп өйрәнеп язылган мәкаләләрдән торган «Татар диалектологиясе буенча материаллар»ның беренче һәм икенче китаплары дөнья күрә.

Болардан тыш Л.Т. Мәхмүтова «Татар теленең тарихи диалектологиясе буенча тикшеренүләр» (1979, 1982, 1985) һәм күп кенә башка фәнни җыентыкларны редакцияләп басмага әзерли.

Галимнәр Л.Т. Мәхмүтова тел секторы белән җитәкчелек иткән елларны «татар диалектологиясе үсеш-үзгәрешенең иң уңышлы чоры»дип саныйлар [Рамазанова, 2014, б. 37]. Бу этапта Идел-Урал регионы татар сөйләшләренең атласын төзү һәм аны матбугатка әзерләү көнүзәк мәсьәлә булып тора. Ләйлә Мәхмүтова оештырган һәм җитәкчелек иткән күпсанлы диалектологик экспедицияләр барышында СССР халыклары арасыннан беренчеләрдән булып, диалектологик Атлас өчен материал туплана. Ләйлә Мәхмүтова – 845 авылның тел мәгълүматларын чагылдырган ике томлык «Урта Идел һәм Урал буе татар сөйләшләре Атласы»ның фәнни җитәкчесе, баш мөхәррире; «Атласка шәрехләр...»нең җитәкчесе, авторларының берсе; «Атлас...»ның Программасын төзүчеләрнең берсе, принципларын

эшләүче. «Атласка» кереш мәкалә авторларының берсе дә – Ләйлә Таһир кызы.

Л. Мәхмүтова – барыннан да бигрәк атаклы диалектолог галимә. Әмма аның лексикография, тел тарихы, лексикология тармакларындагы фәнни хезмәтләре дә татар тел белемендә лаеклы урынын тапты.

Ләйлә Таһир кызы җитәкчелегендә, фәнни редакторлыгында бастырылган, ул төзүче буларак катнашкан сүзлекләрнең саны бихисап: дүрт (1955–1959) һәм бер томлы (1969; 1971; 1984; 1985; 1991 һ.б.) «Русско-татарский словарь»; «Татар теленең фразеологик сүзлеге» (1957; 1959); «Татар теленең диалектологик сүзлеге» (1948; 1953; 1958); «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге» (1969); өч томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (1977–1981) һ.б.

Филология фәннәре кандидаты Л.Т. Мәхмүтова Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИдә эшләп, татар диалектологларының бер генә буынын тәрбияләмәгән. Л.Т. Мәхмүтова биредә үз эшенә бирелгән диалектологлар коллективын төзи алды. Аларның күбесе татар диалектологиясе өлкәсендә билгеле галимнәр булып танылды. Л. Мәхмүтова нигезләгән, өйрәнгән фәнни принциплар аның дәвамчылары, филология фәннәре докторлары Л.Ш. Арсланов, Ф.С. Баязитова, Ф.Й. Йосыпов, Д.Б. Рамазанова, филология фәннәре кандидатлары Т.Х. Хәйретдинова, З.Р. Садыйкова, Р.Р. Шәмгунова хезмәтләрендә тагын да киңрәк ачыла.

Л.Т. Мәхмүтованың фәнни мирасы төрле буын тикшеренүчеләре өчен бетмәс-төкәнмәс хәзинә булып тора.

### Әдәбият

*Бурганова Н.Б., Махмутова Л.Т.* К вопросу об истории образования и изучения татарских диалектов и говоров // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2. Казань, 1962. С. 7–18.

Махмутова Лейля Тагировна // Казанская лингвистическая школа: Книга первая: Казанская тюркская лингвистическая школа / сост. М.З. Закиев. Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. С. 218–221.

*Махмутова Л.Т.* Особенности касимовского говора татарского языка: автореф. дис. ... канд. филол. наук / Ленинградский госуниверситет. Ленинград, 1952. 10 с.

*Махмутова Л.Т.* Основные характерные черты мишарских говоров на территории Пензенской области // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2. Казань, 1962. С. 125–162.

*Махмутова Л.Т.* О татарских говорах северо-западных районов Башкирской АССР (по материалам экспедиции 1954–57 гг.) // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2. Казань, 1962. С. 57–85.

*Махмутова Л.Т.* Некоторые наблюдения над лексикой касимовского говора татарского языка // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2. Казань, 1962. С. 223–235.

*Махмутова Л.Т.* Опыт исследования тюркских диалектов: мишарский диалект татарского языка. М.: Наука, 1978. 270 с.

*Махмутова Л.Т.* Татарский язык в его отношении к древнеписьменному памятнику Codex Cumanicus по данным лексики: краткий анализ и приложе-

ние // Исследования по исторической диалектологии татарского языка. Вып. 2. Казань, 1982. С. 68–153.

*Махмутова Л.Т.* О некоторых татарско-куманских параллелях (по материалам фонетики и грамматики) // Исследования по исторической диалектологии татарского языка. Вып. 3. Казань, 1985. С. 117–142.

*Рамазанова Д.* Сүзләр дәрьясында йөзгән Ләйлә: [күренекле галимә Ләйлә Мәхмүтовага 75 яшь] // Ватаным Татарстан. 2000. 19 авг.

*Рамазанова Д.Б.* Заман белән бергә // Фәнни Татарстан. 2014. № 4. Б. 35–48.

*Тенишев Э.Р.* Материалы по татарской диалектологии // Избранные труды. Книга вторая. Уфа: Гилем, 2006. С. 65–75.

***Кадирова Энҗе Хәнәфи кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

**2021 елның 29 июнендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында «ХХ гасырда – XXI гасыр башында милли төбәкләрдә тел вазгыяте һәм тел ландшафты» дигән темага халыкара конференция узды. Ул Татарстан АССРда телләр турындагы декрет кабул ителүгә 100 ел тулуга һәм Татарстан Республикасында туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышлап үткәрелде.

Конференция эшендә Россиянең төрле төбәкләреннән (Татарстан, Хакасия, Бурятия, Башкортстан, Дагстан, Якутия һ.б.) һәм чит илләрдән (Финляндия, Азәрбайҗан, Үзбәкстан, Казакъстан) галимнәр катнашты. СССРның милли төбәкләрендә һәм БДБ илләрендә тел сәясәте һәм аны тормышка ашыру, рус телен һәм милли телләрне укыту, массакүләм мәгълүмат чараларының тел сәясәтен үткәрүдәге роле һ.б. мәсьәләләр буенча фикер алышулар оештырылды. Чыгышларда тел проблемаларының тарихи аспектлары (тел белгечләренең фәнни эшчәнлеге үзенчәлекләре, татар зыялыларының телнең абруен, дәрәҗәсен күтәрү өчен көрәшүләре һ.б.) белән беррәттән, телләр үсешенең заманча проблемалары (туган телләр һәм милләтара татулык, ике һәм күптеллелек мәсьәләләре дә каралды.

**2021 елның 28 июненнән 9 июленә кадәр** Пенза өлкәсенең Городище, Лопатино, Шемышейка, Исса, Лунино районнарында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге мөдире, филология фәннәре кандидаты И.И. Ямалтдинов җитәкчелегендәге комплекслы фәнни экспедиция эшләде. Экспедиция барышында галимнәр тарафыннан Пенза өлкәсендә яшәүче татарларының милли-мәдәни мирасын, аерым алганда халкыбызның тел үзенчәлекләрен, халык авыз иҗаты әсәрләрен, музыкаль мәдәниятен һәм сәнгатен, археографик һәм эпиграфик һәйкәлләрен барлау һәм өйрәнү буенча зур эш башкарылды, шулай ук бай традицион мәдәни материал тупланды.

**2021 елның июнь–август айларында** республикада Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы чаралары планына кертелгән «Татарстан халкының мәдәниятләр калейдоскобы» проекты кысаларында Мордовия Республикасы Хөкүмәте каршындагы Гуманитар фәннәр институты, Чуваш дәүләт гуманитар фәннәр институты, В.М. Васильев исемендәге Мари тел, әдәбият һәм тарих институты, Россия Фәннәр академиясе Урал бүлекчәсенең Удмурт тарих, тел һәм әдәбият институты галимнәре катнашында Татарстанның Тәтеш, Нурлат, Әгерҗе, Кукмара районнарында комплекслы фәнни экспедицияләр оештырылды.

Әлеге проект Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты инициативасы белән гамәлгә ашырыла. Аның төп максаты – республика территориясендә яшәүче чуваш, удмурт, мари, мордва халкының рухи мирасын фәнни яктан өйрәнү. Институтның күрше республикалардагы хезмәт-

тәшләре белән уртак эшчәнлеге нәтиҗәсе буларак, «Татарстан халкының мәдәниятләр калейдоскобы» җыентыгын нәшер итү һәм төбәкара түгәрәк өстәл үткәрү күздә тотыла.

**2021 елның 23–27 июлендә** Казанда «Тормыш стиле – мәдәни код» I халык иҗаты һәм декоратив-гамәли сәнгать Этно-Fashion үткәрелде. Фестиваль Россия Федерациясе сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы һәм Татарстан Республикасы мәдәният министрлыгы ярдәме белән оештырылды.

Фестивальдә халык сәнгате һәм декоратив-гамәли сәнгать осталары, һөнәрчеләре һәм рәссамнары, дизайнерлар һәм модельерлар, Россиянең барлык төбәкләреннән, БДБ, Европа һәм Азия илләреннән иҗат берләшмәләре катнашты. Чара кысаларында төрле лекцияләр, уникаль мастер-класслар, гадәти булмаган эшләнмәләр ярминкәсе, дизайнерларның үзенчәлекле күргәзмәләре оештырылды. Фестивальнең төп максаты милләтара татулыкны, Россия, Европа һәм Азиядән килгән осталар арасында хезмәттәшлекне ныгытуга юнәлтелгән иде.

**2021 елның 20 августында** Актаныш муниципаль районында Татарстан мәгариф һәм фән хезмәткәрләренең республика август киңәшмәсе узды. Киңәшмә «Татарстан Республикасында заманча мәгариф – һәркем өчен мөмкинлекләр киңлеге» темасына багышланды. Утырышта Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт җитәкчесе Анзор Музаев, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре, муниципаль районнар башлыклары, мәгариф белән идарә итү муниципаль органнары җитәкчеләре, югары һөнәри белем бирү учреждениеләре ректорлары, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре, мәктәп директорлары катнашты.

Киңәшмә барышында мәктәпкәчә һәм урта гомуми белем сыйфатын күтәрү, һөнәри белем бирү, өстәмә белем һәм тәрбия өлкәләренә кагылышлы актуаль мәсьәләләр каралды, 2021/2022 уку елына бурычлар билгеләнде.

**2021 елның 28 августында** Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Милләтара һәм динара мөнәсәбәтләр буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Совет, Мәгариф һәм фән буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Совет һәм 2021 елда республикада Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитетының уртак утырышын уздырды. Утырышта Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Татарстан Республикасы Премьер-министры Алексей Песошин, Россия Федерациясе Президентының Эчке сәясәт буенча идарәсенең милли сәясәт департаменты башлыгы Татьяна Вагина катнашты.

Утырышта Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директорының фән эшләре буенча урынбасары Олег Хисамов институт тарафыннан әзерләнгән яңа буын «Туган тел (татар теле)» һәм «Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» дәреслекләре турында чыгыш ясады.

**2021 елның 30 августында** Казан шәһәрендә язучы, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Кави Нәҗми һәм аның тормыш иптәше, тәрҗемәче Сәрвәр Әдһәмова хөрмәтенә мемориаль такта ачылды. Истәлек билгесе Большая Красная урамындагы 57б нчы йортта урнаштырылды. Тантаналы чарада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Казан Мэры Илсур Метшин һәм Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары Никита Стасишин, Татарстан Язучылар берлеге вәкилләре катнашты. Тантанада катнашучылар Кави Нәҗми һәм Сәрвәр Әдһәмова яшәгән фатирга чәчәкләр салдылар.

**2021 елның 5–11 сентябрендә** Казанда XVII халыкара мөселман киносы фестивале оештырылды. Фестивальдә тулы метражлы нәфис фильм, тулы метражлы документаль фильм, кыска метражлы нәфис фильм, кыска метражлы документаль фильм номинацияләрендә Россия, Франция, Испания, Кытай, Төркия, Иран, Бельгия, Япония, Казакъстан, Үзбәкстан, Азәрбайҗан, Кыргызстан, Таҗикстан һәм башка илләрдән 50 фильм күрсәтелде. Моннан тыш, төрле кинотеатрларда бәйгедә катнашмаган тагын 150 кинофильм тамашачыларга күрсәтелде.

**2021 елның 10 –12 сентябрендә** «Татарча диктант» дөньякүләм белем тикшерү акциясе узды. Чараның төп максаты – татар теленә һәм мәдәниятенә игътибар җәлеп итү, тел белемен тикшерергә мөмкинлек тудыру, туган телгә карата мәхәббәт уяту. Акция Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты, Бөтендөнья татар яшьләре форумы, Казан (Идел буе) Федераль университетның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты, «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе тарафыннан оештырылды. Чара ел саен берьюлы Татарстан, Россия күләмендә һәм дөньяның төрле шәһәрләрендә уздырыла.

**2021 елның 14 сентябрендә** Казанның «Хәзинә» милли сәнгать галереясендә «Шәмаил арт – 2021» каллиграфия эшләреннән торган күргәзмә ачылды. Әлеге күргәзмә рәссамнарның гарәп каллиграфиясе һәм ислам сәнгате темасына багышланган иҗатын үз эченә ала. Галереядә Мәскәү, Санкт-Петербург, Татарстан, Башкортстан, Екатеринбург һәм Төркиядән килгән осталарның эшләре тәкъдим ителде.

**2021 елның 15–21 сентябрендә** Казанда Кәрим Тинчурин исемендәге VIII Халыкара милли драматургия театр фестивале үткәрелде. Чара Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры тарафыннан оештырылды. Фестивальдә Марий

Эл, Дагстан, Адыгея республикалары, Оренбург өлкәсе, шулай ук Кыргызстан театрлары катнашты. Фестиваль кысаларында тамашачыларга милли драматургия әсәрләре буенча куелган иң яхшы спектакльләр күрсәтелде.

**2021 елның 16 сентябрендә** Татарстан Республикасы Дәүләт Советында элмә такталарда, мәгълүмати табличкаларда, топографик тамгаларда, юл күрсәткечләрендә һәм татар телендәге торак йортларның аншлагларында хаталарны ачыклауга халыкны җәлеп итү буенча республикакүләм конкурска йомгак ясалды. Бүләкләү тантанасында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов, Татарстан Республикасы Кеше хокуклары буенча вәкил, Татарстан Республикасында «Төбәк белән идарә итү үзәге» проектын гамәлгә ашыру буенча проект офисы рәисе Сәрия Сабурская, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин, Дәүләт Советы депутатлары Айрат Зарипов һәм Камил Нугаев катнашты. Конкурс йомгаклары буенча 10 җиңүче билгеләнде.

Әлеге конкурс 2021 елның 1 февраленнән 1 сентябренә кадәр «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы базасында үткәрелде, барлыгы 3000 дән артык мөрәҗәгать кабул ителде. Ул Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре буенча комиссия инициативасы белән Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылды.

**2021 елның 20–29 сентябрендә** Казан (Идел буе) федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында яшь галимнәр, аспирантлар, студентларның фәнни-тикшеренү эшләре республика конкурсы үткәрелде. Чара Татарстан Республикасы рус телле халыкларының традицияләренә һәм хәзерге заман тел культурасына багышланган иде. Конкурска барлыгы 150 эш кабул ителде, шуларның 30 ы – чит илләрдән.

**2021 елның 23–24 сентябрендә** Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан «Милләт Җыены» үткәрелде. Чарада Татарстан Республикасыннан һәм шулай ук Россиянең 70 кә якын төбәгеннән 500 ләп вәкил катнашты. Җыен программасы кысаларында 23 сентябрь көнне «Корстон» сәүдә-күңел ачу комплексында Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура утырышы, шулай ук Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында җыенның катнашучылары өчен «Татар кызы», «Җәлил укулары», «Татарча диктант» һәм «Әйдә ШаяРТ!» татар КВН лигасы кебек масштаблы чаралар тәкъдим итү интерактив тамашасы уздырылды.

24 сентябрь көнне Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов катнашында пленар утырыш үткәрелде.

**2021 елның 27 сентябрендә** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының һәм Гамәли семиотика институтының милли мәгариф өлкәсендәге электрон проектлары презентациясе үткәрелде. «Татар халкын берләштерү факторы буларак татар теле: цифрлаштыруның мөмкинлекләре һәм перспективалары» дип исемләнгән чарада Татарстан Республикасында туган тел һәм әдәбиятны укыту мәсьәләләре, аларны хәл итү юллары; татар теле һәм татар әдәбиятыннан электрон дәреслекләр төзү; туган тел һәм әдәбиятны укытуның яңа формасы буларак видеодәресләр буенча фикер алышу оештырылды. Татарстан Республикасында туган тел һәм әдәбиятны өйрәтүдә заманча белем бирү траекторияләренә күзәтү ясалды (СберКласс платформасы) һәм яңа проектлар күрсәтелде. Чарада Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ тарафыннан әзерләнә торган сүзлекләрнең электрон фонды һәм Гамәли семиотика институтының гамәли лингвистик проектлары демонстрацияләнде.

Презентациядә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, белем бирү оешмалары, вакытлы матбугат вәкилләре һәм онлайн форматта Россия Федерациясе субъектларының туган тел һәм әдәбият укытучылары, Татарстан Республикасының милли мәгариф өчен җаваплы методистлары катнашты.

**2021 елның 28 сентябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе оешуга 30 ел тулу уңаеннан ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Ачык ишекләр көне үткәрелде. Чарага Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Милли музее, Татарстан Язучылар берлеге һ.б. оешма вәкилләре чакырылды.

Әлеге чарада Үзәкнең кульязма һәм басма материалларны, тарихи документларны, шәхси фондларны туплау, саклау, фәнни өйрәнү һәм киң җәмәгатьчелеккә җиткерү юнәлешендәге эшчәнлеге хакында мәгълүмат бирелде. Катнашучылар Мирасханә фондларында сакланган бай материал, шул исәптән язучыларның шәхси архивлары белән танышты. Үзәккә күренекле язучы, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Гариф Ахуновның һәм танылган әдәбият галиме, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Хатыйп Миңнегуловның шәхси архивлары рәсми рәвештә кабул ителде, аларга ТР Фәннәр академиясе президенты М.Х. Саләховның рәхмәт хатлары тапшырылды.

Түгәрәк өстәлдә ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры К.М. Миңнуллин, Язма һәм музыкаль мирас үзәге җитәкчесе И.Г. Гомәровның милли-мәдәни мирасыбызны саклау буенча чыгышлары тыңланды, җанлы фикер алышулар булды. Шулай ук Мирасханә фондында сакланган сирәк ядкярләр, кулъязма мирас үрнәкләре, шәҗәрәләр, әдипләребезнең шәхси архив материалларыннан күргәзмә дә оештырылды.

**2021 елның 30 сентябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр

академиясе оешуга 30 ел тулуга, Татарстанда академик фәннең 100 еллыгына багышланган тантаналы утырыш узды.

Утырышта Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Мәкъзүм Саләхов «Татарстанның академик фәне: тарих һәм хәзерге заман» доклады белән чыгыш ясады. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев Татарстан галимнәрен Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе оешуга 30 ел тулу белән котлады. Чарада Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, ТР Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева, ТР Ректорлар советы рәисе, ТР ФА академигы Илшат Гафуров, Макс Планк исемендәге институт (Германия) директоры, РФА академигы, ТР ФА нең шәрәфле әгъзасы Рәшит Сюняев (онлайн-режимда), Висконсин университеты (АКШ) һәм Назарбаев университеты (Казакъстан) профессоры, ТР ФАнең шәрәфле әгъзасы Юлай Шамилуглы (онлайн-режимда) катнашты.

Утырыш кысаларында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе галимнәренә дәүләт һәм ведомство бүләкләре тапшырылды.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2021. № 3

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 30.09.2021. Басылды: 20.10.2021.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,5. Тираж 500 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшриятында басылды
(нәшрият адресы – 420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20)

Журнал бушлай таратыла